1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН 2019 ИЮЛЬ № 7

СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398

НИКАХ КИЛЕШҮЕ
сүздә түгел, кәгазьдә

БЕРЕНЧЕ МӘХӘББӘТ
ата-ана өчен дә сынау

БӘЙРӘКӘ ПАЛАСЫ
һәр авылның – үз бизәге



Алсу НӘБИЕВА:

КҮМӘКЛӘП ТОТЫНСАҢ, ТАУ ДА КҮЧӘ!

Минем өчен син һаман да – 17 дә!..

Минем өчен син һаман да – 17дә!..

Бу фотосурәтләр еракта калган кабатланмас мизгелләргә – Яшьлеккә алып китә... ...Шундый зур галәмдә меңнәр арасыннан бер-береңне эзләп табу – үзе үк могҗиза! Аны күргәч кабынган хисләр – иң саф, иң ихлас, иң садә... Йөрәктәге сагышы да – якты, татлы, моңлы... Беренче очрашу... Аның кебек башка берәү дә юктыр! Дөнья – матур, яшәү шундый рәхәт! Очар өчен канатлар кирәкми дә!.. Ярату, йөрәккә генә сыялмыйча, җанда шигырь булып бөреләнә... Һәм мәңгегә Син – Шагыйрь, Ул Илһамчың булып кала...



Ләбиб ЛЕРОН

ЕЛНЫҢ СОҢГЫ ТӨНЕ

Фиданиягә

Кышкы авыл төне.
Бүлмә.
Икәү.
Чыршы исе катыш хушбуй исе.
Радиола.
Салмак көй агыла –
Җырлый Джо Дассен.

Тәрәзәдән төн сыгылып керә,
Ай яктысын йота иреннәрең!
Күзләреңә багып сөйлим
Блокның
«Таныш түгел туташ»
Шигырьләрен...
Яңа елга каршы төн бу!
Икәү.
Талгын гына, әнә, көй агыла.
Елның соңгы төне!..
Һәм син:
«Сөям», – диеп
Пышылдыйсың колагыма.

Рәсемдә: шагыйрьнең хатыны Фидания ханым. 1980 нче еллар.

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2019

1926 елдан башлап «Азат хатын» исеме белән чыкты. 1991 елда «Сөембикә» итеп үзгәртелде. Хатын-кызларның бөтентатар айлык әдәби-нәфис журналы 1913–1918 елларда чыккан «Сөембикә» журналының дәвамчысы.

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кулъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.



Фото: Анна Арахамия

Баш мөхәррир
Л. Н. Маликова

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нурия Вәлиева, Искәндәр Гыйләҗев, Нәбирә Гыйматдинова, Айрат Зарипов, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Рафаэль Шәвәлиев, Равилә Шәйдуллина, Лотфулла Шәфигуллин.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77

Җитәкче урынбасары 222-09-78
Рәмзия Кашапова
Баш мөхәррир урынбасары 222-09-78
Гөлнур Хәсәншина
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова
Әдәби мөхәррир
Эльмира Закирова
Сайт мөхәррирләре:
Сөмбел Гаффарова
Камилә Димөхәммәтова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Тышлыкта:
Алсу Набиева
Фото: Анна Арахамия

Верстка:
Лариса Маликова

Бүлек мөхәррирләре:
Чулпан Галиәхмәтова
Лилия Гәрәева
Эльмира Закирова
Ландыш Әбүдәрова
Фотокорреспондент
Анна Арахамия
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Гамәли хезмәткәрләр:
Нәфисә Әскәрова
Олег Сердюк

Формат: 225x290 мм
Күләме 64 бит

Басарга кул куелды: 02.07.2019 ел
Заказ О-1730
Тираж 5118

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77
Язылу индексы:
П2204 (ПАП рәсми каталогы буенча)
73002 («Роспечать» каталогы буенча)

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикә»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002





Фото: Анна Арахамия

Баш мөхәррир сүзе



Таныш булыйк, миңа күптән таныш укучым!
Әле кичә генә кебек... «Сөембикә»гә килүем, дулкынлана-дулкынлана баш мөхәррир бүлмәсенә аяк басуым... Баксаң, инде 25 ел узып та киткән! Бу еллар эчендә редакциядә бергә эшләгән һәркем минем өчен тормыш мәктәбе, тормыш тәҗрибәсе дә булды...
Бер көнне көтмәгәндә үземнең уемны «тотып», көлеп куйдым: редакциягә журнал алырга килгән һәр абунәчегә: «Ә ул яңа саныбызда үзе өчен нинди кызык әйбер табар микән?» – дип сынап карыйм икән бит! Һәм күңелемнән барлык язмаларны барларга керешәм... Әйе, сез күп, сез төрле... Ләкин журнал чыгу дәверендә редакция хезмәткәрләре – бүгенгеләре дә, узгандагылары да һәрберегезне күз алдында тотып эшли, иҗат итә. Һәр көн иртән редакция бусагасын атлап керәбез дә журнал гаменә күмеләбез: чираттагы сан тагын да кызыклырак, эчтәлеклерәк, тагын да матуррак булырга тиеш! Нәкъ менә безнең укучы көткәнчә, ул күз алдына китергәнчә, теләгәнчә...
Безнең укучы... Журналыбызның һәр укучысы миңа да шәхсән таныш кебек. (Шулай булмыйча, инде чирек гасыр сезнең белән бит мин!) Әмма күзгә-күз карашу – беренче тапкыр...

Сезне яратып,
Лариса МАЛИКОВА.

Безнең тышлыкта

«Үзең үрнәк күрсәтмәсәң – башкаларны эшләтә алмыйсың. Беркайчан да! Үзем тотынып эшләп карамыйча кешегә куша торган гадәтем юк.»



14 Бер кул белән төен бәйләмиләр
Гөлнур Хәсәншина

Заман һәм без

6 Гаилә тоткасы – хатын-кыз
Фәрит Мөхәммәтшин белән Гөлнур Сафиуллина әңгәмәсе

10 Иртәгәсе көнгә ышаныч?
Чулпан Галиәхмәтова





18 «Бездә шулай савалар...»
Мәдинә Авзалова

22 Беренче мәхәббәт
Лилия Гәрәева

Татар дөньясы



26
Бәйрәкә бизәкләре
Гөлнур Сафиуллина

Мәдәни тормыш



30
«Аккош кебек ак пароход...»
Эльмира Закирова

36
Тәрәзәдә – янә кояш?..
Фәйрүзә Мөслимова

Яшәеш



48
Имән шаһит...
Лариса Маликова



52
Истанбул ритмы
Гөлүсә Закирова

Хатын-кыз галәме



60
Яһүд ашы – чолнт



62
Хуш исле каһвә...

»

PRESSA

ГАИЛӘ ТОТКАСЫ – ХАТЫН-КЫЗ



Гөлнур САФИУЛЛИНА

Элек гаиләләрнең ныклыгы хатын-кызның матди яктан ир-атка бәйле булуы белән аңлатылган. Ә бүген күп нәрсә гаиләдә мөнәсәбәтләрнең гармониясенә бәйле. Ул юк икән – гаилә таркала. Бу гармонияне тудыруга хөкүмәт тә тәэсир итә аламы? Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Хәйрулла улы МӨХӘММӘТШИН белән әңгәмәбез шул хакта.

Гаилә – дәүләтнең иң кечкенә ячейкасы, дип кабатларга яратабыз. Бүгенге көндә гаиләләр безнең дәүләт өчен ни дәрәҗәдә мөһим?

– Гаилә – җәмгыятьнең нигезе. Шушы сүзгә барысы да сыйган... Гаиләләр нык, тату, бердәм, сәламәт икән, җәмгыять тә төзек була. Гаилә институтында – ә ул иң мөһим институт! – соңгы вакыт шактый үзгәрешләр күзәтелү дәүләтне борчый, әлбәттә. Узган ел, мәсәлән, безнең республикада 24 865 яңа гаилә корылган. Әмма шул ук вакытта 13 456 се таркалган. Һәр икенче гаилә дигән сүз бит бу!.. Аерылышучыларның күбесе – ун ел да бергә тормаучылар. Яшьләр сабыр итүнең, түзүнең ни икәнен онытып бара... Алар гаилә корырга ашыкмый. Бала табарга ашыкмый... Гаиләнең «ир эшли, хатын балалар тәрбияли» дигән моделе күптән искерде. Бүгенге хатын-кыз, гомумән, җәмгыятьтәге урынын югалтудан курыкмаса, теләсә кайсы вакытта эшенә кире кайта аласын тәгаен белсә генә бала табарга әзер бугай ул. «Гражданский брак» дигәннәре – адым саен. Аның яшьләр күңелендә – бигрәк тә хатын-кызда – калдырган рухи зыяны турында күбрәк сөйләргә иде безгә.

Сез ничек уйлыйсыз: гаиләнең матди хәле, бигрәк тә аның рухи, әхлакый ныклыгы белән кешенең җәмгыятьтәге активлыгы арасында турыдан-туры бәйләнеш бармы?

– Гап-гади мисал. Иртә таңнан өйдән якыннары белән нәрсәгәдер ачуланышып чыгып киткән кешедә эш кайгысы буламы? Шушы хәл көн саен кабатлана башласа? Шуның өстенә акча проблемасы да килеп кушылса... Үзенең ярдәменә мохтаҗ кешене дә күрми ул, әйләнә-тирә табигатьне саклау турында да уйламый, җәмгыятьтә барган үзгәрешләргә дә битараф – аның дөньясы үз дөньясы белән генә чикләнә. Мондый хәлдән чыга алмыйча кемдер эчүгә сабыша, авырый башлый – тормышы начар булганга башкаларны гаепли. Гаиләдә авыру бала булса – тагын бер авыр хәл.

Әлбәттә, дәүләт бу проблемаларны күрми кала алмый. Дәүләт Советында социаль мәсьәләләр белән шөгыльләнүче комитет бар, хатын-кыз депутатлардан торган «Мәрхәмәт» берләшмәсе эшли. Гаилә мәсьәләләре, аналар һәм балаларга кагылышлы сораулар һәрдаим аларның көн тәртибендә. Дәүләт тарафыннан күрсәтелгән ярдәмнәрнең берсе – Ана капиталы дияр идем. Бүген Ана капиталы 453 мең сумны тәшкил итә. Икенче бала туугa бирелгән бу акчаны күп гаиләләр торак шартларын яхшыртуга тота. Аны шулай ук баланың укуы өчен түләргә, гаиләдә инвалид бала булган очракта, аны тернәкләндерү өчен файдаланырга да мөмкин.

Тик эш акчада гына да түгел. Күңел, җан дигән нәрсә дә бар бит әле. Күптән түгел «Мәрхәмәт» берләшмәсе оештырган хәйрия концертында булдым. «Без бергә!» дип аталган бу проект – киң колачлы проект, ул мөмкинлекләре чикләнгән сәләтле балаларга республиканың атаклы иҗат коллективлары белән бер сәхнәдә эшләү мөмкинлеген бирә. Авыру балаларга «канат куя», аларга үз сәләтләрен үстерергә, киләчәктә тормышта үз урыннарын табарга ярдәм итә. Арча балалар йортында тәрбияләнүче Риназ Гобәйдуллинны, мәсәлән, Салават быел үзенең концертларында катнашырга чакырырга вәгъдә биргән, диделәр. Кем белә, бәлки, ул егет Салават абыйсы аркасында җырчы булып китәр. Иң куанычлысы шул: проект бу балалар тормышына яңалык алып килгән, алар нәрсәгәдер өйрәнгән һәм үзендә көч тойган. Һәм... үзендә җәмгыятьнең хәерхаһ карашын тойган. Үзен кирәкле итеп тойган! Бу – барысыннан да мөһимрәк!

Соңгы вакытта күп балалы гаиләләрне күз алдында тотып кабул иткән хөкүмәт карарларының кайсысы сезне бигрәк тә сөендерә?

– Бер генә карар да буш урында тумый. Узган ел республикада 46 793 бала дөньяга килде. Бу 2017 елга



Хатын-кызның гаиләдәге роле күпкә зуррак. Алар шуны онытмасын.

караганда 3,7 процентка кимрәк... Балалар тууны арттыру нисбәтеннән 2018 елның февралендә Татарстан Министрлар Кабинетының 67 нче Карары дөнья күрде. Авыл җирендә яшәүче хатыннарга бала тапкан очракта бер тапкыр бирелә торган түләү турында ул. Аның нигезендә 25 яше тулмаган әниләргә (авыл җирендә өч ел яшәгән булуы шарт) беренче баласы тугач – 50 мең, 29 яше тулмаганнарга (шулай ук авыл җирендә өч ел яшәгән булуы шарт) өченче баласы тугач 100 мең сум акча түләнә. Шул вакыт эчендә меңнән артык (беренче баласын табучылар – 831, өченче баласын табучылар – 162) яшь ана социаль учреждениеләргә түләү сорап мөрәҗәгать иткән инде. Авылларда балалар туу – икеләтә шатлык! Авыл яши дигән сүз! Бу карар өчен ничек сөенмисең!

Республикада инвалид баланы уллыкка-кызлыкка алучыларга бер тапкыр бирелә торган түләү дә артты, бүгенге көндә ул 200 мең сум тәшкил итә. Тик мондый адымга баручыларның игелеген бернинди акчалар белән дә бәяләп бетереп булмыйдыр, мөгаен...

Тагын бер күңелле яңалык: Россия Дәүләт Думасы өченче укылышта күп балалы гаиләләргә ипотека кредитын каплау өчен бер тапкыр бирелә торган ярдәм турында закон кабул итте. Бу закон Россия Президенты Владимир Путин кушуы буенча әзерләнгән. Закон өченче яисә аннан соңгы баласы 2019 елның 1 гыйнварыннан соң туган гаиләләргә кагыла. Аларга ипотека кредитын каплау өчен 450 мең сум акча биреләчәк. Бу акчалар Россиянең 2019–2020 елларга кабул ителгән бюджетына инде кертелгән. Сизелерлек ярдәм булачак.

Аерылышуга нинди күзлектән карарга? Хокук бозу дипме, әллә җинаять дипме?

– Икесе дәдер, мөгаен... Гаиләне ничек саклап калырга соң? Кайчандыр Татарстан Дәүләт Советы утырышында ул мәсьәләне берничә мәртәбә күтәрдек. Мин шундый фикергә килдем, моны әйткәнем дә бар – тагын кабатлыйм. Яшьләрне бер-берсенә туры китереп таныштырулар юк бугай хәзер.

Бөтенләй юк дип әйтеп булмый, ул йола бүген кабат яңара...

– Яңаруы бик әйбәт. Элек бик киң таралган иде ул... Хәзерге яшьләр, ашыгып, бер-беренең холкын тирән белмичә гаилә кора. Аннан ярты ел яшиләр дә, «характерларыбыз туры килми», дип аерылышалар. Хәзер бит бик җиңел: ЗАГСка да барып йөрисе юк – гаризаны интернет аша гына язып җибәрәсең. Никахлашкандагы кебек. Тик икенче очракта бит бер дә ашыгырга ярамый. Кайчак аларны «суыту» өчен вакыт, читтән бирелгән бер акыллы киңәш тә җитәр иде. Минә шуңа



Фото: Анна Арахамия

да ир белән хатынга уйлар өчен бирелгән вакытны озайтканда начар булмас иде дип саныйм. Гомумән, аерылышу процессын катлауландырырга кирәктер. Дөнья бит – төрле хәл булырга мөмкин: ачуланышасың да, үпкәлисең дә, үпкәләтәсең дә... Сәбәбе дә табылып тора. Беренче мөрәҗәгать итүдә үк аермасалар, кайчак ир белән хатын, бәлки, бу уйдан кире дә кайтыр иде. Менә ни өчен ЗАГС бүлеге хезмәткәрләре чиновник кына түгел, психолог та булырга тиеш. Аерылышырга гариза язган пар белән генә түгел, аларның әти-әниләре – кода-кодагыйлар белән дә сөйләшсен иде алар... Менә шушы фикерләрнең барысын туплап, законга үзгәртүләр язган идек. Кызганыч, бу уңайдан Татарстан парламентының закон чыгару инициативасы Россия Федерациясе Думасында тиешле яклау тапмады. Үзләре кавышкан, үзләре аерылыша: нишләп ике кеше арасына кысылабыз, бу аларның хокукларын бозу була, диделәр. Әмма гаиләнең таркалуына «икәүнең шәхси эше» дип кенә карарга ярамый, минемчә. Аерылышуның аяныч нәтиҗәләрен анализлау һәм шуның аркасында авыр хәлдә калган якны закон нигезендә яклау – дәүләт эше. Ата-аналары аерылышудан еш кына иң зур психологик яраны балалар ала. Шуның өстенә матди кыенлыклар да килеп кушылса... Ә андый кыенлыклар бөтен очракта да диярлек барлыкка килә – ялгыз әнигә баласын аякка бастыру җиңел түгел.

Татарстан Республикасы буенча суд приставлары федераль хезмәте идарәсе өстәлендә алимент юллау буенча 21 меңгә якын «эш» җыелган. Тиешле кешеләргә барып җитә алмаган сумма 2,9 млрд. сумны тәшкил итә. «Тиешле» дигәндә, чит-ят турында сүз бармый бит – ата кешенең газиз баласы турында әйтәбез. Бу бала каршындагы бурычы, җаваплылыгы турында...

Алиментларны юллап алу буенча чаралар күрелә, әлбәттә. Бүгенге көндә Татарстанда алименттан качып йөрүче 12 мең кешегә Россиядән читкә чыгу мөмкинлеге бетерелде, 1 меңнән артыграк кеше административ җаваплылыкка тартылган, Җинаять кодексының 157 нче маддәсе буенча 339 җинаять эше ачылган. Бу саннар артында никадәр язмыш, аларның тормышкөнкүреше ята... Алимент түләмәүчеләр арасында матди яктан төрле дәрәҗәдәге кешеләр бар. Эшсезләр дә, аз хезмәт хакы алучылар да, шактый хәллеләр дә... Узган парламент утырышында нәкъ менә аерылышуларга, алимент түләүләргә кагылышлы өч закон проектын әзерләп, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрдек. Без тәкъдим иткән закон чыгару инициативалары бу эшләрне җайга салу буенча кайбер тәкъдимнәрне кертә. Алимент билгеләгәндә төбәкнең уртача хезмәт хакы Россиядәге уртача хезмәт хакыннан азрак булганда, түләүче яшәгән төбәкнең уртача хезмәт хакыннан чыгып исәпләргә кирәк дип саныйбыз. Аерма бик зур бит. Мәсәлән, безнең Кама Тамагы районында уртача хезмәт хакы – 24, ә Мәскәүдә – 85 мең сум.

Алимент түләүченең милке булып та, ул аны фиктив рәвештә башка кеше исеменә яздырган очракта, җинаять эше ачарга кирәк дип барабыз. Безнең бу теләктәкъдимнәр Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында яклау табар дигән өмет бар.

Аерылышуга – ир белән хатын арасындагы дөрес булмаган мөнәсәбәтләр китерә. Шуларның камиллегенә омтылуга ирешү кирәк. Моңа яшьләр күз алдында матур мисаллар булганда гына өйрәнә ала. Ә сез әти-әниегез арасындагы мөнәсәбәтләрнең кайсыларын үз гаиләгезгә күчердегез?

– Анасына карап – кызын, атасына карап улын коч, диләр бездә. Бер-береңнең нәселен, җиде буын әбибабасын белгәндә генә ныклы гаилә төзеп була дигән фикер ята әлеге мәкальнең асылында. Бу миңа тулысынча туры килә. Әлмәт әле кечкенә генә авыл булган чагында әти-әнием булачак хатыным Луизаның әтиәнисе белән аралашып яшәгән. Әтием Луизаның әнисе Рокыя Саримовна белән бер мәктәптә укыган, ә булачак кодасы белән яшүсмерләр футбол командасында бергә уйнаган – яшьтән үк дус булганнар. Луиза белән икебез дә бертөрле шартларда үскәнбез: кыйммәтле киемнәр кимәдек, кесәдә зур акчалар йөртмәдек. Аны да, мине дә эш белән тәрбияләгәннәр. Балаларны үстергәндә без дә шул тәҗрибәне кулландык.

Луиза белән хәрби хезмәттән кайткач, 1968 елда таныштым. Очраклы рәвештә генә. Әлмәт шәһәре комсомол оешмасына Хезмәт Кызыл Байрагы бирелү уңаеннан оештырылган кичәдә күрдем аны. Очраклы дим дә... Мөгаен, язмышыма шулай язылган булган.

1970 елның 25 декабрендә без өйләнештек. Шул көннән башлап Мөхәммәтшин һәм Хуҗиннар гаиләләренең тормыш юлы бергә үрелеп китте. Әтиәниләрнең бер-берсен күптән белүе ярдәм итте: дус, тату, бер-берсенә ышанучан, булышучан, бердәм зур гаиләгә әйләндек. Нинди дә булса сәбәп табып еш очрашырга тырыштык. Безнең балаларга әби-бабай тәрбиясе биргән мөһим еллар да булган бу.

Икебезнең дә әти-әниләр бик гади, булганына шөкер итеп яшәде – без дә шулай яшәргә тырыштык.

Әтием гомере буе укыды, белем алды. Төннәр буе КПСС тарихы турында китаплар, газеталар укып, радио тыңлап, чыгыш-докладларын «халыкка аңлаешлы булсын», дип язып утыра иде. Һәр очрашуга бик җаваплы итеп әзерләнде. Миңа да: «Улым, әзерлексез килеш кеше белән эшләве авыр. Берүк халык алдына алдан әзерләнмичә чыга күрмә, чөнки әйткән сүзеңә ышанмаска мөмкиннәр. Дәлил, аргументлар табып сөйләргә кирәк. Әйткәннәреңне үз көндәлек тормышың белән дәлилләп күрсәтергә тиешсең. Бер сүз сөйләп, икенче төрле яшәсәң, кеше синнән көләчәк кенә», – дия торган иде. Мин Әлмәт шәһәре партия комитетының беренче секретаре итеп сайлангач әйткән сүзен дә онытмыйм: «Кара аны, кесәдәге борчакны алып сибеп җибәрәсе генә җиңел. Төрлесе төрле якка тәгәрәгәч, аларның барысын да соңыннан берничек җыеп ала алмыйсың. Йөземә кызыллык китермәскә тырыш». Луизага рәхмәт: «әтиегезгә сезнең өчен кызарырга туры



килмәсен» дигән фикерне улыбыз белән кызыбызга да кечкенәдән төшендерде. Луизаларда да тәртипләр бездәге кебек кырыс булган. Шуңа күрә без дә этиәниләр кебек үк балаларны иркәләп үстермәдек. Әйтик, кичке сәгать тугызда Дамир белән Лилия инде йокларга ятарга тиеш иде. Кайчак, кунаклар килгәч, онытылып китәләр. «Балалар...» – дигән бер сүз җитә иде. Әти белән әни дә безгә шуннан артыгын әйтмәде! Вак-төяк кебек тоела гына: үзеңне мәҗбүриләп нәрсәдер эшләргә шулай өйрәтәсең. Тормышта бик кирәк сыйфат!

Әнием Маһинур – әтиемнең ныклы, ышанычлы тылы иде. Әти командировкаларга, укуларга еш йөрде, әнигә шуннан хатлар яза иде. Ул хатлардагы җылылык, мөнәсәбәтләрнең чисталыгы, хөрмәт... Без шул шартларда тәрбияләндек. Әти әнигә «карчык» дип эндәшә иде. Бу сүз хәзер минем дә телемә керде.

Татарстан парламентында ир-атлар хатын-кызларга караганда күпкә күбрәк. Димәк, республика бюджеты да ир-атлар кулында, бүлүче – алар. Гаилә дә кечкенә дәүләт дидек, ә анда акча кем кулында булырга тиеш дип саныйсыз?

– Моны ир белән хатын киңәшләшеп хәл итәргә тиештер. Нигә дигәндә, уртак мал турында бара бит сүз. Аны булдыруга икегез дә: син дә, җәмгатең дә өлеш кертә. Ул балалар үстереп өйдә генә утырганда, акчаны өйгә син генә алып кайтканда да, хатыныңның бу малга хокукы бар. Гаиләдә акча хатын-кыз кулында булса дөресрәк түгелме икән әле? Мин моны үз гаиләм мисалыннан да чыгып әйтәм. Зуррак берәр нәрсә ала башласаң, хатын-кыз башта төрле яклап уйлап, чамалап карый ул. «Ашыкмыйк әле... Ансыз яшәдек бит, тагын бераз яшәрбез. Сентябрь җитә менә хәзер, балаларны мәктәпкә әзерләргә кирәк», – ди ул. Мәктәп тәмамлар чак якынлашса: «Тукта әле, сабыр ит. Балаларны укытасы бар – акчаны азрак җыебрак торыйк», – ди... Һәм ул күп вакыт хаклы булып чыга! Акчада гына түгел, күп мәсьәләләрдә шулай.

Бүген парламентта хатын-кызлар чыннан да күп түгел – унбишәү генә. Эшкә мөнәсәбәтләре белән ир-егетләрдән аерылып торалар – бик җаваплылар. Бөтен социаль тармак алар игътибарында. Ир-ат депутатлар тавыш бирүчеләр арасында күпчелекне тәшкил итсә дә, акча хатын-кызлар карамагында булган тармакларга күбрәк бүленә. Республика бюджетының 60 проценттан артыгы социаль чыгымнарга китүен искә алсак, акчаны кем бүлә булып чыга инде бездә?

Гаиләнең ныклыгы аның традицияләренә дә бик нык бәйле, диләр. Ә сезнең гаиләдә бармы алар?

– Соңгы елларда барлыкка килгән бер традиция турында гына әйтәм. Оныклар белән «Үлемсез полк»ка кушылуыбыз турында. Иң беренче тапкыр кечкенә оныгым Данияр белән чыккан идек. Аңа сугышта катнашкан ике бабакае турында сөйләдек, башына солдат пилоткасы кигездек... Бик горурланып атлады ул бабакаеның рәсемен күтәреп.

Әтием Хәйрулла Мөхәммәтшин солдат хезмәтеннән туп-туры яуга барып кергән. Сугышны башыннан ахырына кадәр узган. Гомере буе фронтташ дуслары белән элемтәдә булды. Луизаның әтисе Әкрам Хуҗин да – Бөек Ватан сугышы ветераны, капитан. Яу кырында күрсәткән батырлыклары өчен Кызыл Йолдыз, Беренче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, күпсанлы медальләр белән бүләкләнгән. Быел без аларның портретларын башка оныклар өчен дә ясатып алдык. Нәсел тарихын белгән кеше үз халкының үткәнен белер, үткәнен белгәннең киләчәге дә матур булыр!

Җәһәт әңгәмә



БӘХЕТ УЛ – өйдә аңлашып, тату, матур яшәү, балаларның гаилә корулары, оныклар бүләк итүләре – болар барысы да минем өчен олы бәхет. Эшеңдә уңышларга ирешә алмасаң да, бәхетле була алмас идең. Аралашыр өчен дусларың, таяна алырлык хезмәттәшләрең булмаса. Сәламәтлегең булмаса...

БАЛАЛАРЫГЫЗГА ИҢ ЕШ КАБАТЛАГАН КИҢӘШЕГЕЗ – бик акыллы киңәш биреп тә, үзең икенче төрле яшәсәң, балаларга тәрбия бирә алмыйсың. Тәрбиянең иң зур өлеше – балалар каршында үз-үзеңне ничек тотуга бәйләнгән.

СЕЗНЕҢ ӨЧЕН ГАИЛӘ – бу сүзгә барысы да сыйган...

АЛИМЕНТ ТҮЛӘМӘГӘН ИР-АТ – оятсыз... Үзара килешмәдегез, аерылыштыгыз ди, тик бала бит гаепле түгел. Хатын гаепле булса да, бала гаепле түгел!

ОНЫКЛАР БАЛДАН ТАТЛЫ, ДИЛӘР – алар безнең иң зур, иң төп байлык! Шимбә көнне безнең зур гаилә бергә җыела. Һәр атнаны шулай! Атна арасында да оныклар шалтыратып, хәл белешеп торалар: «Бабай, ни хәлләр? Дәү әни ничек анда?» – диләр. Бабай диләр!

ЛУИЗА ХАНЫМДА СЕЗ ИҢ ХӨРМӘТ ИТКӘН СЫЙФАТ – мине ярты сүздән, бер күз карашымнан аңлый белүедер.

ГАИЛӘНЕ САКЛАУ ӨЧЕН ХАТЫН-КЫЗ КОЛАГЫНА ГЫНА ӘЙТЕРГӘ ТЕЛӘГӘН КИҢӘШЕГЕЗ – гаиләне саклауда хатын-кызның өлеше күбрәк. Әйе, аларга сабыррак, түземлерәк булырга туры килә. Хатын-кыз безгә яшәргә көч, дәрт бирә.


Фото: Анна Арахамия

Никах күкләрдә укыла, диләр. Ә җирдә ул теркәлә. Мендельсон маршы, тантана, якыннар, дуслар... Яратышкан парлар, балдаклар алышып, гаилә корырга әзер икәнлекләрен раслыйлар. Шул минуттан башлап егет һәм кыз ир белән хатын дип игълан ителә. Димәк, шатлыкта, байлыкта да, кайгыда, авырлыкларда да җитәкләшкән кулларны ычкындырмаска тиешләр. Шатлыкта, байлыкта яшәү рәхәт анысы, ә тормыш көймәсе көнкүреш дигән кыяга килеп бәрелсә... Авырлыкларга түзә алмаганнар җиңел юлга баса: аерылу. Кызганыч, әлеге юлны сайлаучылар бик күп. Рәсми теркәлгән һәр икенче гаилә таркала һәм... милек бүлешү башлана. Ике як та күбрәк эләктереп калырга тырыша. Милек бүлешү – кем кемнең канына күбрәк тоз сала ала дигән уенга әйләнә кебек. Аерылышу – дөнья хәле. Бу вакыйганы милек бүлешеп тагын да ямьсезләмәү өчен гаилә шартнамәсе булышмасмы? Ә бәлки гаиләне таркатмаска да ярдәм итәр ул?.. Иң мөһиме – безне, хатын-кызларны да яклар...



Чулпан
ГАЛИӘХМӘТОВА

ИРТӘГӘСЕ КӨНГӘ ЫШАНЫЧ?

Статистика буенча, кичәге яратышкан парларның милек бүлешүе – гражданлык эшләре арасында иң катлаулы категорияләрнең берсе. Уен эшмени, кайбер гаиләләрдә фатир гына түгел, кашык-чәнечкене дә бүлешә башлыйлар. Әти-әни алып биргән малны бүлгәләү хакында әйтеп тә торасы юк. Алдын-артын уйлап яшәгәннәр алдан ук чарасын күрә бу җәһәттән. Без ачык, цивилизацияле дөньяда яшибез. Кануннарны да, билгеле бер кешеләргә генә түгел, безнең өчен дә язылганын аңлап куллана башладык.

Кызын кияүгә бирү мәшәкатьләре белән йөргән танышым яшьләргә кагылышлы сорау буенча юристка барып кайтканын әйтте. Аптыравым йөземә чыкканны күреп: «Гаилә шартнамәсе турында белештем», – диде. Баксаң, яшьләргә фатир сатып алырга акча бирмәкче икән. Ата-ана шулай ярдәм итеп торгач, матур итеп яшәп китсәләр ярый да. «Хәзер яшьләр нәзберек бит. Проблема килеп чыгуга, аерылышам, дия башлый, бер кеше дә аннан хали түгел. Соңыннан фатир алып бирүеңне судта раслап йөрерсеңмени?!» – ди ул. Хокук белгече яшьләргә гаилә шартнамәсе төзергә киңәш иткән. Шул вакытта аерылган очракта әлеге фатир бүленми калачак. Юрист Диләрә Фәхретдинова нәкъ әлеге мәсьәлә буенча әти-әниләрнең консультациягә еш килүен, бу сорауда гаилә шартнамәсенең иң уңышлы чишелеш булуын әйтә.

Мәхәббәттән баш әйләнә шул! Барыбыз да, тиң ярымны таптым, кушылабыз да гомер буе тигез, матур яшәп, бер көндә бакыйлыкка күчәрбез, дип өметләнәбез. Билгеле, болар бар да матур, тик яши башлагач, алар кайчак тоныкланып кала. Шуңа күрә мал ягын, яшьләрдән битәр, гомер кичкән, тормыш тәҗрибәсе булган ата-аналар кайгырта. Ата-аналарының гаилә шартнамәсе төзү хакындагы киңәшен яшьләр теләп кабул итәме әле? «Без бер-беребезгә ышанабыз», – дип кенә җибәрәләр. Шуңа күрә танышым бу мәсьәләне булачак кода-кодагыйлары белән уртага салып сөйләшергә карар кылды. Киңәшле эш таркалмас, дигән

борынгылар. Бәхеткә, кияүнең әти-әниләре дә алдынгы карашлы кешеләр булып чыга. Яшьләрне бергәләп гаилә шартнамәсе төзергә үгетлиләр. «Дөрес аңла, бүген өйләнешерләр дә, иртәгә аерылышырлар дип бармадым бу адымга, – ди танышым. – Киресенчә, фатир алып биреп, тормышларын башлап җибәрергә ярдәм иттем. Бәхетле булып яшәүләрен телим. Ләкин мәхәббәт белән малны катыштырырга ярамый».

СССР заманында бернинди гаилә шартнамәләре төзелмәгән. Аерылышкан очракта ир һәм хатын милекне үзара килешеп яки суд аша бүлешкән. Тапканы – бергә, югы уртак дип яшәгәннәр. Хәзер исә көнбатышта популяр булган әлеге документны Россия халкы да үз итә башлады. Гаилә шартнамәсе дигән төшенчә гаилә кодексында 1995 елларда барлыкка килә. Дөрес, әлеге институт чит илләрдәге кебек үк үсеш алмаган әле бездә. Шулай да Россия Юстиция министрлыгы статистикасы буенча, соңгы елларда гаилә шартнамәсе төзү очраклары арта. Узган ел илдә 110 мең шундый килешү теркәлгән. Быелның беренче айларында ул 25 меңгә җиткән инде (Татарстанда гаилә шартнамәсе буенча статистика дәүләт сере булып саклана дип аңлаттылар Республика нотариаль палатасында). Безнең илдә гаилә шартнамәсе милек бүлү белән генә чикләнә. Чит илләрдә, кагыйдә буларак, андагы пунктлар бик күп. Хәтта ир белән хатынның атнага ничә тапкыр яратышырга тиешлеге дә язылa. «Аларда гаилә шартнамәләре күбрәк каприз үтәүгә кайтып кала, ә бездә ул җитди, ике якны да яклый торган документ. Аларныкы гаилә мөнәсәбәтләрен кысаларга кертсә, бездә ул ир белән хатынга тормыш алып барырга, мөгамәләләрне җайларга ирек бирә», – ди юрист.

Гаилә шартнамәсе нотариуста раслана. Гаилә рәсми рәвештә теркәлгәч кенә ул үз көченә керә. Рәсми теркәлүсез яшәүчеләр аны яза алмый. Кемнәрдер – гаилә коруга ук, икенчеләре – яшәү барышында, ә кайберәүләр гомер көзләренә кергәч кенә шартнамәне төзи. Соңгылары – олыгаеп яңа гаилә коручылар. Дөрес, гаилә төзегәнче булган мал бүленми. Ә менә яши башлагач сатып алган милекне бүлешергә туры киләчәк. Бигрәк тә әби-бабайның балалары да бүлешү эшләрендә катнаша башласа... Икенче тапкыр гаилә коручылар беренче хатыныдагы балаларына мирас калдырмас өчен дә шартнамәне төзи, ди нотариуслар. (Әйе, андый аталар да була!)

Соңгы вакытларда Россиядә гаилә шартнамәсе күбрәк төзелүнең тагын бер сәбәбе бар: ул ипотека белән бәйле. Ипотека – күпчелекнең яшәү урыны булдыру өчен бердәнбер чара. Гаиләдә берәү эшләми, йә булмаса хезмәт хакы түбән икән, банк бурычка фатир алып бирүдән баш тартырга мөмкин. Йә үз мәнфәгатьләрен яклап, гаиләгә шартнамә төзү шартын куя. Шул рәвешле, фатир – бурычын кайтара алган иргә яки хатынга кала. Нәтиҗәдә, җаваплылык фатир хуҗасына гына төшә. Дөрес, Диләрә Фәхретдинова кредит бирү оешмаларының әлеге гамәлен законсыз дип аңлата.

Диләрә ФӘХРЕТДИНОВА: *Яшьләр әти-әни алып биргән милеккә карата гына шартнамә төзергә мөмкин. Бергә тапкан мал – уртак!*



– Банк берничек тә гаилә шартнамәсе төзүне таләп итә алмый. Ул – ир белән хатын арасында килешеп башкарыла торган гамәл. Әгәр дә банк, гаилә шартнамәсе юк, дип кредит бирүдән баш тарта икән, сез аны судка бирә аласыз, – ди юрист.

Банк сорый, дип, гаилә шартнамәләре төзүнең артуы халыкның кануннарны ныклап белмәве белән аңлатыла. Бәлки, белеп тә әлеге документны эшләтәләрдер. Кеше почмагында яшәп алҗыганнар фатир алу өчен барысына да әзер. Форсатны гына кулдан ычкындырмаска!

Гаилә шартнамәсе хатын-кызлар өчен аеруча әһәмиятле, чөнки, кагыйдә буларак, гаиләдә ир кеше мал табучы, ә хатын-кыз балалар тәрбияли, йорт мәшәкатьләренә күмелә, иренә карьера баскычлары буенча үсәргә шартлар тудыра. Мал тапкан иренең авызына карап, аерылышудан куркып яшәгән бәхетсез хатын-кызлар аз түгел, чөнки аерылышкан очракта бернәрсәсез калачак бит алар. Уртак тормышта җыелган малда өлешең барлыгын раслар өчен суд юлын таптарга туры киләчәк. Ә гаилә шартнамәсе бу мәшәкатьләрдән азат итә. Ул гарант булып тора. Моннан кала, ир белән хатын аерылышкан очракта бер-берсенә нинди финанс ярдәме күрсәтәчәген документта аерым шарт итеп теркәргә мөмкин. Хатынга билгеле бер сумма яки милек калдыру турында бара сүз. Бу урында миллиардер Роман Абрамовичны искә алырга кирәктер. Биш бала табып биргән хатыны белән ул судсыз, низагсыз гына аерылыша. Аңа бик күп милкен калдыра. «Без Абрамович кебек бай түгел, килешербез әле», – дип әйтүчеләр шуны аңласын иде: байлар уртак фикергә килер, аларның бүлешер маллары күп, ә гади халыкка алдан ук килешеп кую хәерлерәк.

Яши башлаганда шартнамә төзедегез, ди. Яшәү дәверендә мал тупланмый калмый. Аларын нишләтергә, диярсез. Юристлар ике төрле юлын күрсәтә: беренчесе – шартнамәдә бергә яши башлагандагы милек кенә күрсәтелә (әти-әниләр бүләк иткән дип укы!), калган эшләп тапканы – уртак, йә милек кем исеменә язылa, аерылышканда шуңа кала дигән пункт өстәргә мөмкин.



Рөстәм хәзрәт ХӘЙРУЛЛИН: *Татар гаиләләрендә никах килешүен гомер-гомергә төзегәннәр. Ләкин кәгазьдә түгел, сүздә, чөнки ул вакытта сүзнең көче зур булган.*

Икенчесе исә яңа мөлкәт өстәлгән саен, җитәкләшеп нотариуска барып, шартнамәгә үзгәреш кертү. Әйе, бу көлке кебек күренә. Безнең менталитетка бик туры килми. Күпләр әлеге документны көнбатыш шаукымы дип кабул итә, әмма тарихка күз салсак, татар гаиләләрендә ул гомер-гомергә шулай булган. «Никах килешүен кыз сорарга барганда ук төзегәннәр. Ата-аналар, кызлары нинди шартларда үссә, кияүгә чыккач та шундый ук шартлар тудыруны таләп иткәннәр. Егет ягының бу таләпләргә әзер булуына инангач кына кызларын биргәннәр», – ди Казанның «Гаилә» мәчете имам-хатыйбы Рөстәм хәзрәт Хәйруллин. Хәзер мондый сөйләшүләргә, нишләптер, игътибар ителми, дөресрәге, кыз белән егет, яратабыз, калганын соңрак уйларбыз, дип, әтиәнисенә сүз башларга ирек бирми. Замана да, карашлар дә икенчерәк. Сүзнең дә кыйммәте төште, шуңа күрә булган сөйләшүләрне ташка басу хәерлерәк. Шартларны никахка кадәр генә куеп була, һәм ул ике якның әтиәнисе тарафыннан алдан сөйләшеп бетерелергә тиеш. Элек Никах килешүе Халык судында теркәлгән, хәзер дә аны рәсми рәвештә раслатырга була.

– Революциягә кадәр килешү никах укылганчы төзелгән. Ир бер сәбәпсез аерылыша калса, хатынына штраф түләргә тиеш булган. Аның күләме алдан ук сөйләшенеп куелган, – ди Рөстәм хәзрәт.

Хәзер, аерылышулар арткан бер чорда, җәмгыятькә әлеге тәҗрибәне кабат кертү кирәк. Мондый шартлар булса, аерылышу юлына басканчы ир-ат йөз тапкыр уйлаячак, дип саный хәзрәт. Бу – гаиләне ныгытырга да мөмкин. Совет чорында юкка чыгарылган никах килешүе дини даирәгә инде кире кайта башлаган. Рөстәм хәзрәт сүзләренчә, аны никахлашканнарның 10 проценты төзи. Нигездә, бу карарга яшьләр үзләре килә икән. Шартлар арасында төрлеләре бар. Мәсәлән, бер кәләш никах килешүенә, ире аерылышкан очракта, Мәскәүдән өч бүлмәле фатир алып бирергә тиеш, дип яздырткан.

– Гаилә шартнамәсен төзүчеләр аз, – ди юрист Диләрә Фәхретдинова. – Мондый адымга, кагыйдә буларак, зур милеккә ия булучылар бара. Ә алар – халыкның 5 процент тирәсе. Башкалар, бу безгә кагылмый, дип, ул хакта уйланмый да.

Без бит әле мәхәббәткә ышанучы, романтик халык. Мондый исәп-хисап эшләре самими хисләрне каралта дип саныйбыз. Моны бер-береңә ышанмау дип кабул итәбез. Гомумән, проблемаларны башка төшкәч кенә хәл итәргә алынабыз, һәм тынычлыгыбызны, саулыгыбызны югалтып туктыйбыз. Шуңа күрә дә гаилә шартнамәсе төзү – киләчәк хакында кайтырту, килеп туарга мөмкин булган бәхәстән цивилизацияле чыгу юлы. Ул безнең хокукны һәм җыйган малны саклый. Ә менә нәкъ шулар киләчәккә ышаныч тудыра Шик-шөбһәләргә урын калмаганда, мәхәббәт тә көчлерәк, самимирәк түгелме соң? Яратышып кына яшә!

ФИКЕР



Флюра ИЛДАРХАНОВА, социология фәннәре докторы

Гаилә шартнамәсе безнең өчен яңа күренеш. Күп еллар ЗАГС идарәсендә эшләдем, тик шартнамә төзү очракларын хәтерләмим. Хәзер дә сирәк кенә төзелә әле ул. Ләкин аны бик кирәкле документ дип саныйм. Бүген һәр өченче-дүртенче гаилә ипотека ала. Бу уңайдан торак проблемаларын булдырмас өчен, яшьләргә шартнамә ярдәмгә килергә мөмкин. Дөрес, ул милекләре, ата-ана мирасына варислар булганнарга мөһимрәк. Безнең җәмгыятьтә 70 процент гаилә уртача хәлдә яши. Шуңа күрә мал бүлешү хакындагы килешү кирәксез дип саналадыр.

Аерылышучылар кайвакыт еллар буе милек бүлә алмый. Менә шушындый очракларда шартнамә ачыклык кертер иде. Нишлисең, заманы шундый... Әхлакый байлыкка караганда, материаль кыйммәтләр өстенрәк булган чорда яшибез.

Рәсми теркәлгән һәрбер парга әхлакый гаилә шартнамәсе дә төзетер идем. Анда гаиләне саклау, берберәңне хөрмәт итү, бөтен проблемаларны уртага салып сөйләшү кебек әдәп кагыйдәләрен кертергә кирәк, чөнки хәзер һәр ике гаиләнең берсе таркала. Гади итеп кенә әйткәндә, җомга көнне туй ясасалар, дүшәмбе көнне инде аерылышырга киләләр.

Гаилә шартнамәсе төзү – берберәңне камиллеккә сынау да бит әле ул. Ирнең тәрбия дәрәҗәсе ачыкланырга мөмкин. Хатынына, балаларына күпме өлеш чыгаруга карап, аның әхлакый йөзе ачыла. Өен, бар байлыгын калдырып, бер чемодан гына күтәреп чыгып китүче ирләр бик сирәк хәзер. Ә мондый документлар гаиләне саклау, бигрәк тә хатын-кызны, балаларны яклау максатыннан булдырыла. Аны куллану мөмкинлегеннән баш тартмаска кирәк.

ФОТОБӘЙГЕ:
«ОБЪЕКТИВТА – ӘНИ»



Фото: Андрей Титов. Казан.

«Объективта – әни» бәйгесе дәвам итә. Аның оештыручылары – «Сөембикә» журналы редакциясе һәм «Казан Кремле» музей-тыюлыгы. Фотосурәтләрегезне 31 октябрьгә кадәр җибәрә аласыз.
Исегезгә төшерәбез: иң уңышлы дип тапкан эшләр журнал битләрендә дөнья күрәчәк, ә көзгә – Әниләр көнендә – Казанда, «Манеж» күргәзмәләр залында алардан күргәзмә оештырылачак.
Җиңүчеләрне планшет, кесә телефоны кебек кыйммәтле бүләкләр көтә.
Конкурсның нигезләмәсе һәм шартлары белән сайтыбыздан таныша аласыз: www.syuyumbike.ru.

БЕР КУЛ БЕЛӘН ТӨЕН БӘЙЛӘМИЛӘР



Фото: Анна Арахамия

Әйе, бәйләмиләр дә, чишмиләр дә! Ул үзенең студентларына бу хакта һәр көнне искәртеп тора. Хәер, аларга гына да түгел... Шулай, тауны күмәкләп тотынсаң гына күчерә аласың!
Россия кооперация университетының Казан кооператив институты ректоры Алсу Рөстәм кызы НӘБИЕВАның эшен, тормышын Фейсбук аша күзәтеп баручылар да минем кебек: «Ничекләр өлгерә ул?» – дип шаккаттамы икән? Бер көнне ул Санкт-Петербургта фәнни-практик конференциядә катнаша (Санкт-Петербург аграр университеты белән хезмәттәшлек итү турындагы килешүгә кул куярга да өлгерә!), икенче көнне инде ул – Актаныштa. Бу юлы Россия татар авыллары ассоциациясе һәм Татарстан фермерлары һәм крестьян хуҗалыклары ассоциациясе белән хезмәттәшлек итү хакындагы килешүне имзалый, өченче көнне... Юк, Фейсбук битенә куелган фотосурәтләр янындагы бу кыска язулар барысын да сөйләми. Әйтелми калганы – тау кадәр!

Гөлнур ХӘСӘНШИНА

Бөтен теләгем – студентлар белем алсын да авылга кире кайтсын.

«Мин ректор вазыйфаларын кабул итеп алгач, иң беренче очрашуыбызда Татарстан авыл хуҗалыгы министры Марат Әхмәтов: «Бер кооператив булса да төзеп кара», дигән иде...»

– Әйе, кооператив төзелеше турында теория генә сөйләп йөри алмыйбыз – аны үзебез оештырып күрсәтергә дә тиеш идек. Сөенеп әйтә алам: бүгенге көндә безнең тарафтан инде 50 дән артык кооператив һәм ревизион союз төзелде. Моңа ничек ирештекме? Җыенабыз да районнарга чыгып китәбез: җирлек башлыклары белән сөйләшәбез, авыл халкы белән очрашабыз. Нәрсә ул кооператив, аңа берләшү нигә кирәк, ресурсларны берләштерүдән нинди файда алып була, дәүләт тарафыннан нинди ярдәм, булышлык көтәргә? Әлеге сорауларга җавап бирәбез, укытабыз, өйрәтәбез. Шуның нәтиҗәсендә кооперативлар төзелде. Инде алар бәйгеләрдә катнашып, грантлар отарга да өлгерде. Әйтик, Питрәч районындагы балык җитештерү һәм эшкәртү кооперативы грант отты. Тагын биш кооператив конкурста катнашу өчен гариза тапшырды – нәтиҗәләрен көтәбез. Ревизион союз да моңарчы безнең республикада берәү генә иде. Ул шушы кооперативларга күзәтчелек итә, эшләрен контрольдә тота. Закон буенча, бөтен кооперативлар да ревизион союзга керергә, ә анда иң кимендә 25 кооператив булырга тиеш. Без оештырган кооперативлар үз ревизион союзларын төзеде, взнос күләмен дә үзләре билгеләде.

Хәзер инде кооперативлар төзүдә ярдәм сорап, районнар безгә үзләре мөрәҗәгать итә. Бүген инде барысы да беләː дәүләт тарафыннан аларга байтак ярдәм каралган. Ресурсларны берләштерү шулардан файдалану мөмкинлеге бирәчәк. Кооператив булып оешканда, продукцияләрен кыйммәтрәк бәягә сата алалар. Әйтик, сөт җитештерүчеләр берләшә икән, егермешәр меңнән кушылып, сөт җыярга машина сатып алалар – продукцияне арадашчысыз үзләре илтеп тапшыралар. Теләгәндә, кечкенә генә сөт җитештеру



■ Безне быел Бөтенроссия татар авыллары эшмәкәрләре җыенының бер мәйданчыгы итеп сайладылар. Анда катнашучыларның да күбесен «хәләл» сертификатын алу мәсьәләсе кызыксындырды. Регионнарда яшәүче татарлар: «Бездән дә студентлар кабул итегез әле», – диде. Башка регионнардагы 36 көллият белән килешү төзедек менә. Очрашу файдага булды!

производствосы да төзеп куярга мөмкиннәр.

Ә безнең студентлар өчен кооперативлар төзү – ул практика. Бигрәк тә «кооператив оешмаларның икътисады»н өйрәнүчеләр өчен. Алар кооперативларга юридик һәм «бухучет» ягыннан ярдәм итәләр, салым мәсьәләләрен хәл итәргә булышалар. Икенче яктан, кооператив – эш урыны да. Бүгенге студент, димәк, үзенә иртәгәгә эш урыны әзерли. Авылдан килгән студент кире авылга кайта икән, ул «подъемный» акчалар да ала, бер ел буе аңа МРОТ буенча минималь хезмәт хакы күләмендә пособие дә түләнә. Кооперативта эшләсә дә. Авыл хуҗалыгы министрлыгына белешмә китереп тапшыру гына кирәк. Яңа эшли башлаган кеше өчен зур ярдәм бит. Бу акчаны үзләре кооператив төзегәннәр дә ала.

Авылны яшәтү – бүгенге көндә мин моны үзебезнең төп максатыбыз дип саныйм. Беренче курска килүгә студентлар анкета тутыра, «Авылга кире кайтырга җыенасызмы? Моның өчен төп шарт нәрсә?» дигән сорауга җавап бирә. Әлбәттә, барысын да тору һәм эш урыны кызыксындыра. «Фитнес, төнге клуб» дип язучылар да бар. Быел шундый тәҗрибә ясап карадык: районнардагы кулланучылар җәмгыятенә студентларны практикага җибәрдек. Хәтта шәһәрнекеләрне дә. Ул түләүле практика булды – кулланучылар җәмгыяте 15 әр мең түләде, яшәү урыны белән тәэмин итте. Кооперативларның нәрсә икәнен эчтән белү өчен бик мөһим бу практика. Шәһәрнекеләр бик авырсынып кына күнгән иде, аннан үзләренә ошап та китте. Киләчәктә аларның хәтта 10 проценты гына авылга кайтып төпләнсә дә, безнең бу эшнең нәтиҗәсе булыр.

«Бүген Казан кооператив институтында төрки дөнья хатын-кызлары фикер алышты. Татар мәдәният үзәгендә үткән бу түгәрәк өстәлдә Төркиянең Татарстандагы генераль консулы хатыны Мария Доган да катнашты».

– Кооператив институтта татар мәдәнияте үзәге... Әйе, кемнәрдер өчен сәер тоелуы да бар. Студентларыбызның яртысы – шәһәрдән. «Безгә татар теле курслары кирәк иде», – дип алар мөрәҗәгать итте. Бушлай курслар оеш-

«Без – кооперация институты, сез монда берләшергә өйрәнәчәксез», – дим студентларыма.



Студентларга белем генә бирәбез, тәрбия – безнең эш түгел, дию белән килешмим. Алар кооператив институтта укый, ә кооператив – берләшү, бердәм булу, командада эшли белү дигән сүз. Безнең максат – шушыңа ирешү. Кооператив төзүдә дә иң мөһиме берләшә белү бит. Тормыш итү өчен бу – мөһим сыйфат, алдагы көнегездә дә кирәк булачак дип аңлатам студентларга. Гаилә дә шул ук берләшү бит ул. Әгәр икәүнең берсе гаилә эчендә гел «мин» генә дисә, андый гаилә озак яшәми – йә бүген, йә иртәгә таркала...

тырдык. Бу курсларга институтка якын-тирәдә яшәүче халык та язылды. Курслар эшләп киткәч, студентлар белән очрашуга татар артистларын, зыялыларны, шагыйрьләрне чакыра башладык. Татар мәдәният үзәге шулай оешты. Ачылышына бөтен татар дөньясына билгеле шәхесләр җыелды. Шуннан соң атна саен диярлек үзәктә берәр чара үткәрелә башлады. Безнең татар мәдәният үзәгенә бүләк ителгән экспонатлар турында исә аерым сөйләргә кирәк. Апанаевлар нәселе дәвамчылары китергән тарихи ядкарьләр үзләре генә дә ни тора! Үзәк эшли башлагач, хатын-кызларның аеруча актив икәнлеге күренде. «Әйдәгез, мәдәният үзәге каршында хатын-кызлар клубы төзик», – дигән карарга килде алар. «Исемен ничек куярга?» – дип уйлаша башладык. Мөхлисә Бубыйның тууына быел 150 ел икәне искә төште. Беренче татар казыясы, исеме уку йорты белән бәйле шәхес. Аңа тукталдык. Мөхлисә Бубый исемендәге клубның иң беренче утырышына Камал театры актрисасы, Татарстанның халык артисты Дания Нуруллинаны да чакырдык. Ркаил Зәйдулланың театр сәхнәсендә барган «Үлеп яратты» әсәрендә Мөхлисә Бубый ролен ул уйный бит. Шуннан өзекләр уйнады: барыбызның да йөрәкләрен тетрәтте... Клубыбызны «Ак калфак» татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасы съездында катнашучыларга да тәкъдим иттек. Гомумән, республикада барган байтак чараларда катнашырга өлгердек. «Тукайга мәхәббәт илә...» дип аталган Бөтенроссия шигырь сөйләүчеләр бәйгесенең безнең институт диварларында узуы да бик күп нәрсә турында сөйли, минемчә.

Минем өчен укытучы буларак та, ректор буларак та балаларны төрле-төрле коллективлар белән бергә эшләргә өйрәтү мөһим. Бер-берсенә буйсынып, бер-берсенә юл биреп, бердәмлекләрен күрсәтеп... Бүген бу – бик авыр эш. Әйткәнемчә, коммуникацион барьерлар бар: бер өстәл артында утырганда да, сөйләшмичә, бер-берсенә «смс» кына җибәрергә мөмкин бүгенге яшьләр. Командада эшләү үз артыннан шактый күп тәрбия мәсьәләләрен дә кузгата: бер-береңә ышанырга, ышанычны акларга, намуслы булырга өйрәнү.

«Бүген бездә кунакта минем укытучым – профессор Ильяс Топсакал. Ул Казанга Татарстан Фәннәр академиясе чакыруы буенча килде. Эш графигы бик тыгыз булса да, безнең төрек үзәгенә кереп чыгарга да вакыт тапты».

– Бездә ни өчен төрек теле һәм мәдәнияте үзәге дә эшлиме? Моның сере бик гади. Беренчедән, мин үзем кайчандыр төрек лицеен тәмамладым. Безгә анда бик төпле белем бирделәр. Аннан укуымны университетта, тарих факультетында дәвам иттем. Диссертация яклადым. Төркия буенча Татарстандагы беренче диссертация иде ул... Икенчедән... Бездә туризм һәм отель эшләре буенча уку юнәлешләре бар. Аларда белем алучы студентларны практикага чит ил отельләренә җибәрү мәсьәләсе килеп туды. Төркиянең Казандагы генераль консуллыгы безгә берничә отель тәкъдим итте. Студентлар Төркиядә җаен эшләп кайттылар да: «Төрек телен өйрәнәсебез килә. Икенче елга тагын барыр идек, телне дә белсәк, яхшырак урыннарга урнашу мөмкинлеге бар, хезмәт хакыбыз да югарырак булачак», – диделәр. Аларның теләге буенча укыта башладык. Консуллык укытучылар бирде, дәреслекләр кайтарды. Курсларны тәмамлау турындагы сертификатны да генераль консул Әхмәт Доган аларга үз кулы белән тапшырды.

«Бүген Татарстан икътисад министрлыгы оештырган лекториядә «Минималь капитал белән үз эшеңне ачу» дигән темага лекция укыячакмын...»

– Мин аларга кооперативлар турында сөйләдем. Минималь ресурсларны берләштереп, нәрсәгә ирешеп булганын аңлаттым. Без моны еш кына очрашуларда мәктәп балаларына да өйрәтәбез. «Синең дәфтәрең ничә сум тора?» – дип сорыйм берәр баладан. «20 сум», – дип җавап бирә ул. «Сез сыйныфта 20 бала, һәрберегезгә бер дәфтәр алу өчен, димәк, 400 сум акча кирәк, – дим. – Ә хәзер, әйдәгез, җыегыз шул 400 сум акчаны. Һәм мин сезгә берәр дәфтәр һәм берәр тундырма да алып киләм». «Ничек

алай?» – дип аптырыйлар. «Бөтенегезнең акчасын кушкач, дәфтәрне инде 20 сумга түгел, 15 сумга гына алам. Чөнки күмәртәләп алганда бәясе кимрәк тора», – дим. Массакүләм куллану икътисады шушы була... Институтта фәнни бер тикшеренү үткәрдек. Бездә 500 ләп кеше эшли, 6500 студентыбыз бар. Алар бер атнага күпме ит, сөт, каймак, бәрәңге, карабодай сатып ала һәм шуның өчен күпме өстәмә акча түли – барысын да исәпләдек. Үзебезнең ашханә базасында логистик үзәк оештырдык. Атна буе заявка җыябыз: кемгә, күпме, нәрсә кирәк? Ә пәнҗешәмбе көнне, шул заявка системасы буенча кооператорларыбыз безгә продукция китерә. Ике якка да файдалы: фермер товарын сата, ә безнекеләр арзан һәм органик продукция ала. Пайлар алмашу дигән сүз шушы инде. Катнашучылар – товарны алып килүчеләр дә, сатып алучылар да – барысы да безнең кулланучылар җәмгыяте әгъзалары. Студентлар кооперациясе дип атала ул безнең. Кооперативның нәрсә икәне, нигә кирәге – күз алларында.

Диплом алганнан соң, авылга кайтып үз кооперативларын оештыручылар инде бар. Мәсәлән, икътисад факультетын тәмамлаган Рамазан Хәйдәров туган ягында – Әлки районы Иске Чаллы авылында ит җитештерү буенча кооператив төзеде. (Сүз уңаеннан: Әлки – минем дә туган ягым, тамырларым – шуннан. Күптән түгел мине Әлки якташлар җәмгыятенең җитәкчесе итеп сайладылар.) Аның янында башка авыллардан да пайчылар тупланыр дигән өмет бар. Сыерлар өчен яңа комплекс төзергә хыяллана. Грант программасына керергә тели. «Эшне алып барырга алган белемем бик булыша», – ди.

«Бәхетемнән җиде кат күктә бугай бүген мин! «Студентлар язы» фестиваленең Гран-прие – бездә! Иң сәләтле студентлар Казан кооператив институтында укый!»

– Бу минем өчен шулкадәр зур вакыйга! Ректор урындыгына утырганчы, җиде ел – тәрбия эше, аннан дүрт ел укыту эше буенча проректор булып эшләдем. Студентларыбызның бу фестивальдә Гран-при алуы – хыялым иде. Яшьләр арасында бик популяр булган җырчы Альберт Нурминский безнең студент хәзер: сервис һәм туризм кафедрасында укый. Фестивальнең концертын «Корстон»да оештырдык: бер мең ярым тамашачы сыешлы залда урын җитмәде. Күпләр Альберт Нурминский чыгышын карарга дип тә килгән иде. Ул безнең тамашаның дәрәҗәсен бик күтәрде. Андагы алкышларны, андагы эмоцияләрне күрсәгез! Жюри шаккатты! Гран-придан тыш, «Иң яхшы режиссер эше», «Профессияләрне иң яхшы тәкъдим итүче уку йорты» дигән грамоталар да алдык. Программабыз һөнәрләргә багышланган – отель тормышы турында иде. Кунакханәдә эшләүче хезмәткәрләр – горничныйлар алъяпкычын бәйләп, ахырда сәхнәгә мин дә чыктым.

Шундый фикердә мин: үзең үрнәк күрсәтмәсәң – башкаларны эшләтә алмыйсың. Беркайчан да! Үзем тотынып эшләп карамыйча кешегә генә куша торган гадәтем юк. Чаңгы ярышына да студентлар белән бергә чыктым, «Үлемсез полк»та да алар белән бер сафта атладым...

«Институтыбызның «Homies» кафесы башкалардан аерылып тора хәзер. Ул «Хәләл» стандартын алды. Республика югары уку йортлары арасында без – бердәнбер!»

– Безнең институт Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте каршындагы «Хәләл» комитетының уку-укыту мәйданчыгы булып тора. «Хәләл» сертификатын алырга теләгән оешмалар безгә мөрәҗәгать итә. Яңа гына вебинар системасы буенча Севастопольдән бер оешманы укыттык: андагы татар-башкорт оешмасының заказы иде бу. Бик канәгать калдылар! Бу сертификатны ничек алырга, аның өчен ниләр белергә кирәк – үзебезнең кафе өчен документлар әзерләгәндә студентлар барысына да өйрәнде. Хәләл – мөселман кануннары буенча чалынган ит, әзерләгән ризык кына түгел, ул – яшәү рәвеше хәзер. Хәләл туризм, хәләл медицина дигән терминнар инде гадәти сүзгә әйләнеп бара. Безнең «Туклану продуктлары технологиясе» факультетында да хәләл темасы модуль буларак өйрәнелә. Ә экспорттагы хәләл темасы «Таможня эше» факультетында укытыла: төрле юнәлешләр шулай хәләл темасында берләшә. Татарстаннан экспортка китә торган продукция «хәләл» булып чыкса, ул читтә, бигрәк тә мөселман илләрендә популяр булыр иде.


Сүз уңаеннан: кафебыз хәләл стандартына ия булгач, Рамазан аенда ифтар мәҗлесен инде үзебездә генә уздырдык. Һәр мөселман кешесе ураза аенда халык өчен ифтар уздырырга тиешлеген татар студентлары күрергә, ислам диненең бу йоласына өйрәнергә тиеш дип саныйбыз.

«Абитуриентлар белән очрашуга әзерләнәбез! Бүген татар телендә трек-сәламләү яздырам. Безнең институтта нинди телләргә өйрәнергә була – һәркайсында яңгыраячак ул».

– «Таможня эше» дигән юнәлешне 2011 елда ук ачкан идек: инде бу бүлектә өч чыгарылыш студентлар әзерләдек. Аэропортларда, таможняда, таможня янында булган структураларда эшләргә безнекеләр кирәк. Гомумән, «Таможня эше» эчендә профильләр шактый, әйтик, мәгълүмати куркынычсызлык, хокук саклау эшчәнлеге һәм башкалар. «Оргсинтез», «Татнефть», хәтта «Бәхетле» кебек экспорт-импорт белән эшләүчеләргә – чит илләргә товар сата яки үзе сатып алучыларга да безнең студентлар кирәкле кадр. Быел ике яңа юнәлеш ачтык менә. Беренчесе – «икътисадый куркынычсызлык» – хәзерге заман өчен бик кирәкле белгечлек. Икенчесе – икътисад буенча магистратура. Хәзер безнең чылбыр түгәрәкләнде дисәк тә була: IX сыйныфтан соң урта профессиональ белем алырга да була бездә, XI сыйныфтан соң бакалаврны тәмамларга да, инде менә магистратурага керергә дә. Моннан тыш, аспирантурабыз да бар. Ә минем хыялым – көллият алдыннан мәктәп тә ачу. Юк, алай түгел – мәктәп һәм балалар бакчасы!



«БЕЗДӘ ШУЛАЙ САВАЛАР...»



Мәдинә
АВЗАЛОВА

Ишекне ачып керүгә үк иң «крутой» мегафермаларның берсенә килеп эләгүебезне аңладык.









Сыйфатлы сөт җитештерү энә белән кое казудан ким түгел икән.

Кукмара яклары – таулы яклар. Түбән Казаклар авылыннан читтәрәк, өстәрәк – таулы җирдәрәк урнашкангамы, сөт шәһәрчеге шундук күзгә ташлана. Безне «Урал» хуҗалыгының «капка»сыннан ук каршы алган җирле үзидарә башлыгы Рамил Фәйзелхак улы Маликов, үзе артыннан ияртеп, әле килгәнче үк ишеткәнебездән хәйран иткән мегафермага алып китә. «Башта карыйк, күрик... анда эшләүче кызлар чая безнең, сораганны көтеп тормаслар, үзләре сөйләр».

Җиңел машина асфальт юлдан элдереп кенә мегаферма капкасын үтеп китә дә, зур бер бина янына килеп туктый. Машинадан төшкәч тә тирә-юньгә күз ташлап, бермәл ис китеп карап торабыз. Ферма яннарында чәчәкләр, басарга куркып торырлык чисталык, тәртип... Рәттән тезелешеп киткән биш зур торакның һәркайсының үз билгеләмәсе. Янәшәдә генә «тудыру йорты», аннары азык-төлек заводы, сыер саву залы, «Карусель», «Ёлочка»лар...

Бинага (биредә эшләүчеләр аны торак дип сөйләшә) йөгереп кенә кереп китмәкче идек, шундук кулыбыздан эләктереп алып туктаталар. «Аяк киемнәрегезне салыгыз!» Салабыз, башмаклар киябез дә, җирлек башлыгының сөйләгәнен тыңлый-тыңлый, баскычтан күтәреләбез, сыер саву залына килеп эләгәбез.

Берәү дә биредә чиләк күтәреп йөрми. Сыер имчәген тартып утырмый... Савылырга тиешле маллар «Карусель»гә кереп басканнар да, «әйлән-бәйлән, сөт һәм әйрән» дигәндәй, әкрен генә, бер җайга әйләнәләр дә әйләнәләр. Шаккатып, тел шартлатып карап торуыбызга да исләре китми. Таптылар искитәрлек нәрсә, без бу «Карусель»дә көненә өчәр әйләнәбез, диләр микән. Маллар кинәнгән арада, җилендәге сөт имчәкләргә каптырылган аппаратлар аша торба буйлап зур савытларга йөгерә. Баш зоотехник Нурсил Галиев әйтмешли, көненә бер вагон сөт савыла. Көненә, җәмәгать! 200 баш мөгезле эре терлеге булган һәм көненә 24–25 литр сөт савып, аһ иткән, куанган заманалар да бар иде бит безнең?! Бүген исә әлеге гаҗәеп сөт илендә – бер торакта гына 450 баш мөгезле эре терлек асралып, көненә һәр сыердан 32 шәр, 40 ар литр (!) сөт савып алына. Бинаны салып кую гына түгел шул, анда эшли белергә дә кирәк! Ә иң мөһиме: алдагысын уйлап эш итәргә! Әйтик, алар киләчәктә савым сыерларны 1500 башка (хәзер 1400 баш) җиткергәч, сөтен киметә башлаган сыерларны, таналарны иткә җибәрергә уйлыйлар. Иске торакларда яшәүче 200 баш сыер турында да онытмыйлар. Барын кертеп исәпләгәндә биредә иллеләп кеше эшли. Шуларның унсигезе сыер савучы, малларны «Карусель»гә кертеп торучылар, операторлар, зоотехниклар, монитор каршында утыручылар да шушы исәпкә керә.

– Сыерларның һәркайсына тамга тагылган, – ди баш зоотехник. – Колакларына да, муеннарына да. Мал әйләнә башлауга ук компьютер эшли башлый, кайсы малдан күпме сөт алынуы, һәм нинди сөт алынуы барысы да мониторда чагылып бара. Рационнары бертөрле булса да, сөтне төрлечә бирәләр.

Сөтнең, итнең сыйфаты, әлбәттә инде, малны ничек ашатуга бәйле. Бу яктан «Урал» авыл хезмәтчәннәренең күңеле тыныч. Бигрәк тә сөтләрен сатып алучы Чүпрәле, Биектау, Арча районнары халкы бәхетле: сыйфатлы, тәмле сөт эчә алар! «Силос, сенажны үзебез әзерлибез. Рационны тулыландыру өчен арпа, бодай, соя, арыш, кукуруз кушабыз. Тагын витамины да булсын дип, микро-макро элементлар да өстәп җибәрсәң», – дип вәземләп сөйләгән Нурсил Васыйл улын тыңлап, малларга азык әзерләү – үзе бер сәнгать икән дигән нәтиҗәгә киләбез.



■ Гүзәлия: «Кияүгә чыкканда миңа 17 генә яшь иде әле. Илшатка ул чагында – 19. Яшь идек. Яшьлек җүләрлеге булдымы икән, бер ел йөрдек тә өйләнештек. Тормышлар үкенерлек булмады анысы. Ирем әйбәт минем. Күп сөйләшми, өйрәтми, андый гадәте бөтенләй юк».

«Рәхәтләнеп эшлибез...»

Мегаферма тәүлек буе – өч смена эшли. Беренче смена – иртәнге дүрттән көндезге сәгать уникегә кадәр. Без смена тәгәлләнеп килгән чакка туры килдек. «Карусель»нең эчке ягында дүрт хатын-кыз – дүрт сыер савучы (сменада алар дүртәү генә)... 1400 сыерга хезмәт күрсәтәләр. Хезмәт күрсәтәләр дигәч тә, аларның бурычы – җиленгә саву аппаратларын каптыру һәм соңыннан малларның җиленнәрен һәм аппаратларны әйбәтләп юу... Яныбызда гына шул эшләр белән мәш килгән бер ханым гаҗәпләнеп карап торуыбызны күргә: «Их-х, чак кына соңга калдыгыз, – ди дә, –

Фото: Анна Арахамия

Эшләр алга таба да шулай уңышлы барса, кукмараларның сөтчелек буенча илнең үзәгенә әйләнеп куюлары да ихтимал!

бездә менә шулай савалар!» – дип куя. Горурлану да, үзенә бер мактану да бар бу сүзләрдә. Сөйләшеп китәбез. Гүзәлия исемле икән. Ул сменасын тапшырган арада, җирлек башлыгы: «Ире дә, улы да фермада», – дип, шушында эшләгән Гобәйдуллиннар гаиләсе турында сөйләп ала.

– Әйдәгез, мин сезгә үземнең ферманы күрсәтәм, – ди, каршыбызда елмаеп басып торган Гүзәлия.

Түбән Казакларда андый «ферма» белән кеше гаҗәпләндерәм димә, абзар тулы мал асраучылар – ике өйнең берсендә. Гүзәлия дә: «Ике үгез, ике савым сыер, ике тана, ике бозау тотабыз», – дип санап китә. Әле алар көтүдә икән, шуңа тагын тавык-чебешләрне дә кушсаңмы?! Фермадан бер дә ким түгел. Янында гына күз күреме җитмәс зур бакча, бәрәңгесе, яшелчәсе, җиләк-җимеше... барысы да кул астында, иел дә өзеп ал гына. Ничек эшлисең, шулай яшисең, кыскасы. Тормышлары белән танышканнан соң, без моңа тагын бер кат инандык. Каршыбызга чыккан кече уллары Рәдил фермага эшкә ашыга иде.



– Миннән башка булмый анда, – ди ул безгә. – Смена башланганчы аппаратларның, суыткычларның торышын тикшереп-карап чыгасы бар.

Ул – оператор. Җиһазларның торышына җаваплы кеше. Ватылганын рәтли, төзәтәсен төзәтә, саву тәртибен күзәтә. Әнисе кайтты, хәзер әнә улы эшкә чыгып китеп бара.

– Бөтен гомер ферма белән өй арасында йөреп узды, – дип сөйли Гүзәлия ханым. – Төрлесен күрдек. Фермага тездән пычрак ерып барган чаклар да булды. Аяктан резин итекләр төшмәде. Ә хәзер... хет биек үкчәле туфли киеп бар әнә *(көлеп җибәрә)*. Ферма ишеге төбенә кадәр асфальт юллар, фермага килеп керәсең, ялт иткән чисталык. Шундый зур үзгәрешләр, бер уйласаң, ышанырлык түгел. Яңа техника, яңа технология күрәсе килгән кеше безнең мегафермага гына килсен! Безнекеннән дә шәбрәге, ай-һай, бармы икән?!

Бар анысы. Саба районы фермасында әнә роботлар эшли. Анда сыер савучылар да күренми, сыйфатсыз сөт тә шундук бракка чыгып бара. Ләкин ул, беренчедән, бик кыйммәт, икенчедән, аны инде эшләргә кешең калмаган очракта гына кулланасың. Ә без бит эшче урыннары булдырырга дип тырышабыз, яшьләрне авылда калдырырга азапланабыз. Яшьләр китеп бетсә, фермадагы роботлар белән генә тормышны алып барып, авылны яшәтеп, саклап калып булыр микән? Шунысы да бар бит әле. Дүрт авылны берләштергән Олыяз авыл җирлегендә һәм шушы хуҗалыкка караган Каенсарда халык, иң мөһиме, эш белән тәэмин ителгән.

– Рәхәтләнеп эшлибез, рәхәтләндереп акчасын алабыз, – ди әнә Гүзәлия.

Аена 35–40 ар мең хезмәт хакы алган сыер савучыдан, бигрәк тә әлеге дә баягы мегафермада эшләүчедән: «Тагын кайда эшләр идең?» – дип сорамагыз. Ул эшенә җаны-тәне белән береккән. Гүзәлия шикелле утыз ел эшләп тә, лаеклы хезмәт ветераны булып та, әле тагын шуның кадәр эшләр идем, дип торучылар бер ул гына түгел бирелә. Димәк, хезмәт шартлары, әңгәмәдәшем әйтмешли, коллективта үзара мөнәсәбәтләр, атмосфера әйбәт. Алар инде туганнар шикелле. Бер-берсенең ни белән яшәвен сулышыннан ук белеп-тоеп торалар.

17 яшьтән – фермада

Гүзәлия үзе Түбән Казаклардан кул сузымында – ике чакрым тирәсе арада урнашкан Чишмәбаш авылыннан. Элек бу авыл суган үстерү белән танылган «Коммунизмга» колхозына кергән була. «Чишмәбаштагы бөтен кызлар, бер-бер артлы кияүгә чыгып, Казакларга күчеп бетте», – дип көлә Гүзәлия.

– Башымда укыйм дигән уй булмады. Янныбызда гына ферма, шунда эшкә урнаштым. Башта терлекче итеп алдылар, тора-бара сыерлар сава башладым. Гөжләп торган мондый мегафермалар юк иде ул чагында. Төшеңә дә кермәс андый үзгәрешләр моннан берничә ел элек башланды. Тиз генә башладылар да, тиз генә салып та куйдылар. Җитәкчебез Газинур Хатыйм улы Хәбибрахманов бик кешелекле безнең. Һаман халык өчен тырыша. Эшләгән кешенең кадерен белү, югары эш хакы, ял йортына юлламалар... барысы да аның, бары аның хезмәте ич!

«Әти белән әни бик кырыс иде, алар безне эшкә өйрәтеп үстерде», – дип, яшь чакларын искә алып утырган Гүзәлия ханым, малайлардан калышмыйча, мотоциклга да утырып чапкан. Әтисе белән бергә сенаж тракторында да эшләгән. Шуңадырмы, килен булып төшкән 17 яшьлек кыз балага фермага эшкә килү бер дә авыр сынау булып

тоелмаган. «Эшләгәнең минем өчен булса, өйрәнгәнең үзең өчен», дип үстергән бит аны әнисе.

Гүзәлия белән Илшат Гобәйдуллиннар гаиләсе күпләргә үрнәк булырдай. Уллары Рәдиф белән Рәдил икесе дә Яниль авыл хуҗалыгы училищесын тәмамлаган. Берсе – агроном, икенчесе механизатор белгечлеге алган. Кайчандыр әниләре эштән кайтуга идәнен юып, малларны карап, хуҗалыкта бөтен эшне алып барган малайлар хәзер үзләре өйләнеп, башлы-күзле булганнар. Рәдифе – Казанда, үзе әти инде. Нәни оныгы Ясминәгә Гүзәлия куанып бетә алмый. «Әби булдым инде», – ди ул елмаеп.

Ире Илшат – малларны «Карусель»гә куып кертеп торучы.

– Тыңлыйлармы соң? – дибез.

– Тыңламасалар, Гүзәлиягә әйтәм, дип куркыта ул аларны, – ди хатыны янә көлеп җибәреп. – Бер көнгә өч тапкыр кереп чыгалар бит шул конвейерга.

Илшат сүзне икенче юнәлешкә кертеп җибәрә. Ул авыл кешесенең бүген мул тормышта яшәве, ә моның өчен иң элек, үзеңә тырышырга кирәклеге турында сөйли. Түбән Казаклар авылы балаларының ике чакрымдагы Олыяз мәктәбенә йөрүләре, анда уку өчен бөтен шартлар тудырылуы, юлларның төзек, урамнарның чиста булуы турында горурланып сөйли. «Бездә барысы да халык өчен эшләнә», – дип, хатыны сүзләрен кабатлый.

«Кем җитештерә, шул яши»

«Урал» авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативы җитәкчесе Газинур Хәбибрахманов шулай ди. «Бүген җитештерүче кеше генә әйбәт яши, – ди ул. Һәм тагын, – яңалыктан артта калырга ярамый», – дип тә өсти. Үз тәҗрибәсеннән чыгып әйтә. Яңаны торгызып, менә дигән итеп эшләп күрсәткәннән соң әйтә. Һәм ни өчен тәвәккәлләүләрен дә аңлата.

– Авылда кеше кими, – ди Татарстанның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре һәм башка күп кенә бүләкләр иясе Газинур Хатыйм улы. – Пенсиягә китеп бетсәләр, нишләргә? Эшче көчләрнең кимүе яңа резервлар эзләүгә этәрә. Бу мегаферма безгә 560 миллион сумга төште. Кредит алмадык. Иттән, сөттән, бәрәңгедән кергән акчага салдык. Сыер саву залына җиһазлар алганда акчаның 40 процентын дәүләт түләде. Тагын 30 процент субсидия бирделәр.

Киләсе елга безнең карамактагы «Рассвет» хуҗалыгында тагын бер зур комплекс – мегаферма салырга уйлыйбыз. Хәзер җирне рәсмиләштерү мәшәкате белән йөрибез, – ди җитәкче.

«Урал»лар еллык савым буенча республикада беренче урында. Алар көненә 67 тонна сөт сата. Акчага әйләндерсәң, миллион сумнан артып китә. Әйе, җитәкче әйткәнчә, төзеп куюда гына түгел хикмәт, эшли белүдә, эшне оештыра белүдә.

Мегаферманың үз нәселле таналар үстерү цехы бар. Аена 90 га якын бозау туа икән. Хайваннарны ясалма орлыкландыручы, каплатылган малның торышын УЗИдан караучы белгечләре дә бар аларның. УЗИ аппараты үзе генә дә 650 мең сум тора. Төрле чирләр баштан ук кисәтелә. Кайсыдыр мал бозаулаганнан соң сөт бирүен дәвам иттерә, сөтенең сыйфаты начараеп киткәне иткә китә. Эшне әнә шулай җиренә җиткереп эшләсәң генә ул! 2016 елда илкүләм оештырылган «Алтын көз» күргәзмәсендә алтын медаль алулары да зур вакыйга булган.

Җитәкче турында гел җылы сүзләр генә ишеттек. Сорашмасак та, авыл кешеләре үзләре мактады. «Ярдәм сорап барсаң, борып җибәрми, җаен таба. Санаторийга да җибәрә, акчалата да ярдәм итә», – диделәр. Былтыр ял йортына шушы бер җирлектән генә дә 90 кеше барган. Гаҗәп инде, бер уйласаң. Игелек кылу өчен күп тә кирәкми, нибары игътибар һәм кеше хәленә керү җитә. Ә моны бик сирәкләр эшли. Әйтик, «Урал»ның «Алтын йөрәкле кеше»се кебекләр. Шундый җитәкче булганда алар рәхәтләнеп эшлиләр, рәхәтләндереп акчасын да тоталар. Гүзәлия шулай ди бит әнә...

РЕСПУБЛИКАДА ГЫНА ТҮГЕЛ, ИЛДӘ БЕР



Сергей Димитриев, Кукмара муниципаль районы башлыгы

– Кукмара районында гомер-гомергә авыл хуҗалыгын үстерүгә игътибар аеруча зур булды, һәм ул киләчәктә дә шулай булыр дип уйлыйм. Авыл хуҗалыгын үстерүгә юл куйган күп кенә яңалыклар иң элек безнең төбәктән башланды. Чөнки районда үрнәк булырдай, башкаларны да үзе артыннан ияртә алырдай көчле коллективлар, алдынгы карашлы җитәкчеләр җитәрлек безнең. Бу очракта мин «Восток», «Урал», «Вахитов» исемендәге авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативларын күз алдында тотып әйтәм.

Бүген агропромышленность комплексларын модернизацияләү һәм яңа технологияләр кертү дәвам итә. Бу эшләр беренче булып 2012 елда «Восток» хуҗалыгында – 400 баш мөгезле эре терлеккә исәпләнгән сөт залы булган югары технологияле терлекчелек комплексын сафка бастырудан башланып китте. 2014 елда аның икенче чираты кулланууга тапшырылды. Аннан аларга «Вахитов» исемендәге һәм «Урал» хуҗалыклары кушылды. Заманның иң югары таләпләренә туры китереп эшләнгән мегафермаларның яңаларын сафка бастыру дәвам итә. Алга таба аларга «Рассвет» авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативы һәм «Әсәнбашагро» җәмгыяте дә килеп кушылыр дип торабыз.

Районда тәүлегенә 273 тонна сөт җитештерелә, ә аена ул 8190 тоннага кадәр җитә. Сөт җитештерү күләме буенча Кукмара республикада беренче урында бара. Планнарыбыз зурдан: киләчәктә үзебезне ил күләмендә танытырга, беренчеләр сафына чыгарга иде безгә!

БЕРЕНЧЕ МӘХӘББӘТ

Иртәме-соңмы, ул һәркемгә килә. Аның беренчесе, икенчесе... гомерлеге була. Кемгәдер канатлар куя, үстерә, үсендерә. Ә кемнеңдер йөрәгендә гомерлек яра калдыра.



Лилия ГӘРӘЕВА

Фото: Анна Арахамия

Моңарчы поэзиягә исе дә китмәгән балагыз кинәт кенә шигырь сөяр бер җанга әверелсә, аптырамагыз. Кичә генә чәченең ничек ятуын уйлап та бирмәгән улыгыз бүген аларны юешли-юешли тарый икән, аңа да гаҗәпләнмәгез. Кызыгыз көзге алдында бөтерелеп, үзеннән күзгә күренмәс җитешсезлекләр эзләсә, анысына да шаккатасы түгел. Боларга әле күзләрнең моңсулыгы һәм төне буе телефоннан сөйләшүләр өстәләчәк. Хәтта күз яшьләре дә озак көттермәс. Бу тынгысызлыкларның сәбәбе бер генә – балагыз гашыйк булган!

Барлык әти-әниләр дә шундыйдырмы: улыңның тәүге кат гашыйк булуын – куанып (ниһаять безнең малай да зур үсте!), ә кызыңныкын сагаеп кабул итәсең икән. Югыйсә безнең үзебезне дә кайчандыр үз кочагына бөтереп алып, утларга-суларга салган хис бит ул. Эчтә җилпенгән күбәләкләрне хәтерләгез әле. Аны күрер өчен ашкынганыгызны, аны сагынганыгызны, аерылу сагышларын... исегезгә төшерегез. Искиткеч бер халәт! Гаҗәеп хис! Әмма иңнәргә канатлар куйса гына, куаныч китерсә генә гаҗәеп ул. Әгәр киресенчә булса... Балагыз җавапсыз сөю утында янса? Мәхәббәте аңа газаптан башка бернәрсә дә бирмәсә? «Сиңа әле 15 кенә. Алда, беләсеңме, андыйлар күпме булачак!» – дигән сүзләрегез генә юатмас шул телгәләнгән күңелен.

Тәүге ярату хисләрен күпләр 14–15 яшьләрендә кичерә, тик арабыздан ничәбез генә беренче мәхәббәте белән кавыша алды икән. Беренче мәхәббәтнең бик сирәге генә бәхетле тәмамлана. Күп очракта җавапсыз була ул. Әлегә бернинди тормыш тәҗрибәсе булмаган яшүсмернең бу очракта ниләр кичерүен аңлавы кыен түгел. Ул безгә – янасын янып, көясен көйгән һәм болытлар артында һәрчак кояш булуына инанган өлкәннәр өчен генә бу янулар көлке булып тоела. Бала өчен ул әлегә иң олы һәм бердәнбер сөю. Хисләрен кабул итмәүләре үзе турындагы фикере формалаша гына башлаган яшь кеше өчен трагедиягә тиң. Журналыбызның алдагы саннарында без бу хакта бер язган идек: яшүсмерләрнең үз-үзләренә кул салуы күп очракта нәкъ менә җавапсыз мәхәббәт аркасында була икән. Йөрәк януларын басар өчен, алар кайчак әллә нинди чараларга да бара. Мендәргә капланып елау – иң җиңеле әле.

Исем-фамилиясен бар дөньяга фаш итәргә теләмәсәм дә, үз арабызда булган бер вакыйганы мисалга китерәсем килә. Югары класс кызларының яңа гына институт тәмамлап кайткан укытучыларына гашыйк булуы еш очрый торган хәл. Гөлнурның да (исеме үзгәртелде. – *Авт.*) үз укытучысына – кичәге студентка күзе төшә. Җиденче сыйныфны гына тәмамлаган кыз ике ел буе җавапсыз мәхәббәт утларында яна. Укытучы егет, билгеле инде, әле балигъ та булмаган баланың хисләрен уртаклаша алмый. Әмма аңа карап кына кыз да бирешергә җыенмый: егетне чын-чынлап эзәрлекләргә,

Француз язучысы Виктор Гюгоның кызы Адель җавапсыз мәхәббәт аркасында гомерен психиатрия клиникасында төгәлли. «Адель синдромы» дигән сүз шуннан кереп калган.

хәтта үз-үзенә кул салу белән янарга ук керешә. Бу хәл ахыр чиктә укытучыларга һәм кызның әти-әниләренә дә барып ирешә. Әмма баланың хисләрен тыяр көч таба алмыйлар. «Син аны яратма!» – дип кенә йөрәккә боерып булсачы! Белмим, аннан ни булган, әллә егет үзе артык катырак бәрелгән, әллә әти-әниләреме – ул бала хастаханәгә эләкте. «Тагын ярты сәгатькә соңарсагыз, коткарып калып булмый иде», – дигән табиблар. Бер кап йокы дарусы эчеп бетергән булган. Әле болай гына да йотмаган, тизрәк тәэсир итсен өчен, төеп эчкән. Бүген Гөлнурның да, укытучы егетнең дә – үз гаиләсе, һәр икесе дә бәхетле балалар үстерә. Тәүге хисләрен Гөлнур хәзер үзе дә көлеп кенә искә аладыр бәлки, ләкин ул чакта бик аздан гына фаҗига булмый калган.

Беренче мәхәббәтнең җавапсызы гына түгел, тиң булмаганы да әти-әниләрнең күңел тынычлыгын боза. Кызының тирә-якка хулиган дигән аты таралган егеткә гашыйк булуы яки улының җиңел холыклы буларак бәяләнгән кыз белән очрашуы кайсыбызны гына куандырыр икән. Кызлар күзлегеннән андый егетләр башкалардан кыюрак, тапкыррак булып күренә шул. «Аның белән очрашудан тыям», – дисең икән, яшүсмер үҗәтләнә генә. «Тыелган җимеш татлы була», – диләр бит. Яшүсмерлек чоры – бала алдында әти-әниләрнең авторитеты төшкән чор да бит әле ул. Безнекенә караганда, инде әллә ничәнче егет белән очрашып йөрүче классташ кызның киңәшләре балабыз өчен «ышанычлырак», аның тәҗрибәсе зуррак булып тоела. Әти-әнинеке түгел, дус-иш сүзе үтемлерәк бу вакытта.

Әле менә бу көннәрдә Казанда 15 яшьлек кыз баланы эзлиләр. Берүк исән-сау гына табыла күрсен. Моннан алдарак тагын бер кыз шулай югалган иде. Соңыннан аның яраткан егетенә ияреп китүе ачыкланды. Әти-әниләре аның белән башка аралашмаска кушкач, бала, барысына да кул селтәп, өйдән чыгып киткән. Ул кыз гаиләсенә кайтмый калмас, гыйшкы да узар, ләкин бу башбаштаклыгы өчен нинди хак түләр бит? Ярый ла киләчәгенә күләгә төшермәсә. Әмма күкләргә күтәрергә тиешле мәхәббәт, кайчак канатларны кисеп, гомер сукмакларын әллә нинди караңгы

тыкрыкларга алып кереп чуалта да, язмышларны чәлпәрәмә китерә.

Классташлары кулларына аттестат алганда, безнең күрше кызы кулына беренче баласын алды. Тәүге мәхәббәтенең җимешен хәзер әнә ялгызы гына үстерә. Туган бала үсәр, тик әнисенең дә бу мәхәббәте соңгысы гына булмасын, өч көнлек дөньяда һәркайсыбыз баласына гаилә бәхете тели ләбаса.

Күптән түгел беренче мәхәббәтнең моңарчы күрелмәгән кызык төре – ерактагысы белән дә очрашырга туры килде. 14 яшьлек кызымның Екатеринбургта яшәүче бер малай белән интернет аша язышканын белә идем. Икесе дә бер үк спорт төре белән кызыксына, уртак мавыгулар хакындагы әңгәмәләр тора-бара – дуслыкка, дуслык мәхәббәткә үк үрләгән түгелме. Гомерендә бер күрмәгән дип әйтеп булмый анысы, интернет әллә нинди мөмкинлекләр бирә, әмма гомерендә бер тапкыр янәшәсендә дә утырмаган егет өчен чып-чын сөю утларында яна кызым. Тегесе дә, әллә үртиме, әллә башкамы – үз сәхифәсенә кызлар белән төшкән фотолар урнаштыра. Ул көнне бездә күз яшьләре, баланы юатырга тырышулар...

Балаларыбыз үсәр анысы. Бүгенге газаплары үзләренә дә кысыр хәсрәт кенә булып тоелыр. Күңелләрен каната-каната олылар тормышына әзерләнүләре берүк чыныктырсын гына, сындырмасын иде үзләрен.

Белгеч фикере



Полина МОИСЕЕВА, педагог-психолог. «Доверие» яшьләргә һәм балаларга социаль хезмәт күрсәтү үзәгенең «Сердәш» психологик-педагогик ярдәм бүлеге хезмәткәре

Яшүсмерләрнең беренче көчле хисләре әти-әниләрне дә, укытучыларны да еш кына борчуга сала. Шул ук вакытта яшьтәшләре белән аралашуның алар өчен бик әһәмиятле булуын да онытырга ярамый. Ләкин балаларның үзләре белән бу хакта сүз кузгату җайлы түгел. Әти-әниләрнең әлеге мәсьәләгә мөнәсәбәтле булуы яшүсмернең күңеленә тияргә, яраларга мөмкин.

Күңеленә сөю хисе кергән яшүсмер кайчак башка бернәрсә турында да уйлый алмый торганга әверелә. Баланың укуы начарлану, билгеле инде, әти-әниләрнең котын ала. Беренче тапкыр чиратта укырга кирәген, ә мондый мөнәсәбәтләрнең тормышта әле бик күп булачагын ничек кенә аңлатырга тырышсагыз да, яшүсмер өчен беренче мәхәббәт барыбер үз урынын ала. Балага нинди дер басым ясасагыз, аның хисләрен игътибарсыз калдырырга теләсәгез, әйткән сүзләрегез һәм кылган гамәлләрегез агрессия генә тудырачак.

Улыгыз яки кызыгыз сайлаган кешене, аралашкан дусларын өнәмәвегезне белдерсәгез дә шундый ук реакция күзәтелә. Мондый очракларда әти-әниләр еш кына чикләүләр кертә, бертуктаусыз контрольдә тота. Алай итеп кенә баланы тыңлаучанга әйләндереп, дусларыннан биздереп булмый шул. Киресенчә, аның сезгә булган ышанычы тәмам югалырга мөмкин. Сезнең сүзгә карап кына гыйшкы төшкән белән аралашудан туктамас ул, ләкин инде сездән яшереп эшләячәк.

Әгәр дә балагыз тәүге тапкыр гашыйк булган икән, моңа җитди карарга тырышыгыз. Әйе-әйе, бу хисләрнең әле узгынчы гына булуын, бу газапларның онытылачагын, мондый мәхәббәтнең әллә ничә булачагын белсәгез дә, аның өчен хәзергә моның бик тә мөһим икәнен истә тотыгыз.

Ул мәхәббәт җавапсыз булса да, сайлаган кешесен аңа тиң күрмәсәгез дә, балагыз мөнәсәбәтләрне үзүдән газапланса да, әти-әниләрнең алга таба эш итү планы бертөрле.

Беркайчан да баланың хисләреннән көлмәгез, аларны бер кирәксез нәрсә дип атамагыз. Балагызга үз хисләре, борчулары турында сөйләргә мөмкинлек бирегез. «Нинди мәхәббәт әле бу яшьтә. Синең өчен беренче урында уку», – дип, ярты сүздән кырт кисмәгез. Аның ышанычын тою үзегез өчен бик кыйммәт икәнен төшендерегез.

Сезне нәрсәдер сагайта яки борчый икән, бик сак кына бу хакта сүз кузгатып карагыз. Ул сезнең белән әлегә килешмәс тә, анысына да әзер торыгыз.

Кәефе төшкәнен күрсәгез, шунда ук аның игътибарын башкага юнәлтергә, бу хисләренең әһәмиятен киметергә омтылмагыз. Үз хисләре белән бераз үзе яшәп алсын. Аны аңлавыгызны, хәленә керүегезне белдерегез. Сезгә теләсә кайчан мөрәҗәгать итеп буласын аңласын ул. Кичерешләре артык тирән кебек тоелса, үз-үзен тотышы сагайтса, психологка күренергә күндереп карагыз.

Шунысын да онытмагыз: баланы контрольдә тотуның иң яхшы чарасы – үзара ышанычлы мөнәсәбәттә булу.

Әмма һәрнәрсәдән искәрмә булган кебек, бала актив матдәләр куллануны гадәт итсә, законга каршы килә торган гамәлләр кылса, җәберләргә юлыкса, бу очракта инде җитдирәк чаралар да кулланмый булмый. Болары инде әти-әниләрнең катгый позициясе таләп ителгән очраклар.

ЧЕЛТӘРЛӘРНЕ КЕМ СУЗА?

Кешеләр һәрвакыт үзара мәгълүмат алышкан. Ут, күгәрченнәр, морзе әлифбасы, телеграф, чыбыклы телефон, кәрәзле элемтә, интернет... Алдынгы технологияләр әле моның белән генә дә чикләнмәс. Секунд эчендә дөньяның теләсә кайсы почмагына мәгълүмат җиткерүче әллә нинди технологияләр табылыр. Болар бар да яхшы, әлбәттә. Ләкин шуларны кулланылышка кертү өчен белгечләр дә кирәк әле! Мәгълүмати кабельле челтәрләр белгечләрен киләчәк һөнәре дип атыйлар. Ул – WorldSkills чемпионаты структурасындагы 45 компетенция арасында. Кабель сузуны, үткәргечләр белән эшләүне, гадәттә, ир-ат эше дип күз алларга күнеккәнбез. Тик хәзерге җәмгыять бөтен киртәләрне юкка чыгара. Әлеге белгечлеккә кызлар да килә һәм... кайбер егетләрнең борынына чиертә. Аида ЗӘЙНУЛЛИНА – шундыйлардан. WorldSkills Russia чемпионатында ул әлеге компетенциядә юниорлар арасында беренче урынны алды.

Казан кызы Аида Зәйнуллина 9 нчы сыйныфны тәмамлаганнан соң, укуын урта һөнәри белем бирү йортында дәвам итәргә уйлый. Моны ул вакытын әрәм итәсе килмәү белән аңлата. «Ике еллык мәктәп программасын биредә бер ел эчендә үзләштерергә мөмкин, моннан кала, белгечлек тә аласың», – ди кыз. Россиянең иң яхшы техникумнары исемлегенә кергән Казан мәгълүмати технологияләр һәм элемтә техникумын сайлый. Кызлар арасында әллә ни популяр булмаган телекоммуникацияләр буенча белгеч һөнәренә туктала. Гади тел белән әйткәндә, интернет үткәргечләр сузучы монтажчы. Ләкин хәзерге заман өчен үтә кирәкле һөнәр. Теләсә нинди предприятиенең нәтиҗәле эшчәнлеге бүлекләр арасында мәгълүмат, видеосигналларны тапшыруны тәэмин итү сыйфатына бәйле. Техникумда укый башлагач, WorldSkills хәрәкәте җиңүчеләре хакында әнисенә кайтып сөйли. Мин дә алар арасында булачакмын дигән максат куя. «Анда бит малайлар гына катнаша, син бит кыз бала», – дип, Аиданың әнисе әллә ни әһәмият тә бирми. Ләкин кызының тырышуын күреп, аңа һәрьяклап теләктәшлек белдерә башлый. Ә Аида максатына кыю адымнар белән атлый: башта сайлап алу турын уза, аннан төбәк чемпионатында икенче урын яулый.

Май аенда Казанда узган WorldSkills Russia чемпионатында үз компетенциясендә Аида егетләр арасында бердәнбер кыз була. Ә осталыкта аңа тиңнәр табылмый. Җиңел бирелми аңа ул җиңү. Биш ай буе көне-төне бер ялсыз чемпионатка әзерләнә. «Ташлыйм микән әллә?» дигән уй да килә аңа. Ләкин ярты юлда туктап кала торганнардан түгел Аида! Чемпионатта берничә модуль буенча дүрт көн буе ярышалар. «Акыллы йорт» системасы да ясыйлар, үткәргечләр дә сузалар. Соңгысы иң авыры була: яшерен биремне үтәргә кирәк! Чемпионат кагыйдәләре буенча, андый биремнәрне башкарганда катнашучыларга беркем белән дә сөйләшергә ярамый. Көн буена янындагы дусларыңа бер кәлимә сүз әйтми яшәп кара әле син! Ә таләп бик катгый: бер кеше авызын ачып сүз әйтә икән, бөтен команданы ярыштан төшереп калдыралар. Бу бит Татарстан ышанычын акламау. Иртәдән кичкә кадәр беркемне белмәгән кыяфәт чыгарып йөрергә туры килә. Конкурс көне артта калып, өйгә кайтырга дип автобуска чыгып утыргач та сөйләшеп китә алмый азапланалар әле.

WorldSkillsта катнашып, техникумда булмаган күнекмәләрне үзләштерә ул. «Чемпионат минем өчен кызыклы сәяхәт кебек булды», – дип искә ала. Бик күп дуслар таба, сабырлык, тырышлык кебек сыйфатларны үстерә, тиз генә карарлар кабул итәргә дә өйрәнә. Һәм... эшче һөнәрләр хәрәкәтендә калырга ниятли. Хәзер ул зурлар белән көч сынашырга тели. Югары белем алып, үз белгечлеге буенча чит илдә эшләп карау хакында да хыяллана. Нигә андамы? Чөнки телекоммуникацияләр Кытай, Япония, Корея үсеш алган, һәм мәгълүмати кабельле челтәрләр буенча белгечләргә анда ихтыяҗ бик зур. Аиданың бу өлкәдәге алдынгы технологияләр белән эшлисе килә.



Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА



БӘЙРӘКӘ БИЗӘКЛӘРЕ



Гөлнур САФИУЛЛИНА

– Менә монысы көре дип атала... Станның ике педале бар: берсе – ал көренеке, икенчесе – артныкы... Зөләйха апа, бер җеп ычкынган монда! Тимерен тартканда өзелеп киткән, күрәсең. Төйник... Дөрес кердеме? Нишләп шул арада ычкынган соң әле ул? Хәзер камыт энәсе бирәм...

– Камыт энәсенә җитәме соң, җебең кыска, Тәнзилә. Карале, кирәк бит! Кылычның икенче теше булдымы бу, өченчеме? Әле ярый тиз күрдек...

Ике останың бу сөйләшүен тыңлаганда, мин дә сезнең кебек палас сукканда иң авыры җеп ычкыну (өзелү) дип аңлаган идем. Әңгәмәнең башы гына иде әле. Хәзер беләм: өзелгән җепне ялгаудан бигрәк, башта аны сузу кыенрак. Ялгышсаң, сукканны кире сүтү дә җиңел түгел.

Паласны күбрәк яңгыр яуган, буран булган көннәрдә суга идек.

Бер паласка 40 сум бирәләр иде.







...Бәйрәкә – борынгы авыл. Аның данын еракларга ишеттергән шәхесләрне саный башласам, язмам башка юлга кереп китәр. Бөтен дөньяга билгеле мәшһүр композитор Софья Гобәйдуллинаның да нәсел тамырлары шушы авылга килеп тоташуын гына әйтим дә... (Юлыгыз Ютазы якларына төшсә, Бәйрәкәгә сугылырга, музейларын карап чыгарга һичшиксез вакыт табыгыз!)

Ә палас... Әйе, бу авыл осталары суккан палас та аның матур бер үзенчәлеге! Элек Бәйрәкәгә яучы җибәрүчеләр яхшы белгән: аларда буй җиткән кызлар бирнә өчен палас та әзерли. Зуррагын, кечерәген. Өч чәчәклесен, икелесен. Җете төслесен, караңгырагын... Килен булып төшәчәк нигезенә гомер буе бер ямь биреп торачак, тузуның ни икәнен белмәячәк паласлар! Ә аннан кибетләргә фабрикаларда тукылган келәмнәр кайта башлаган, һәм борынгыдан килгән бу һөнәр кинәт кенә кирәксезгә әйләнгән. Станнар чормаларга күчкән, буяулар – караңгы почмакларга, җепләр – сандыкның төбенәрәк... Тик күз нуры һәм җан җылысы кушып суккан паласлар барыбер башка шул алар! Кибет тулы келәм әнә, ә күңел барыбер боларына күбрәк тартыла. Тик инде бу эшнең тәртибен, җаен белгән осталар гына авылда бик аз калган. Бармак белән санарлык кына... Яңа гына туксан яшен тутырган Зөләйха апа Газизова – шуларның берсе. Әмма шәкерте булмаган остаз остазмыни ул?! Тәнзилә апа Мәрданшина аңардан палас сугуның инде бөтен серләренә дә өйрәнергә өлгергән.

Осталар миңа палас сугу серләрен сүтә. Аны гына да түгел.

Чабата үрүнең дә җае бар

Зөләйха апа: Паласны 7 яшемнән суга башладым. Әлеге дә баягы, инәйгә ярдәмче кирәккә. Педальгә аягым да җитми иде әле... Ач вакытлар бит, бер уч булса да он бирмәсләрме дип тырышу. Укый да алмадым мин. Күршедәге өч чакрымдагы Зирекле Елга авылына бала карарга җибәрделәр. Инәй хәл белергә килсә, җир тырнап, елап кала идем. Сагынганмындыр инде... Бала караган өчен бер ирләр бишмәте, бер күлмәк бирделәр. Инәйнең беренче ире сәнәкчеләр бәрелешендә үлгән, аннан алты баласы бар иде. Икенче әтәйдән дүртәү туганбыз. Бер рәхәт күрмәгән инәй... Өстәвенә, сугыш чыкты. 1943 елны аның инәсен – әбине дә безгә китереп куйдылар. Абый сугыштан яраланып кайтты, эшкә инде яраклы булмады. Ә мин, шөкер, кул арасына иртә кердем. Колхозның бер эшеннән калмадым. Торф чыгарырга да җибәрделәр, Молотовка урман кисәргә дә: 60 кеше барган идек, бар да качып бетте – өчәү генә калдык... Юклык заман. 17 яшемә җитмичә өстемә ситсы күлмәк тә кия алмадым: барысы да киндер иде.

Бәйрәкәдә паласны өй саен диярлек суккан чаклар бар иде. Берсеннән-берсе күреп, өйрәнеп... Хәзер элеккегеләрдән өчәү генә калдык бугай инде: мин, Нәгыймә, Наҗия... Кияүгә китүче кызлар бирнәгә дип суктыралар иде. Идәнгә җәяргә – бертөсле палас, караватка җәяргә – икенчене... Сатып алырга җеп юк иде, аны үзләре әзерләп килә – искергән кием-салымны сүтеп. Элеккеге әйберләр искерсә дә, тузмый, нык була иде. Үзебез шуларны төрле төсләргә мана идек. Буявын Ташкенттан алып кайтып саталар. Әмма ул паласларны юып булмый, уңа иде. Мин кияүгә чыкканда инәй миңа җиде аршынлы – аны шулай сөйлиләр – палас сугып бирде. Сәкегә җәяргә дип. Йон җебе юк, чүбектән суккан иде: андыйга утырган саен кадаласың.

1951 елны килен булып төштем. Бианай чирле иде инде, сукыраеп, урын өстендә 8 ел утырды. Биатай аннан калып 7 ел яшәде. Аның тутасы Маһинурәттәйне бианайны карарга алып кайткан булганнар. Ире сугышта үлеп, бер кызы белән тол калган иде: шул кайтудан ул бездә яшәп калды. 45 ел бергә гомер иттек. Шулкадәр тату яшәдек! Улымны, Илгизәремне югалткан көнне дә

Хәзер кызлар бирнәгә палас алып бармый. Алай да оныгыма: «Кызым, берәр җиреңә җәярсең», – дип, икене сугып бирдем әле.

янымда Маһинурәттәй булды. Табиб иде улым. 30 яше тулып бер атна узгач, авариягә очрады, ике баласы калды... Алтын күк баланы илттек тә куйдык шулай итеп. 67 яшьтә булыр иде менә. Улым 19 яшенә җиткәндә генә кызым Илсөярне таптым – алар тәрбиясендә яшим хәзер. Хәер, үзем дә тик тормыйм әле. Ике көнгә бер аш пешерәм, бәйләү бәйлим... Ел саен Картлар һәм Балалар йортларына бишәр кием оекбаш бәйләп җибәрәм. Аннан – туганнарга... Элек бик михнәтле яшәсәм дә, уфтанмыйм. Бүгенгемә бер түгел, мең шөкер...

Балалар үскәндә дә палас сугуны ташламадым. Элек җәй буе гектар-гектар чөгендер эшкәртә идек. Көзгә өчәр гектар бәрәңге казыйбыз. Казыйбыз да, чүпләп машинага да тутырабыз – куллар ничек чыдагандыр... Төшке ашка өйгә кайтам. Түтәй инде әзерләп, салып куйган була. Тиз генә ашыйм да, стан артына кереп утырам... Сәгате җиткәч, тагын чыгып чабам.

Яңа балтасап куйдым дип, искесен еракка атма

Тәнзилә апа: Бианай мәрхүм булды да, кире төп нигезгә яшәргә кайттык. Ике катлы колхоз йортына чыгып киткән идек. Хәзер стан торган менә бу урында бианайның караваты иде. Ә караваt кырыендагы стенага палас эленгән...

Зөләйха апа: Тәнзиләнең биеменә – Нәсимәгә ул килен булып төшкәндә мин сугып биргән палас бу. Аңа инде 40 ел!

Тәнзилә апа: Әйе, күптәнге палас... Аның урынына яткан саен, паласны өйрәнәм. Моны ничек сугарга була икән, дим. Аннан кәгазь алып, бизәкләрне санап шунда төшерә башладым – схемасын ясадым. Тик сугу тәртибен барыбер эшли башлагач кына аңладым. Зөләйха апа күршедә генә яши югыйсә, тик аннан кереп сорашырга һич башка килмәде.

Зөләйха апа: Минем станны турап утка яктык шул... Тагын палас сугармын дип кем уйлаган?! Габдрәфыйк бабагыз үзе ясады аны. Бер эшләмәгән эше юк иде: кулы белән киле генә төймәде... Пенсиягә чыккач: «Булды, җитте!» – дип туктатты. Алар да туйгандыр. Кечкенә генә өйдә шактый урынны ала бит ул стан... Станның кылычын да, көресен дә үзе ясаган иде. Ә тешен бамбук агачыннан ясыйлар. Тарак теше шикелле була ул – җеп шуның арасыннан йөри... Монысы тузган җиргә икенчесе булыр дип, тагын бер уч кылыч ясап, өй кыегына менгезеп куйган идек. Янында ун төрле ун кап буяу да бар иде. Торалардыр, кая китсен, шунда яталардыр...

Алтынны оста суксын

Зөләйха апа: «Балаларны өйрәтә алмассызмы?» – дип, ул вакыттагы авыл советы рәисе Рәис Габдрахманов килеп чакырды. Нәгыймә бармады, мин ризалаштым. Булышырга Әлфия Шәриповага куштылар. Берүзең генә эшләп булмый аны – мәшәкате күп. Тик Әлфия авырып китте дә, эш бераз туктап торды. Бактың исә, күршемдә генә яшәүче Тәнзиләнең дә дәрте булган икән менә... Ул килеп кушылды. 2013 елның ноябреннән бирле бергә эшлибез. Урыссудан, «Иҗат йорт»ыннан заказ килеп тора – без сугып торабыз. Тәнзилә барысын дәфтәргә язып бара: 200 ләп палас суктык инде. Башта музейда суктык. Кышкы суыкларда өсне дә салмыйча эшләгән чаклар булды.

Тәнзилә апа: Грант оттылар да, мәктәпкә фабрикада эшләнгән 15 станок алдылар. Кызларга палас сугу серләрен технология укытучысы Рәмзия Дәүләтханова өйрәтә хәзер. Безнең ул станнарга утырып караган юк әле – өйдә генә эшлибез. Бу станны безгә, музейдагысыннан күчереп, кодам ясап бирде.

Намазлыкка җылы, диләр безнең паласларны. Кубрәк буләккә алалар. Кояшта әллә күпме ятса да, уңмый, тузмый, юганда төсе чыкмый. Басылып утырып эшләсәң, бер атнада бер палас бетереп була.

Зөләйха апа: Яңа палас башласак, көн дә киләм Тәнзиләләргә. Бер килгән көе дип көне буе утырам. Эшләмәсәм, авырый башлыйм мин... Кул көче кирәк монда – җеп тыгызлансын дип гел кагып барасың. Ялгышсам: «Тәнзилә!» – дип кенә кычкырам. Ул шунда ук аңлый...

Тәнзилә апа: Гипнозлый палас сине! Стан артына бер утырсаң, бөтен дөнья онытыла. Өй эшләре дә, ашау да... Быелтыр чебиләр дә алмадым. Зөләйха апа иртән сигездә килә, кичке дүрттә китә. Ул, сөбханалла, нык әле, күзлек тә кими. Таң белән, кәтмән тотып, бакчасын әйләнеп керергә дә өлгерә. Ул киткәч, төнгә таба мин утырам. Сыерны савып, сөтне әйләндереп, сепаратны югач кына...

Үлчәүсез чабата да тукый алмассың

Тәнзилә апа: Паласның киңлеге кылыч тешенә карый. Безнеке 80 сантиметрлы менә. Шуннан озынрак таяк куеп караганыбыз юк. Сугарга калгач, берние юк аның – әкренләп утырасың. Анысын бер генә кеше дә эшли ала. Иң кыены – җепне сузу. Кылыч белән көрегә җеп кертүне ялгызың берничек эшли алмыйсың: аны бик дөрес алып барырга кирәк. Ишекне биклибез: җеп сузганда берәр тискәре, авыр аяклы кеше килеп керсә, ялгышмыйча калмыйсың. Шуңа күрә ишекне

берәүгә дә ачмыйбыз... Өй иркен булса, бер буйга гына да барып булыр иде дә. Идәнгә җиде кадак кагабыз. Минем бабайны да (ирем Кәшифне диюем) бусагага утыртып куябыз – ул миннән җепне алып тора. Зөләйха апа белән без арада йөрибез. Кылычта ничә теш булса, шул кылыч санынча җеп сузарга кирәк. Ә безнең станда 185 теш... Әби белән икәү тезләнәбез дә, идәнгә кара-каршы ятып, җеп саныйбыз. Икешәр-өчәр мәртәбә! Җеп кадактан чыгып очмаска тиеш әле.

Зөләйха апа: Энә белән кое казу кебек бу... Ул көн шушының белән генә үтә...

Тәнзилә апа: Җепне идәндә сузганнан соң, мин станның – эченә, Зөләйха апа суга торган урынга утыра. Җепне икешәр-икешәр итеп аның бармагына эләм. Ул тартып ала да, ал күрә белән арт күрәгә кертә... Үзең тотынып эшләп карамыйча, аңларга авыррак, әлбәттә.

Зөләйха апа: Бисмилләһир-рахмәәнир-рахиим... Менә шулай итеп кагабыз... Менә шушылай итеп кыстырабыз... Сукканда да гел санарга кирәк, югыйсә хәзер ялгышасың. Буталудан куркып, эшләгәндә сөйләшмибез дә. Башка бернәрсә хакында да уйлый алмыйсың: ялгыштыра. Ялгыштыңмы, аннары инде сүтәргә кирәк. Суккан паласны кире сүтү – үлем! «Сүтмик», – дип сукранам Тәнзиләгә.

Тәнзилә апа: Унар сантиметр кире сүткән чаклар бар. «Безнең хатаны башка буыннар кабатлар бит аннары», – дим Зөләйха апага.

Юкәне әзерләмичә, чабатага керешмә

Тәнзилә апа: Җепләрне Октябрьскига барып, андагы кибетләрдән эзлим. Кайберләрен Урыссу базарыннан алам. Бер баруда гына сиңа кирәге булмый әле аның... Паласка «полушерсть» әйбәт. Гел матур төсләр генә сайларга тырышабыз: зәңгәр, сыек яшел, кызыл, сары... Җирлеген төрле төсләрдән эшлибез. Әбигә кара төс ошый, ә миңа – чия төсе, зәңгәр төс. Үлчәүле җепнең төрлесе төрле авырлыкта – чамасын белү кыенрак: йә артык кала, йә җитми. Эшләр өчен йомгаклы җеп җайлырак. Ике чәчкәле бер паласка 10-11 йомгак җеп, җирлегенә – тагын 2-3 йомгак «ирис» җебе кирәк. «Палас тыгыз, нык булсын», дип, Зөләйха апа чит-читләренә җепне икешәр кат кыстыра. Бер палас икенчесен кабатламый дип әйтә алмыйм, кабатлый, әлбәттә.

Ислемай сатучы янында исе йогар

Тәнзилә апа: Тузаны бар инде, әлбәттә. Гел идәнне сөртеп торам. «Тузан сулап ятасың, бөтен сәламәтлегеңне бетерәсең, – дип сеңелләр ачулана. – Нигә кирәк бу паласлар сиңа?» – диләр. Ә минем эшлисем килә! Өйрәндем дә, туктый алмыйм менә.

Зөләйха апа: Тузаннан үлсәләр, әллә кайчан мин үлгән булыр идем. Минем эшләүгә?! Пычрагы кайчагында төшәрлек була иде.

Тәнзилә апа: Кибет җебеннән аның кадәр тузан коелмый. Ә менә сарык йонынннан шактый чыга.

Җәүһәр кадерен җәүһәрчеләр белер

Тәнзилә апа: Караватөстенә җәяргә дип бәйләгәндә, ике палас бәйләп, уртадан тегеп кушабыз. Тоташтыру да – бик катлаулы эш. Паластагы бизәкләрнең икесен бергә кара-каршы китерү кирәк. Җеп тигез булмаса, моны ничек эшлисеңме? Каршы якта җеп нечкә икән, бу ягын ике яки өч итеп китәсең.

Башта һәр паласның схемасын дәфтәрдә эшлим, санап чыгарам. Дәфтәрдәге бер шакмак – 2 сантиметрга тигез. Бик иске бер палас алып килгән иде Зөләйха апа. Күзләрен санап, аны да дәфтәргә төшердем. Орнаменты борынгы аның – башкорт ягыннан кергән бугай. Безгә алар ерак түгел бит.

Зөләйха апа: Юк, бу паласка көя төшми. Кышын селкеп, кагып керәбез, карда аунатабыз... Үзең суккан паласны танымыйча?! Таныйбыз! Яңа паласларда төен бик сирәк, юк диярлек. Төен керсә, гел күңелсез була бит...

Тәнзилә апа: Кызым инстаграмда миңа бит ачкан. Үзем белмим дә... «Бөтен кул эшләреңне шунда күрергә була, әни», – ди. Карап кына сокланмасыннар, өйрәнеп тә калсыннар иде – иң зур теләк шул.

Ютазы районы.



Фото: Анна Арахамия

«Сибелә чәчәк» яңгырый. Гөл чәчәкләре, искән җилләр, сагынулар... Күңелнең әллә кай кыллары өзелеп киткәндәй була. Җырчының мелизмнарга бай көчле лирик сопрано тавышы, үзенчәлекле тембры җаннарны иркәли. Тагын, тагын җырлавын көтәләр. «Зиләйлүк», «Тәфтиләү», «Сакмар су», «Таң атканда», «Кар суы»... Үзәкләрне өзә җырчы! Кара бәрхет күлмәге, калфагы ничек килешә үзенә. Затлы! Чибәр! Күпләр күңелендә кабатланмас урын алган Разия Тимерханова ул! Бары Разия Тимерханова гына озын халык җырларын әнә шулай оста башкара алган.



Эльмира ЗАКИРОВА



«АККОШ КЕБЕК АК ПАРОХОД...»

Минем җыр дөньясына исә Разия Тимерханова «Ак пароход»ы белән килеп керде. Ашкынулы, сагынулы-көтүле, бераз вальс, бераз фокстрот-ка бөтереп алып кереп китә торган. Сара Садыйкова ул шлягерын Разия Тимерханова өчен махсус язган диләр... Минем өчен ул үзе дә – аккош кебек, ак пароход кебек.

Разия Тимерханова... Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленең чишмә башында торган затлы җырчы. Татарстанның атказанган артисткасы. Ансамбльнең беренче һәм кабатланмас солисткасы. Александр Ключарев, Мансур Мозаффаров, Заһид Хәбибуллин, Җәүдәт Фәйзи күп вакыт халык көйләрен нәкъ менә Разия Тимерханова тавышы мөмкинлекләрен күздә тотып эшкәрткән. Аның репертуары җырчы үзе эзләп тапкан, баянчы Рокыя Ибраһимова архивында сакланган халык көйләреннән һәм композиторларыбыз җырларыннан торган. Соңгы вакытта яшь җырчылар халык җәүһәрләренә ныграк игътибар итә башлады. Ә ул җырларның күбесендә Разия апа аһәңе, Разия апа бормалары, Разия апа ремикслары. Менә нинди талант булган ул!

Бу талантлы җырчы инде арабыз-дан китсә дә, җырлары һаман йөрәк түрендә. Аны шәхес буларак ача торган матур сыйфатлар – истәлекләрдә, хатирәләрдә.

Разия апа татар халык җырла-рына яңа сулыш өргән, диләр. Мин «Үзгәреш җиле» проектын искә төшердем. Аның да макса-ты – милли аһәңнәрне саклап, татар җырының мөмкинлекләрен ачу бит. Һәм әлеге проектның продюсеры, төп оештыручысы Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры директоры Рәүфәл Мөхәммәтҗановның Разия Тимерханова улы икәнен дә искәртсәк... Димәк, ул «Үзгәреш җиле» фестивале белән берникадәр әнисен дә кабатлый кебек... Көнелдә сорау арты сорау туа. Разия апа нинди гаиләдә үскән? Үзенең гаилә тормышын ничек көйләгән? Нинди әни булган? Җырчыны замандашла-

Ул татар халык җырларын интерпретацияләү белән танылa, ягъни аларга яңа сулыш бирә, яңача яңгыраш сала.

ры ничек итеп искә ала? Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленә ничек килгән? Кайсы композитор-лар белән якыннан аралашкан?..

Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстанның атказан-ган сәнгать эшлеклесе, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреа-ты Рәүфәл Мөхәммәтҗанов истәлекләре Разия Тимерхановaны безгә тагын да ныграк якынайта, аның зур талантына, халкыбызның сөекле җырчысы булуына кабат инанасың.

«Башка андый җырчы булмаган!»

Опера һәм балет театры директорының бүлмәсендә татар җыры, җыр һәм бию ансамбле, аның беренче солисткасы Разия Тимерханова турында сөйләшеп утырабыз. «Үзгәреш җиле»ндә яңгыраган «Сибелә чәчәк»тән Разия апа аһәңнәрен табарга тырышабыз.

– Элек татарда булмаган бит җыр-бию ансамбле, – дип, сүзен ерактан башлый Рәүфәл Сабиро-вич. – Шул ук «Каз канаты»н түгәрәк уеннарда, аулак өйләрдә җырлаганнар анысы. 1937 елда Дәүләт җыр һәм бию ансамбле оешу исә татар халкының мәдәни тормы-шында зур вакыйга булган. Мәскәү консерваториясен тәмамлаган Зөләйха Әхмәтова ансамбльне тудырган кеше, ул ансамбльнең җитәкчесе. Бик энергетикалы, кыяфәте белән Фаина Раневскаяга охшаган, теш арасына «Беломор» папиросы кыстырып кына сөйләшә. Аннан куркалар да иде... Бүгенгә килеп җиткән татар халык җырларының төп классикасын Зөләйха Саттаровна булдырган. Ә ул кемгә таянган, дисезме? Әлбәттә, әнигә! Башка андый җырчы булма-ган! Аның статусын чамаларга була инде шуннан! Ул – ике музыкаль белеме булган бердәнбер җырчы! Казан музыка училищесында пиа-



Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле. Уртада – солистка Разия Тимерханова.

Аны үзара «Сәйдәшев әсәрләрен иң оста башкаручы кыз» дигән титул белән йөртә башлыйлар.



Сабир Мөхәммәтҗанов белән Разия Тимерханова уллары Рәүфәл һәм Фирдүс белән. 1953 ел. Фото: гаилә архивыннан.

нист һәм вокалист дипломы алган. Ә кайбер җырчылар нота да белми... Әни минем бөтенләй башка...

...Разия Тимерханова турында укыганнарымны искә төшерәм.

Александр Ключарев, Мансур Мозаффаровлар халык җырларын ансамбль өчен эшкәртәләр. Бу җырларны башкару өчен әзерлекле җырчылар кирәк була. Солтан Габәши музыка училищесының вокал бүлегендә укучы 19 яшьлек Разияне күреп ала һәм үзе белән ансамбльгә алып килә. Башкаларның белеме булмый. Разия Тимерханова – иң беренче солистка. Аның эчке әзерлеге, потенциалы зур була!

1918 елда Казанда музыкаль гаиләдә туа. Әтисе Дәүләтша – «Зингер» тегү машиналарын төзәтүче оста. Әнисе Гыйззениса – курай, кубыз, гармунда уйнап, тирәюньдә дан тота. Моңлы итеп җырлый. Дүрт бала арасыннан бигрәк тә Разия музыкага сәләтле булуы белән аерылып тора. Мәктәпне тәмамлагач ул, беркемгә бер сүз әйтмичә, Казан музыка училищесына имтиханнар тапшыра. Пианист Мария Пятницкая талантлы кызны үз классына чакыра. Разия бик мавыгып укый. Хорда җырлау аңа аеруча ошый. Ул вакыт өчен сирәк очрый торган хәл: Разиягә параллель рәвештә хор бүлегендә дә укырга рөхсәт итәләр. Опера җырчысы, заманында Шаляпин белән чыгышлар ясаган Екатерина Ковелькова кызга вокал дәресләре бирә.

«Ак пароход» җыры әтигә багышланган»

– Әйе, әйе! «Ак пароход»ны әни моряк ире Сабир Мөхәммәтҗановка багышлап җырлый! «Ак пароход алып китте иркәмне еракларга...» Әти 1939 елдан 1949 елга кадәр Владивостокта, Тын океан флотында хезмәт иткән бит. Ул флотка 1939 елда китә. Әни көтә, еллар буе көтә! Сара Садыйкованың Гөлшат Зәйнашева белән иҗат иткән «Ак пароход» җыры әнине күздә тотып, аның тавышы өчен язылган. Тагын шунысы да бар әле: әтием Сабирның абыйсы Галимҗан да флотта хезмәт итә! Әни, яратып, «минем мореходларым!» дип йөртә аларны. Иң кызыгы – абыйлы-энеле Галимҗан белән Сабир ике бертуган кызга – апалы-сеңелле Мәрзия белән Разиягә өйләнә!

Шундый бер истәлек. Әни Владивостокка берничә көнгә ансамбль белән гастрольләргә бара. Поезд Владивосток вокзалына килеп туктый да, артистларны төшереп калдырып, запас юлга күчә. Әтигә корабльдән ничек чыгарга туры килгәндер, командирлары ничек җибәргәндер... Ә әнине барыбер эзләп таба! Очрашалар... Озын буйлы, хәрбиләрчә төз, матур кеше иде әти. Әнине бик ярата иде! Җырчы буларак әни үзен тулысынча ача алсын өчен, бөтен эшне башкарды ул. Ашарга да әзерли, мине һәм энем Фирдүсне дә карый... Шәһәр партия комитетында бик җаваплы эштә эшләсә дә, гаилә дип җан ата иде. Әни әти ышыгында үзен һәрчак бәхетле хис итте...

...Мин Разия Тимерханованың музыка белгече Зәйнәп Хәйруллинага әйткән сүзләрен искә төшерәм: «Зәйнәп, мин бәхетле хатын-кыз. Ныклы гаилә, шәп егетләр, яраткан ир, халкымның сөекле җырчысы...»

«Гастрольләр, гастрольләр...»

– Әни ансамбль белән бөтен Советлар Союзын иңләде! Кавказ, Урта Азия республикалары, Мәскәү, Ленинградлар... Өчәр-дүртәр айга чыгып китәләр... Әнинең гастрольләрдән кайтуын ничек көтә идек! Безгә киемнәр, уенчыклар алып кайта. Үзбәкстаннан алмалар, Мурманск, Архангельскидан балыклар алып кайтканы истә... Поезд килә дигәч, платформага чыгып басабыз. Иң башта кара паровоз күренә, анда Сталин барельефы... Акрынаеп, вагоннар уза башлый. Әни инде вагон тәрәзәсеннән каршылаучыларны барлый, күзләре белән безне эзли. Никадәр сагыну, ярату ул күзләрдә... Хәтергә нык уелып калган шулар.

Мин 5 нче классны бетергәч, әни икебезне дә үзе белән гастрольләргә алды. Кайбер авылларда күңелле, балык та тотабыз. Ә кайбер авылларда кандалалы өйләрдә дә йокларга туры килә. Грузовик әрҗәләренә утырып, бер авылдан икенчесенә күчәбез. Әни бик җайлы, әйбәт энергетикалы кеше иде.

Ул барында сүзгә килүләр, конфликтлы хәлләр гел булмый иде. Ул шундый юмористка әле, җитмәсә! Компаниянең җаны. Рәхәтләнеп көлә, шаярта, мәзәк сүз сөйли. Күп укый иде. Спорт ярата. Бик тә сыгылмалы гәүдәле. Теләсә нинди биеклектән суга сикерә ала. Шәп йөзә. Оптимист.

...Ансамбль ветераннары сөйләгәннәрдән дә Разия апа чая, шат күңелле булып күз алдына килә.

«Салкын клублар, артистлар үзләре мичкә ягa. Электр юк, лампа яктысында җырлыйлар. Юлданиләр генә булмый! Вагоннар рельстан чыккан, автобус әйләнгән чаклар... Сугыш ахырында Урта Азиягә озак гастрольләргә җибәрәләр. Әйберләрен атларга, сыерларга асып, үзләре авылдан-авылга җәяү атлый. Берсендә, ат булмагач, үгез бирәләр. «Үгез – кире хайван, колагын кытыкласаң гына кузгалып китә», – диләр. Артистлар шулай эшли дә. Үгез күзе тонып чаба – Разия ташлы юл читенә очып барып төшә... Кич концерттан соң сызланып чыга. Кайчак төннәрен улларын сагынып елаган чаклары да була... Ул бик ярдәмчел иде. Ансамбльгә килгән яшь кызларны ничек киенергә, сәхнәдә үзен ничек тотарга өйрәтә. Ятим балаларны бик кызгана. Аларны концертка бушлай кертә. Халык аны бик ярата иде. Коллегалары ничек үз иткәнне белсәгез!.. Ул аларны берләштерә белде. Ансамбль өчен кирәк булган калфак, кәләпүшләр кибетләрдә сатылмый әле ул чакта, әбиләр сандыкларында гына саклана. Ә алар күңеленә һәм сандыгына ачкыч табуны Разия булдыра менә! Татар авылларыннан алып кайткан милли киемнәр, онытылган җыр-көйләр аеруча кадерле була. Разия аларны үз репертуарына кертеп җибәрә. Үткен сүзе, шук-шаянлыгы белән артистларның күчмә тормышын җиңеләйтә дә белә: йә кинәт прическасын япончалаштырып, юлдашларына Пуччининың Чио-Чио-сан ариясен җырлап күрсәтә; йә кулына тальян алып, авыл егетләре кебек гармун күрекләрен киереп, күңелле бию көен сыздырып җибәрә.

«Ул бик матур иде!»

– Әни... Ул шулкадәр акыллы хатын иде. Беркайчан да ачуланганын, кычкырганын хәтерләмим. Бездә күпләр җырлый. Мин үзем дә шул мохиттә үстем. Җырлыйм. Әни белән гастрольләргә йөргәнем булды, музыка мәктәбендә укыдым. Күп уйнадым – зур оркестрларда, вокал-инструменталь ансамбльдә... Джаз музыкасы белән мавыктым, «Битлз»ны күзәтеп бардым. «Антология Казанского рока» дигән китап бар. Анда минем турыда: «Рәүфәл Мөхәммәтҗанов – аранжировщик-клавишник», – дип язылган... Хәтта Мөслим Магомаев Италия партизаннары җырын башкарганда – ул Казанга 1968 елда Азәрбайҗан сәнгате көннәренә килгән иде – Спорт сараенда аңа кушылып уйнап торганым бар... Вадим Усманов, Ренат Ибраһимов, Рәшит Абдуллин, виртуоз-гитарист Арион Рәхмәтуллиннар белән аралашып, иҗат итеп, «Волга» халыкара лагеренда яшьләр өчен төрле чаралар үткәреп йөргән чаклар... Ә әни минем бу вакыйгаларда кайнавымны һәрчак күз уңында тотты, киңәшләрен бирде. Музыка дөньясына тартылуым әнидән киләдер. 5 нче класста укыганда фортепианода уйнавымны радиога яздырдылар. Математик класста укыдым. Әни ата-аналар җыелышына килә иде. Аңа инде гел сокланып карыйлар! Ул гел игътибар үзәгендә. Балалары өчен бик мөһим икән әти-әнисенең шундый булуы. Ул бик матур иде! Күлмәге дә, туфлиләре дә, прическасы да...

Менә бу альбомында татар җырлары гына түгел. Ул классиканы да яхшы белә: анда ноталары белән арияләрдән өзекләр язылган. Европа, рус композиторлары әсәрләре. Чайковскийның «Соловушка»сы... Опера театрындамы, филармониядәме – бер «капустник»та әни Чио-Чио-санның төп партиясен татар мелизмнары белән җырлап, бөтенесен таң калдыра. Ул бар яктан да талантлы иде. Шигырьләр дә яза. Теле искиткеч бай. Гөлшат Зәйнашева, бер сүзен дә төзәтә алмыйм, бар да урынында, ди. Татарстан радиосының позывное булып киткән «Туган җирем Татарстан»ны беренче башкаручы да – әни. Ул аны Мәскәүдә, «Голубой огонек»та җырлый. «Үзгәреш җиле»н дә шул җыр белән башлап, шуның белән тәмамлыйбыз... Масштабы бик колачлы, офыклары киң иде әнинең.


Башкалар да аны яратып, сагынып искә төшерә:

«Разия апа королева кебек иде! Үз-үзен тотышы аристократларча. Зәвык белән матур итеп киенә. Хулиганланып алулары да матур, килешле килеп чыга. Ул башкалар өчен йолдыз кебек иде. «Кар суы», «Зөбәрҗәт», «Сибелә чәчәк»ләрне бүген дә җырлыйлар. Ә бит ул җырларны халыкка беренче тапкыр җиткерүче Разия апа иде!»

Разия Тимерханова пенсиягә киткәч тә, ансамбльдәгеләрне өенә җыеп, импровизацияләнгән җыр кичәләре оештыра әле. Җырлар яздыра, концертларда чыгыш ясый. Бик нәзакәтле, артык әдәпле, игътибарлы булуы аның тәрбиялелегеннән, зыялылыгыннан киләдер. Саксыз сүз әйтеп, кешеләрнең хәтерен калдырудан да курка ул. Аны радиога художество советына әгъза итеп чакыралар. Бик профессиональ бәя бирә. Һәм һәрчак: «Мин артыгын әйтеп ташламадыммы?» – дип сорый...»

Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында «Сибелә чәчәк»не тыңлый-тыңлый, атаклы җырчы Разия Тимерханова турында кадерле истәлекләрне барлап утырабыз. Рәүфәл Мөхәммәтҗанов өчен ул бөек җырчы гына да түгел. Бик кадерле, газиз кеше. Кызлары Сәйрән белән Зарема турында сөйли башласа да, сүз «Үзгәреш җиле» проектына күчсә дә, һаман Разия Тимерхановага сагынуга кайтып кала.

– «Таң атканда», «Сибелә чәчәк», «Зиләйлүк», «Сакмар»... Бу җырлар гел әни тавышы белән күңелдә яңгырый... Күп нәрсәләрне аннан сорыйсым, аның белән киңәшләшәсем килә. Космос белән элемтә бардыр дип уйлыйм. Әни мине ишетәдер кебек...



Зиннур Мансуровның иҗаты гаҗәп киңкырлы! Нечкә хисле лирик шагыйрь фәлсәфи, публицистик шигырьләре, мифологик образлары, милли тарихка кагылышлы кыю фикерләре, афоризмнарга корылган кыска шигырьләре белән укучылар күңелен яулады. Күпьеллык тикшеренүләр нәтиҗәсендә язылып, рус һәм татар телләрендә басылып чыккан «Тукай белән әңгәмәләр»е исә әдәбият тормышында зур вакыйга итеп бәяләнде. Анда төрле әңгәмәләр аша татар дөньясына кагылышлы заманча сорауларга җавап табарга була. Шагыйрьне зур юбилее белән котлыйбыз һәм игътибарыгызга өр-яңа шигырьләрен тәкъдим итәбез.

Зиннур МАНСУРОВ

ДӨНЬЯ КАЯ ТАБА БАРА СОҢ?

Серле сәйях

Кальбең яхшы хәбәр көткән чакта,
аһ, бу вакыт шундый тын ага, –
ерак юллар үтеп кайткан төсле,
сабый бала килә дөньяга.

Пырылдаша тәрәз пәрдәләре,
гүя галәм кичәр ал җилкән.
Тәүге тапкыр аһлап куя бәби –
озын сәфәр тәмам алҗыткан.

Үзе җитди, әллә инде безгә
нидер тапшырырга ант эчкән.
Аннан... җәннәт исе аңкып тора –
әйе, ул чынлап та алыстан!

Түбән төшеп йөзә каурый болыт,
әйтерсең лә күкләр саярган.
Ять-яшь затны лаек юньгә кертеп,
чәбәләнә тәндә сәйяр җан.

Сөембикә манарасы

Бәгъзе затлар, авып китә калса,
диеп,
юкка алдан төрле-төрле уй корган, –
манараның нигезенә,
мәрмәрташтай,
кан-яшь, моң-зар дуен булып
утырган.

Көләч йөзле ясинчылар нигә һаман,
авышкан, дип кычкырыша
бар көчкә?
Сөембикә манарасы тоташкандыр
фәрештәләр йөри торган баскычка.

...Алла белсен, әллә юри,
әллә чынлап
тама анда инде тагын кем яше?
Юк, манара төп-төз килеш
басып тора,
кыегаеп киткән бары дөньясы.

Коръән-хафиз

Бисмилләәәһир-рахмәәәнир-
рахииим.

Коръән ятлый угыл ялгыз гына,
ризалыгы өчен Алланың;
түгелгәндәй була күңеленнән
әллә шатлык хисе, әллә моң.

Ниятләгән сүрә аятьләрен
хәтеренә бикләп барганда,
әллә ничек истән чыгып тора
фани дөньядагы бар гамь дә.

Җаны өчен җайсыз рәвеш алган
манарасы килә зир-зәбәр.
Зиһнен ачып кергән һәрбер сүздә
хикмәт нуры сеңгән энҗе бар...

Ять-яшь башы кинәт чатнап куя,
дәррәү чәнчегән күк мең инә, –
бөтен галәм агып керә төсле
йодрык кадәр генә миенә.

Аслын аңлап ятлый откыр угыл,
сокландырып сыный Хак юлы.
Мөкатдәслек тулы могҗизаны
сыйдырырмы адәм гакылы?!.

Бәгырь өнен якты моңга төреп,
үзалдына хәтем кылганда,
тагын пакьлек аша үтә кебек
ана сөте белән кергән дә.

Укып киткән һәрбер хәреф саен
насыйп итәр аңа ун әҗер.
Талибанә күккә таянганның
исәп тоткан эше уңадыр.

Ул кальбенә уйгач әл-Китабның
ахыргача утыз парәсен,
килеп басар мең дә утыз сөаль:
дөнья кая таба бара соң?..

Гарше әгъляэ күрми сабак аша
фашлап күрсәтәдер барсын да;
Җиргә вәхи булып иңгән хөкем
кайнап тора ять-яшь башында.

Коръән ятлый угыл ялгыз гына...

Ихласлык фаҗигасе

Яңа елда җанвар булып
киенгән нәни улын
сөйде ана: «Тик бел шуны:
битлек астында – уен...»

Балигъ яшьтә балга баргач,
бәлагә тарган улын
аяп, ата: «Нык тор, – диде, –
битлек астында – уен...»

Ике йөзле дөнья белән
пәрмә-пәр килгән улын

дәште күкләр: «Син кал өстен –
битлек астында – уен...»

...Сынчы килеп йөзлек алгач*,
яд кылып Адәм улын,
көлде иблис: «Бар, кит аңлап:
битлек астында – уен,
битлек
астында –
уен...»

Аһәңдәшлек

Оркестрның сихри аһәңеннән
йөрәк ялкынланып, җан эри.
Тәмам оеп тыңлый моңчан халык –
Шопен музыкасы яңгырый.

Залда хушлык тулып ашкан мәлдә
син йөткереп куйдың сак кына.
Ошбу тыйнак ютәл туры килде
көйнең салмак аккан чагына.

Килештереп тамак кыруыңны
һәммә кеше ачык ишетте.
Сөбханалла, синең өн-авазны,
ахры, ноталар да иш итте.

Яңгырашның тоеп ятышлыгын,
хәтта күңелемә шик керде, –
композитор шушы йөткерүне
махсус бизәп язган шикелле.

Әсәрләндем сәер унисонга,
сиздем тәндә янар тау көчен!..
Инде синсез кабат тыңлый алмам
мәшһүр «Шопениана» тавышын.

Allegro

Ошбу шигырьдә
үзен танып алачак
көйязар ханымга

Яшен ташы кебек тота-каба
иңде икән синә кем җаны?!
Инде хәзер гомер итә бирче,
ашыктырып фани дөньяны.

Әммә тәкъдир сүзе шундый саллы –
килеп бетмәс синең көеңә.
Илаһ җаен хаклап таңнар ата
һәм моң гына сүнеп көн иңә...

Күпләребез бии кубызыңа,
уйнак кулың җитә бар җиргә!
Фәрештәләр кылган гамәлеңне
өлгералмый язып барырга.

Эчең поша хәтта матәм маршын
гел-гел шулай акрын уйнауга.
Насыйп җенең өстәп торган дәртне,
бүлсәң, җитәр иде ун җанга...

Көнем бетәр диеп хафа чикмә,
фигылеңә мәңге тугры син, –
олуг нәби сурга өргән чакта
нота битен ачып торырсың.

Ишарәт

Күбәләк канаты кагылып киттеме,
тетрәтеп үттеме
бибекнең өн-моңы, –
ишелде кинәттән...
кып-кызыл күбәдәй,
чирәмдә утырган багалма өеме.

Аптырап көндезгә тәгамгә
ашыктым,
янәдән гаҗәпкә калдырды өй мине:
бернинди сәбәпсез ишелде табында
телемләп киселгән ипекәй өеме.

...Сентябрь яңгыры.
Кыйблага караган
тәрәзәм ничәнче мәртәбә юылды.
Аңыштым, ниһаять –
мин газиз әнкәмне
төшемдә күптәннән
күргәнем юк иде.

Агыш

Бормаланып чишмә ага әрәмәдән,
тирә-юньгә җофар исе бөркелә.
Яргаланган җиде улак эргәсендә
бер карт белән ике малай гөр килә.

Бабалары, кабат-кабат бисмиллалап,
багалмалар тәгәрәтә иң өстән.
Өметләнеп аста тора оныклары:
«Коры калмыйк
безгә тиеш өлештән!»

Ә дәү әти, инде зекер әйтә-әйтә,
торыннары хозурында ант кыла.
Тегеләре тәкатьсездәй
тәкрарлыйлар:
«Улак буйлап алма озак акты ла...»

Агымсулар соңгы вакыт аксакалның
төшләренә гелән кереп йөдәтте;
күрсенгәндәй кабатлады
күңеленнән:
«Балачакның алмалары тиз акты,
аһ, шулкадәр тиз акты!..»

Ялгану

Әнкәй үлгән көннең
истәлеге

Ябь-яшь башым ташка орыр мәлдә
әллә ничә төрле уй кордым;
аннан кулны селтәп, озак кына...
кендегемә карап утырдым.

Күзне йомсам, бөтен аңны биләп,
әнкәй тулгак тоткан төн бага.
Ике бәгырь җебен пычак өзгәч,
ни соң бәйли мине дөньяга?

Күкләр тыны сеңгән кендек бавы
вәйран булып ята кайларда?..
Тәкъдир сузган тәүге ярдәм кулы
бик салкын да иде, кайнар да.

Ялгышмыйча кая ялганырга –
ташып тора юкса көч тәндә.
Җуя төсле инсан кирәк җайны
җиһан карынына күчкәндә.

Файда бирмәс, еллар аша сорап,
кендек әбиемә дәшү дә.
Тамчы каным тамган ап-ак биләү
агып киткән инде ташуда.

Бергә-бермен гел-гел тибәрергә
әзер торган тормыш алдында.
Оча вакыт! Тоту кыен хәтта
чабып барган атның ялын да.

Тармакланган яшен тамырына
үрелә-үрелә япан кыр кичтем...
Кичерсәңче, әнкәй, көферләнеп,
ахры, акланырга керештем.

Мин болай да насыйп җаным белән
инде мәңгелеккә береккән.
Авыр чакта, Аллам, гаҗиз башка
уйлап алыр форсат бир икән –
йөз сорауга җавап бер икән.

* Мәрхүмнең йөзеннән битлек (маска) алу күздә тотыла.



тәрәзәдә – янә кояш?

Фәйрүзә Мөслимова... Күңелләргә җыр булып килеп кергән шагыйрә. «Яраттырасым килә», «Алкаларым сыңар-сыңар», «Төшемә кер әле»... Шигырь сөючеләргә бу исем, ул җырлар күпне сөйлидер. Тупыл мамыгыдай ак һәм йомшак, Агыйделедәй салмак-талгын, сыерчык бураннарыдай ашкын шигырьләре язлы, назлы, тузганаклы... Хикәяләре дә шигырь юлларына сыялмаган хисләрдән тора, алардан ихласлык, яктылык сирпелә... Тынгысыз җаны, үткен каләме, эзләнүчән, максатчан холкы, бу дөньяга, язмышларга битараф булмавы, кешеләрне яратуы исә аны журналист итеп тә таныта.

Ә күз алдында һаман бер картина...

Студент чагында имтихан алдыннан зачётка арасына талисман итеп шомырт чәчәкләре салып куючы, җәйге яңгыр астында ак күлмәге лычма суга әйләнгән, ак босоножкаларын кулына тотып, асфальтка җыелган күлләвекләргә ялантәпи көлә-көлә кереп баручы, туган ягына кайткач, Актаныш басмаларыннан Агыйделгә йөгерүче Фәйрүзә... Хыялый, гадәти тормыштан да матурлыкны күрә белүче ихлас зат ул. Иҗаты да, үзе дә матур.

Июль кызы Фәйрүзәне түгәрәк гомер бәйрәме белән котлыйбыз! «Сөембикә» укучыларын һәрвакыт сөендереп торуын телибез.

Эльмира ЗАКИРОВА



Фәйрүзә МӨСЛИМОВА

ТӘРӘЗӘДӘ – ЯНӘ КОЯШ?..

(Хикәя)

Бер шәһәрдә яшәсәләр дә, әнисе янына әллә ни еш бара алмый Нурия. Эш, гаилә, балалар... Хатын-кызның мәшәкате бихисап шул. Аннары, тиз генә хәл белешеп алу өчен телефон да җитә, гел очрашып-сөйләшеп тору мәҗбүриме?

Менә бу ял көнендә, ике баласын иренә калдырды да, әнисе янына барып кайтырга уйлады. «Теләсәгез, паркка чыга аласыз, кинога барсагыз да була, мин кичкә әйләнеп кайтырмын», – диде.

Урамда яз, кояшлы апрель балкый иде. Кар эреп, анда-санда гөрләвекләр челтери, нәни күлләвекләрне сикереп үтәргә, урап узарга туры килгәли. Йөзенә сипкелләр сибеләсенә дә исе китмичә, Нурия кояшка карап атлый. Балачак сукмаклары буйлап узганда, әлбәттә инде, ваемсыз рәхәт чаклар искә төшә. Күпмедер еллар элек, шундый ук бер апрельдә, ниндидер зур сайлау көне билгеләнгән иде. Президент сайлаулар булгандыр инде ул, мөгаен. Нуриянең хәтерендә ул көн бәйрәмчә күңелле, якты булып сакланып калган. Үзенең әле ул чакта сайлауга яше җитмәгән. Абыйсы Наил инде сайлауга барачак! Ә ул, әнә, һаман йоклап ята. Техникумында дәресләре иртә башлана шул, ял көне булгач, озаграк йокламакчы.

Тик шунда тәрәзәдән кояш нурлары кереп, туп-туры күзенә төшәргә, керфекләрендә биергә керешмәсенме? Ничек? Аларның тәрәзәсе төньякка карый лабаса! Наил теләр-теләмәс урыныннан кузгалды:

– Ну бу Артурны! Тәки йокларга бирмәде!

Каршыдагы йортта яшәүче дусты Артур үзенә төшкән кояш нурларын көзге белән Наилгә «озата», шулай итеп аның күзләрен чагылдыра икән. Ул арада үзе дә кереп җитте:

– Тор, йокы чүлмәге, киттек сайлауга! Гражданлык бурычыбызны үтәп кайтыйк.

...И-и, күңелле дә вакытлар булган инде. Егетләр тиз арада «бурычларын үтәп» тә кайттылар. Гөнаһ шомлыгына, каратут йөзле Артурның сизелер-сизелмәс сакал җибәргән чагы, абыйсы да «кавказ кыяфәтле»ләргә тартым. Ә көньякта сәяси вазгыятьнең катлаулырак чагы.

Сайлау участогында: «Сез кем буласыз, нишләп йөрисез биредә?» – дип, милиция постында тоткарлап та торганнар үзләрен. Бу хәлне көлә-көлә сөйләделәр дә, кичкә кадәр өйдән чыкмавыбыз хәерле дип, чәй эчеп, телевизор карап кына утырдылар.

Әнисенә барышлый, Нуриянең хәтеренә гел нишләптер шул Артур белән бәйле вакыйгалар килде. Югыйсә үзенең дуслары да, абыйсының башка дуслары да шактый иде бит. Күрәсең, Артур белән ешрак аралашканнардыр. Өйдә берәр мәшәкать килеп чыкса, ялт итеп Артур кереп җитә: яңа люстра эләргә кирәк булсынмы, кухняда ремонт ясарга дисеңме... Ә аяк киеме төзәтүдә аңа һич тиңнәр юк. Иске босоножкаңны да ялт итеп яңартып бирә.

Бервакыт Артурларның балконында көтелмәгән күренешләр барлыкка килде: анда, кер бавына элеп, бала чүпрәкләре, ползункилар киптерә башладылар. Нурия соң чиккәчә гаҗәпләнде. Абыйсы хәлне гади генә аңлатып бирде: «Әйе, аның яраткан кызы бар, моңа кадәр «гражданский никах» белән яшәделәр, бәбиләре тугач, үзләренә, әти-әнисе янына алып кайтты менә», – диде.

И Артур, Артур! Яшерен серләрең дә булган икән бит. Моннан соң тагын да гаҗәбрәк серләрең белән шаккатырдың әле син Нурияне. Эш болай булды: ул көтелмәгән серне иң элек Нуриягә абыйсы тиште. «Мин өйдә булмаганда Артур керсә-нитсә, ишекне ача күрмә, ул наркотиклар куллана», – диде. Әйтүен әйтте дә бит, ул сүзләр Нуриянең бер колагыннан керде дә икенчесеннән чыгып та очты. Һәм чыннан да, абыйсы да, әнисе дә өйдә юкта Артур ишек кыңгыравына басты. Идән юып йөри иде Нурия, аны-моны уйламады, ачты инде ишекне. «Менә, Наилнең туфлиен яңартып керттем әле», – диде Артур. Кай арада күреп алгандыр, көзге каршында күрше фатир хуҗасының: «Кызым кайтса, бирерсең, ачкычын оныткан икән», – дип калдырган ачкычы ята иде. «Телефоннан шалтыратырга гына кереп чыгыйм», – дип, шул ачкычны сорап алды да күршегә кереп китте. Бик тиз әйләнеп чыкты үзе, бу хәлне онытырга да мөмкин иде. Тик... Кич белән Нурияне күрше кызы чакырып алды да: «Ачкыч синдә иде. Шкафтан акча югалган. Йә кайтарасың акчаны, йә милиция чакыртабыз, әниеңә дә әйтәбез», – дип котын алды.

Менә ичмаса капты кармакка Нурия! Артурны эзләп чыгудан мәгънә юк. Абыйсына әйтсә, мин сине кисәттем, диячәк. Әнисен ничек хафага салсын тагын... Болай да гаиләне берүзе тартып бара, очын очка ялгап яшиләр диярлек. Җитмәсә, заводларында хезмәт хакын да вакытында түләмиләр. Шулай да Нурия шкафтагы бер китап арасында күпмедер акча ятканын белә. Нишләмәк кирәк? Милициягә эләккәнче, шуны алып бирү хәерлерәк. Әнисенә берәр ничек аңлатыр әле. Ул бит аны һәрвакыт гафу итә...

Югалган акчаның бик тиз кирәге чыкты. Өстәвенә, Нуриянең үзенә. Мәктәптә инглиз теленнән яңа дәреслек сатып алырга кирәк булып чыкты. Әллә ни кыйммәт булмаса да, акчаны әнисеннән сорыйсы бит.

Әнисе акча ятарга тиешле китапка үрелгәндә, ни үле, ни тере басып торды Нурия. Анда акча юк иде! Менә китте сорау алулар, аңлатулар, үпкәләшүләр, тиешле җәзасын алулар... Абыйсы Артур янына чыгып чапты. Кая анда? Урланган акчадан әллә кайчан җилләр искән инде.

Менә шундый гыйбрәтле вакыйга. Ә инде наркотиклар тоткынлыгына эләккән шундый ярдәмчел, яхшы күңелле бичара Артур һич көтмәгәндә үлеп китте. «Передоз, – диде абыйсы. – Күпме әйттем, тотынма дип, тыңлата алмадым бит. «Наркоман түгел мин, теләсәм ташлыйм», – дип йөрде...» Ни үкенеч, шул гөнаһлары өчен гомере белән түләргә туры килде Артурга. Каршы балкон тәрәзәсендәге кояш нурлары да сүнде...

Әнисе янына килеп җиткәнче, әнә шуларны күз алдыннан кичерде Нурия. Домофон төймәсенә басканны көтеп кенә торган диярсең, әнисе ишекне шундук ачты.

– Кызы-ы-ы-м, кайчаннан бирле күзгә-башка күренгәнең юк иде. Ничек кенә киләсе иттең? Алма бәлеше пешереп йөри идем әле. Кияү белән балалар килмәдемени?

– Юк, әни. Балачактагы кебек, синең белән икәү генә сөйләшеп утырасым килде әле менә.

– Бик әйбәт иткәнсең, телефоннан тавышың ишетелсә дә, күзләреңне күреп булмый шул.

Нурия елмаеп кына куйды. Ул үзе алай ук тирән уйланып тормый, эшендә дә, гаиләсендә дә аралашу җитәрлек булгач, киресенчә, кайчакта ялгыз калу да аңа бик рәхәт кебек тоела. Әнисенә дә ялгызына рәхәттер дип уйлый. Абыйсы гаиләсе белән бөтенләй башка шәһәрдә яши. Шулай ук телефон аша аралашалар. «Элек без әнкәйләргә хатлар яза идек», – ди әнисе. И әни, әни... Анысы элек булган бит аның, хәзер заман бөтенләй башка.

Очрашу шатлыгыннан әнисе табын әзерләргә керешге. Нурия үзен чыннан да кечкенә баладай хис итеп, кулларын юып, өстәл янына, әнисе каршына чүмәште. Ул арада төньякка караган тәрәзәләре балкып, нурланып алды да, бер уңайдан әнисенең дә, Нуриянең дә йөзләрен балкытып үтте.

– Әни! Артур тәрәзәсеннән кояш карый?!

– Әйе, кызым. Аның улы миңа шулай сәлам бирергә ярата. Бик акыллы бала. Бер очрашканда аңа әтисе турында сөйләгән идем. Абыеңның дусты булуы турында да. Иртәнге якта көзге белән кояш нурларын уйнатуын да искә алдым инде. Менә хәзер үзе шулай мине сәламли.

– Әни, минем аны бик тә күрәсем килә! Артурның гел яхшы якларын гына үзенә күчерсен иде ул, гөнаһларын гына кабатлый күрмәсен иде.

Сүзләрен шулай Артурны искә алудан башлаган ана белән кыз бик озаклап табын янында сөйләшеп утырдылар. Ә кояшлы якты урамда озын кыштан соң җиңел җәйге киемнәргә күчкән кешеләр хозурланып йөри, карлар эри, түбәләрдән тамчылар тама иде.





Наил ШӘРИФУЛЛИН

Наил Шәрифуллинның язмасы исеме белән үк әсир итте. Әтәмби әбиләре турында шулкадәр яратып язган! Фазыл Искәндәрнең Чегемын хәтерләтте ул. Авыл әбиләре һәркайсы – үзе бер кабатланмас образ! Тагын шунысы да бар: Наил – язучы Миргазиян Юнысның авылдашы, алар икесе дә Исергәп егетләре. Әллә гүзәл табигать, әллә ихлас кешеләре, әллә шул якларга гына хас гадәтләр сагынуларны шулай барлата микән? Электроника, лабораторияләр, конструкторлык бюролары дөньясыннан булган Наил язучылыкка, журналистикага кереп китә, публицистик язмалары белән танылa, китаплар чыгара. «Ватаным Татарстан» газетасының махсус хәбәрчесе. Лениногорскида яши.

САГЫНУЛАРНЫ БАРЛАГАНДА

ЯКИ ӘТӘМБИ ӘБИЛӘРЕ

(Эссе)

Тәрәзә кыйссасы

Авылны мин элеккечә сагынмыйм инде. Күп еллар үтеп, танымаслык булып үзгәргәнгәдерме, әллә артык зур булгангамы, бик теләгәндә дә аны күңелемә тулысынча сыйдырып бетерә, уйлап сагышлана, гаҗизлеккә бирелә алмас идем. Мин үзем үскән урамны – Әтәмбине сагынам. Аны да бөтенләе белән түгел. Бала чакта мин менмәгән бер генә агачы, ялан тәпи басмаган бер генә карыш чирәме, мин ятып аунамаган туфрагы калмаган очын – авыл башын сагынам мин.

Безнең өй авылның нәкъ башында иде. Мин дәрес әзерли, китап укый, утырып тамак ялгый торган урын тәрәзә каршында булып, зәңгәр рамлы шул тәрәзәдән колхозның җимеш бакчасындагы алмагачлар, урманга чаклы сузылган иркен яшел кырлар, Кандыз юлы дип йөртелеп, кояш баешы ягына китеп югалучы гади кыр юлы, посадка дип аталып, гаскәрдәй тигез сафларга баскан якын һәм ерак агачлыклар – барысы-барысы да, хәтта бездән ун чакрымнарда урнашып, инде күптән таралып юкка чыккан урыс авылының һаман да исән чиркәү гөмбәзләренә чаклы аермачык күренеп тора иде.

Гаҗәеп гүзәл манзара иде ул тәрәзәдә. Андагы күренешнең соклангыч бөеклеген, үзем өчен, нечкә-сизгер күңелем өчен булган кадерен, бәясен дә мин соңыннан гына – нигез бушап калып, өй дә, аның белән бергә тәрәзә дә юкка чыккач кына аңладым...

Гади авыл өендә мәшһүр рәссамнарның картиналары, әлбәттә инде, юк иде. Кая безгә – каткан тезгә дигәндәй, данлыклылары түгел, хәтта иң гадиләре дә юк иде. Шәһәр кешесе булганчы мин аларны күрмәдем дә, белмәдем дә. Атаклы картиналарны миңа менә шушы тәрәзәдән күренгән, мине үз кочагына алырга һәрчак әзер тере манзара-сурәт алыштырды. Авыл башының шул болыннары, кырлары, инеше, шул агачлыклары мине кочагына сыендырып назлап кына калмады, гади, эчкерсез бер табигать баласы итеп тә үстерде. Шуңадыр, ахры, язын агачлар яфрак ярганда, һәр ел саен, әле хәзер дә, йөрәкне җилкендереп күңелемдә тыелгысыз бер уй-теләк туа: юкка чыккан нигеземә кайтып, шул зәңгәр рамлы тәрәзә торган

урынга басып, сабый чакның күңелемә уелган бөек сурәтенә, картинасына, һәр елны яңарып яңадан туган шул кабатланмас гүзәллеккә туйганчы бер карап торасы, юанасы, сафланасы, кабаттан да самимиләнеп, бик азга гына булса да балачакка кире кайтасым килә. Яз белән җәй арасындагы илаһи һәм газиз, әмма да ки кыска бер чорда җаным шулай җилкенә минем.

Әмма язмышның шаяруыдырмы, бу теләк тормышка ашмый кала. Язлар узып китә. Җәйләр көзгә авышып, яфракларга сары иңә башлаган мәлләрдә мин тагын зарыгып май урталарын көтәргә керешәм. Ел буе кайтырга, инде үзгәргән булса да шул күренешкә карап янә хозурланырга, кайчандыр бу дөньяны аңлый, табигатьнең даһи гүзәллегенә төшенә башлаган чорга, шул тәрәзә торган урынга барып басарга җыенам. Тагын барып җитә алмыйм, тагын калам. Дөнья мәшәкатьләре белән язлар, ямьле җәйләр тагын үтеп китә. Йөрәк белән күңел янә сыкрап елый. Алар миңа фәкать шул зәңгәр тәрәзә аша бу җиһанга чыкканымны, дөнья бәһасенә торырлык хәзинәне югалтуымны, аның тоныклана башлаган төсләрен яңартудан бу елда да мәхрүм калуымны инде ничәнче кат искәртәләр кебек.
Мин алардан тагын бер кат гафу үтенәм. Киләсе майларда кайтырмын дип тагын вәгъдә бирәм...

Тирәкләр моңы

Язларда кайтылмаса да, авыл башы чирәмнәрен тирән карлар каплап, элекке колхозның элеккеге алма бакчасы буенда бер-берсенә елышып баскан ялангач каеннарны кышкы салкын кочагына алганчы, йә шунда җәйләр көзгә авышкан мәлләрдә туган яктан, буш нигездән барыбер бер әйләнелә тагын үзе. Ян күршебез мәрхүм Нурмөхәммәт абзыйга рәхмәт, исән чагында, бер дә авырсынмыйча без гомер иткән урынны – хәтсездән бушап калган шул нигезебезне үзенә печәнлек итәсе килепме, башка уй беләнме, киртәләп алган булган. Аркылы үтеп йөрмәслек итеп. Киртәләнгән җир киртәләнгән инде, аз гына да тапталмаган, кайда биек, кайда тәбәнәк булып кызгылт тукранбашлар үскән, зәңгәр күзле тыйнак һиндыбалар кояшка үрелгән, анда-санда кыңгырау чәчәкләр дә күренгәләгән һәм, бәлки, шулар аркасындадыр, газизлеген югалтмаган ул җирне ташландык нигез дияргә барыбер тел әйләнми. Мәңге кире кайтмас еллар истәлеген бөтенләй үк җуйдырмыйча, җанга җылылык биреп, өмет өстәп торган урын булып кала ул. Тик, ни кызганыч, соңгы вакытларда киртәләр акрын гына тузып, җимерелеп килә. Өй урыны, бәрәңге бакчасы җирләре барысы бергә авыл башы чирәмлегенә кушылыр, аны зурайтыр көннәр якынлаша...

Уратып алган нигез бөтенләй үк буш дияр идең, Нурмөхәммәт абзый корган киртәләргә терәлеп үк ихата эчендә мәгърур ике тирәк агачы үсә. Алар шундый биек, канат-ябалдашлары шундый киң, мин алар өчен сокланам да, күпмедер хафаланып та куям. Хафалануларым шуннан, тирәкләрнең берсе миннән хәтсезгә өлкәнрәк тә бит. Давыл-фәлән чыкса, каршы торыр көче һәрчакта да җитмәскә дә мөмкин аның. Мин сабый чакта ук тирәк шактый биек иде. Аңа үрмәләп менеп йөргәннәремне, берсендә, ботак шартлап сынып, җиргә мәтәлеп төшкәнемне каршы күршебез Нурислам абыйның күреп калып, соңыннан үземә «космонавт» исеме тагып куйганын да яхшы хәтерлим әле. Комаров дигән космонавт уңышсыз очыш ясаган ел иде ул. Агачка кат-кат менүләр гадәттә язларын, апрель башларында, карлар эрегән чакка туры килә иде. Мин, 10-12 яшьлек малай, юк-бар такталардан үзем булдыра алганча итеп сыерчык оясы ясыйм да ачык яшькелт төстәге ботакларга тотына-асылына менеп, шуны әле ул вакытта күкләргә үк ашмаган тирәк кәүсәсенә беркетәм. Һәм зарыгып аның хуҗалы булуын, яз алып килгән кошларның шунда ияләшүен, оя коруын көтәм. Бераздан теләгем кабул була гына түгел, түбәм дә күккә тия. Кояшлы җылы иртәләрнең берсендә өйалды ишеген ачып тышка чыгуыма, кара каурыйларын аксыл таплар чуарлаган яз кошы – сыерчык, оямның түбәсенә баскан да канатларын кага-кага тансыклаткан илаһи җырын суза.

Тирәкләр искә төшкәндә яңарган, күңелемнән һичкайчан җуелмаячак истәлек-сагынуларымның янә берсе – кичке салмак җилдә үзара нидер сөйләшкәндәй лепелдәшкән яфраклар. Яфрак шавы. Тирәкләр моңы. Җәйге тын кичләрдә, бар булган башка тавышлар тынган мәлдә шул шауны, моңны ишеткәнегез, озаклап тыңлаганыгыз булдымы? Бүген дә шул шау хәтеремә төшкән саен, күңелемә аерым бер рәхәтлек иңә, куанычым арткандай була. Бала чагымда, үсмер вакытларымда күпме кичләр, верандадагы тар ятагыма ятып, табигать кенә тудыра алган шул кабатланмас аһәңне – меңәрләгән яфракларның, җәйләр кыска, аралашып, серләшеп калыйк, дигән кебек, үзара талгын гына сөйләшүләрен тыңлап, изрәп татлы йокыга тала идем бит мин...

Безнең «квартал»

Балачак мизгелләре яңарганда, мин әле тагын үзебезнең «квартал»ны, аның кешеләрен, күрше-тирәне дә бик сагынам. Мин сөйлисе затларның күбесе бакыйлыкта инде. Шул исәптән, 70-75 ләрне яңарак кына узган әби-бабайлар булып, бүген балаларына оныклар үстерешергә, булдыра алганчы дөнья көтәргә тиешләре дә гел икенче «квартал»га – татар авылларында «каенлык» дип аталган җиргә, авыл башына терәлеп үк торган зиратка күчеп, инде хәтсез еллар кызыл балчыктан алынган тар, салкын ләхетләрдә яталар. Авылдашым, урамдашым, олуг язучы Миргазиян Юнысның үткән гасырның җитмешенче елларында ук татар матбугатында (шул исәптән «Азат хатын»да да) дөнья күргән данлыклы «Әтәмби хатыннары» язмасындагы затлар да күптәннән шундагы мәңгелек йортларында...

Авыл башында бер-берсенә кара-каршы утырган өч пар өй, өч пар ихата, төп урам Әтәмбидән, аның башка йортларыннан аерылып, үзенә күрә бер кечкенә квартал сыманрак булып тора иде. «Тора иде» дим,



чөнки алты йортның бүген өчесе генә исән. Ике нигез урынында бушлык булса, Мөкатдис бабайларның хәтсездән ятим калган өе яртылаш җимерек хәлдә. Исән дигәннәренең дә икесендә инде беркем дә яшәми.

«Квартал»ны, әйткәнемчә, әле дә төп урамнан ике яклап ике тыкрык аера. Тыкрыкта язын кар суы ага торган алай тирән булмаган тар гына чокыр – җәйләрен ямь-яшел чирәм белән капланып, безгә янә дә бер аулак уйнау урыны булган урыннар нәкъ элекке кебек. «Квартал» гына, әйткәнемчә, гел башка инде бүген…

Язасы килгән сүз без – бала-чагага һәрдаим диярлек күз-колак булып торган, гомер уртасына якынлашкан балаларына без – ташбашларны үстерешкән, барысы да диярлек шактый озак яшәп, кем әйтмешли, ашыйсын ашап киткән әбиләр турында иде. Мин үскәндә алты йортлы безнең ул «квартал» үзенчә гөрләп торып, анда ул-кызлары, киленнәре, оныклары белән бергә биш карчык та дөнья көтте. Әле чагыштырмача яшь әбиләр. Безнең якта кулланылган сүз белән бәяләгәндә – дыңгычтайлар. Менә шушы биш карчыкның бары берсе генә бабайлы булып, мин үскәндә алар барысы да диярлек җитмешне инде ваклаган, бәлки аз гына өлкәнрәк тә булганнардыр. Һәм инде чагыштырмача сау-сәламәт көе, бер-берсенә чәйгә, хәл белешергә кергәләп, капка төпләрендә озаклап сөйләшкәләп утырып, йорт тирәседәге көндәлек мәшәкатьләрен дә калдырмыйча, балаларына мал-туарын, бакчасын карашып, кайчагында бер-берсе белән бәләкәй генә тавышланышып та (дөнья булгач, анысы да булгалый), акрын гына, кабаланмый гына картаялар иде. Дөньялар, Аллага шөкер, тыныч, сугыштан соңгы авыр елларга караганда тормыш күпкә яхшы, бик күп булмаса да пенсиясе дә килеп тора, колхозда инде эшләнәсе эшләнгән – тагы ни кирәк? Гәпләшкәндә яшьлек еллары, сугыш вакытында бер караңгыдан икенчесенә чаклы эшләгән вакытлар, тол калулар, бер-бер артлы хәтерләрдә яңарып, бер күренеш икенчесенә ялганып китәр, сөйләшеп сүзләре бетмәс иде. Малай-шалай күзлегеннән караганда, әбиләрнең мондый яшәешхәләте гомерлеккә, бик тә озакка кебек иде. Мин ул вакытларда олыгайган саен елларның тизрәк үтүен, гомернең санаулы еллардан торуын, чикле булуын аңышып бетерми идем шул әле.

Әбекәем

Әбиләр хакындагы истәлегемне үз әбиемнән башлыйсым килә. Аны әле һаман да төшемдә күрәм. Инде күпме тапкырлар бер үк төш: авыл башындагы язгы яшел чирәмдә аякларын сузып утырган да, оядан яңа гына чыккан сап-сары каз бәбкәләрен саклый ул. Өстендә үзе яратып кия торган парчалы яшькелт күлмәге, аксыл яулыгын аркасына төшереп бәйләгән. «Менә, балам, Ходай кушып, тагын ишле булып чыктылар, исән үссәләр көзгә сезгә дә булыр әле», – ди. Күзләрендә балаларча самими сөенү, көләч шатлык. Мин дә сөенәм. Сары йомгак каз бәбкәләре, муеннарын сузып, бер-берсе белән нидер гәпләшәләр, үлән йолкыганда «лып» итеп артларына утыралар да, тагын куанышып-сөйләшеп алалар. Төш булса да исәпләп ятам: шундый матур кояшлы яз килү – бер шатлык булса, ишле бәбкәләр чыгу – икенче шатлык. Өченчесе – барысыннан да зуррагы – күрешү шатлыгы. «Исән-сау йөрдеңме, балам?» – әбекәй озак итеп аркамнан сөйгәндә, мин гадәттә уянып китәм. Бөтен шатлыгым шул мизгелдә эреп юкка чыга. Өзелеп әбекәембичарамны сагына башлыйм. Аның инде бу дөньяда булмавы белән һаман килешәсем килми. Аңа күрсәтә алмаган игелекләр өчен үкенүләрем төер булып тамак төбемә утыра.

Әбекәй, әбекәем. Бу сүзне мин сөйләшә башлаган вакыттан алып ир уртасы булганчыга чаклы әйтеп килдем. Аның картайганын да, ничектер, сизмәдем. Ниндидер беркатлылык белән аның кайчан да булса бер үләренә дә ышанмадым. Кырык ел буе «әбекәй» дип йөргәч, ул минем өчен инде мәңгелек сыман инде.

«Казлар артыннан да сине күтәреп йөгердем. Сыер кайтмаса да сине күтәреп эзләргә китә идем. Сепарат аертырга барганда да үземнән калдырмадым», – дип сөйли иде мәрхүмә. Шулай булгандыр. Үземне белә-белгәннән бирле әбекәйнең итәгенә тагылып йөрдем. Ул минем төп тәрбиячем, төп әңгәмәчем, төп яклаучым да иде. Шунлыктандыр, хәтерлим, мәктәпкә укырга кергәч, укытучыбыз Сәлимә апага да, ялгышып, берике тапкыр «Әбекәй» дип дәштем. Классның рәхәтләнеп күтәрелеп көлгәннәре истә калган. Кибеткә чыкса да – мин, Баулыга, Башкортстандагы Приютово бистәсенә, энесе янына барса да, совхоз ягына җыенса да – җитәкләгәне мин. Мин белә-белгәннән бирле хәрәкәтне, юлны яратты, кешеләр белән аралашуны, сөйләшүне үз итте, шуңа хирыс булды. Хәзер уйлап куям, юкка да сөенә белүе, һич кенә дә пошаманга төшеп аптырап калмау сыйфаты, көр күңеле, якты йөзе, тормышны яратуы шулай озак яшәткәндер аны.

Кышларын мин мәктәпкә дип уянганда, әбекәй мичкә әрәмә чыбыгын ягып маташкан була. Шул чыбыкның барлы-юклы күмерендә мин укырга киткәнче тиз генә коймагын да пешереп бирә. Ураза вакытында мин дә сәхәргә торам. Аның уразага дип алып куйган хәлвәсе була, ул мине шуның белән сыйлый. Каникулларда кунакка әни белән бертуган абыйның кызлары Әлфия белән Зөлфия киләләр. Килү белән алар әбекәйдән күзикмәк пешертәләр. Шуның өчен үлә язалар. Аларның кайтуы, күзикмәк ашаулар минем өчен дә олы шатлык, бәйрәм була иде. Ул ипле, акыллы кызларны шундый ярата идем, алар киткәндә әбекәйгә күрсәтмичә генә мышык-мышык елап калам. Мәктәпне тәмамлагач, кызлар икесе дә бер-бер артлы медицина институтына укырга керделәр. Әбекәйнең шаяртып әйткән сүзләре хәтеремдә: «Ходаем, икесе дә табиб булып чыксалар, дәвалый башласалар, үлә алмый этләнерсең».

Урманнарга, әрәмәләргә йөрүләрне искә төшерәм. Совхоз әрәмәлегеннән һәр елны әбекәй белән чиләк-


Фото: Фәнзилә Мостафина

чиләк балан, шомырт җыя идек. Баланнан ул кыш буе балан бөкериләре (бөккәнне бездә шулай диләр), бәлешләре пешерә, әчкелтем җимеш сулары ясый, төелгән шомырттан пешергән кабартмалары телеңне йотарлык була. Ул җиләккә йөрүләр, җиләк бөкериләре! Инде сиксәнне узгач та, җиләк дигәндә дөньясын онытучы карчыкны урман каравылчысы машинасына утыртып җиләклеккә илтеп куя иде. Әбекәй, яшь кызлар җитезлеге белән тегеңә ике-өч сәгать эчендә чиләкне тутырып та бирә. Хезмәте өчен каравылчы соңыннан бер-ике кап һинд чәе китерә. Хәзер уйлыйм, җиләкне һич кенә дә чәй өчен җыймагандыр ул. Сиксәннән соң биш чакрымдагы урманны әйләнеп кайтуы бик җиңел эш түгел. Ә монда илтеп куялар, алып кайталар. Җәйге ямьле урманга барып хуш исле болын чәчәкләре арасында, кошлар сайраганда кызарып пешкән җир җиләкләре җыю аның өчен бер сәяхәт, хозурланып кайту, күңелгә хуш килә торган шатлыклы бер шөгыль, картлыкның аз сөенечләреннән берсе булгандыр.

Туксаннар тирәсенә җиткәч, моңарчы гәпләшергә яраткан әбекәйнең сүзе азайды. Сөйләштерсәң сөйләшә, үзе башлап бик сүз әйтми. Мин моны башта картлык галәмәтедер дип уйлаган идем. Ул гына түгел икән. Улында, Баулыда тора – ашаталар, эчертәләр, тик рәтләп сөйләшмиләр. Кайчагында атналар буе да бер сүз әйтмәскә мөмкиннәр. Авылда тора – әни, гомумән, сүзгә саран кеше. Әбекәй үзе сүз башлаганда да әңгәмә барып чыкмаска мөмкин. Менә шулай акрынлап олы кешедә, хәзергечә әйтсәк, комплекс туа, күрәсең. Мин аны кирәксезлек комплексы дип атар идем. Минем хәзер беркемгә дә кирәгем юк, болар мине яратмыйлар икән, мин бер артык кашык, иске җиһаз болар өчен, дип уйлап йөри башлый карт кеше. Шул уй акрынлап аның аңына сеңә. Кыенсыну, беренче итеп сүз башламау гадәткә әйләнә. Чырайга боеклык иңә. Мондый халәт картлар күңеле өчен иң авырыдыр. Без генә аларны аңларга теләмибез.

Исәннәрнең кадерен белмибез шул без. Тамак төбендәге төер кебек, әбекәй исән чагында үтәлергә тиеш булып та, хәзер инде беркайчан да үтәлмәячәк ике үкенеч калды. Мәрхүмәнең туып-үскән якларын – Башкортстандагы Сүлле авылын исән чакта бер күреп кайтасы бик килгән иде. Ул бу үтенечен бераз оялыпкыенсыныбрак, нәзакәтле итеп кенә әйтте. Тик алып барып булмады. Нәрсә сәбәп булды икән дип сорыйм хәзер үземнән. Тормыш ваклыклары, күп нәрсәне соңга калдыру гадәте, һаман шул дөнья куу. Ә, бәлки, төп сәбәп гап-гади сансызлыктыр? Икенче үкенеч – хәтерсезлек белән, 90 яшенә бүләк алып бирә алмадым. Монысы да аның шул сансызлык инде. Ул бит юк кына әйбергә дә чын-чынлап сөенә белә, яктырып китә, куана иде...

Шәфигаттәй

Каршыбызда гына, урам аша гына улы Нурислам абый белән килене Гөлфара апа янәшәсендә, үз нигезендә Шәфигаттәй яшәп ята. Тәбәнәк кенә буйлы, җыйнак гәүдәле, кара тут йөзле, артык күп сөйләшми торган тыныч карчык. Усаллыгы да бар, әйтәсе сүзен өздереп, кайчагында кистереп үк әйтә. Мин аны еш кына бездән якында, инеш буенарак урнашкан Аскы урамдагы кызына – Минҗан апаларга йә барган, йә кайткан вакытында очрата идем. Шулай да хәтеремә



аның да әбиләрнең традицион эше – казлар карап, шулар белән мәш килгәне ныграк сеңеп калган. Бәбкәләр чыгу белән, май башларында ук, чүпрәк пумала кигерткән таягын алып, көннәр көзгә авышкач, бәбкәләр сары матур төсен күптән җуеп, әнкәләреннән аз гына кайтыш булып үсеп җиткәндә дә шул таягын кулыннан төшермәс иде Шәфигаттәй. Казлары да ким дигәндә ике оя һәм шактый ишле була торган иде. Авыл башының олы келәмдәй җәйрәп яткан ямь-яшел чирәмнәре исемә төшкәндә, шул күренешнең аерылгысыз өлеше булып, күрше әбинең пумалалы таягын як-якка селкеп, бер көтү казларын су буена куганы күз алдыма килеп баса. Бәбкәләр генә түгел, эреле-ваклы дүрт онык та эти-әниләре эштә чакта күрше карчыгы карамагында иде. Бигрәк тә өлкән онык Илшатның «әбием» дип яратып дәшүе хәтердә әле. Оныклар – әбиләрен, әби кеше оныгын яратмый кала аламы соң инде? Әби тәрбиясе алган балалар да үзгә – инсафлырак, мәрхәмәтлерәк булмый микән әле. Тик менә картаймыш көнендә яшәгән нигезен ташларга туры килде шул Шәфигаттәйгә...

Нурислам абыйның кызылга буялган калай түбәле олы йорты хәтсездән инде буш тора. Моннан 30–40 еллар элек андый йортлар авылда бөтенләй сирәк иде. Якын-тирәбездә беренче җиңел машинаны да Нурислам абый алды. Аның коймалары да башка коймалардан аерылып, заманына күрә затлы итеп корылган иде. Болар барысы да мактауга лаек гамәлләр, әлбәттә. Әмма каршы күршебезнең күпмедер кысмырлыгы, саранлыгы да читтә йөрмәгәнлеген дә искәртми булмыйдыр. Шәфигаттәйнең пенсиясен дә сорый, хәтта таләп итәләр икән дип сөйләштергәлиләр иде авыл башында. Сәбәпләрнең, бәлки, башкалары да булгандыр, өлкән кешенең дә үз холкы бит. Ни генә булмасын, бераздан Шәфигаттәй улы һәм килене белән тынышмыйча, ничә еллар гомер иткән нигезен ташлап, башка йортка – кызына күчте. Күчүе бер хәл, шул күчеш китергән үпкә һәм рәнҗештән, имеш, әбиебез үзен кимсетүчеләрне каргап та киткән. Бәлки, чыннан да шулай булгандыр: бераздан күрше-тирәне генә түгел, бөтен Әтәмбине шаккаттырып, Нурислам абый үзе генә түгел, хәләл җефете дә аракы белән дуслашып куйдылар. Ахырда, нәрсә әйтим, шул зәхмәт, ул китергән бәхетсезлекләр, аларны бер-бер артлы үз өйләреннән күп булса ике йөз адымда урнашкан зиратка да күчереп куйды. Әле ул гына да түгел, каргыш әллә инде дәвамлы булып, бушап калган йортка яшәргә кергән кешеләр дә, имеш, нинди дә булса бәлагә тарыйлар, дип сөйләделәр. Бәлки, шуңадыр, нигезебезгә каршы олы өй хәтсез еллар хуҗасыз да инде.

Мәфтуха әби

«Квартал»да гына түгел, мин үскән вакытларда, бәлки әле бөтен урамыбызда салам түбәле бердәнбер өй – Мәфтуха әбиләрнеке иде. Кызы Галия апа гомере буе авыл советында җыештыручы, йомышчы булып эшләде, кияүгә чыкмады. Әбинең икенче, яшьрәк кызы Райга – акылга таман, кеше белән бөтенләй аралашмас-сөйләшмәс, күрше-тирә керсә дә мич арасына качучы, сәламәт вакытында кияүгә чыгарга өлгермәгән карт кыз иде. Мин аның кан качкан ап-ак йөзен һәм капка башы яки койма ярыгы аша урамны күзәтүләрен генә хәтерлим.

Кешегә сирәк керә иде Мәфтуха әби. Кече кызының шундый халәте, олысының кияү күрми олыгаеп килүе аны, әлбәттә инде, кимсетмичә калмагандыр. Ана йөрәге аның ишегә бик тә сизгер була бит. Күрше әби кеше белән сөйләшкәндә дә артыгын әйтмәс, тик шулай да берәр кызык яки хикмәтлерәк сүз кыстырып куяр. Галия апа, киресенчә, кеше белән аралашырга бик маһир булды. Холык-фигылендә, үз-үзен тотышында ялгызлык никтер аз гына да сизелми иде кебек.

Йортта эшкә яраклы ике генә кеше, алары да хатын-кыз затыннан булып, барыбер кешедән ким яшәмәс өчен җан көчләренә тырыша иде күршеләр. Сыердан да өзелмәделәр, сарыгын, кош-кортын да асрадылар. Кышка җитәрлек итеп печәнен, утынын да әзерли алдылар. Мин авылдан чыгып китеп, шәһәрдә укып йөргән елларда салам түбәле кечкенә ул өйне калдырып, искерәк булса да алты почмаклы җыйнак кына бер йортка күченеп куйдылар. Моның өчен, чамалыйм, акчаны да шактый озак, тиенләп, бөртекләп җыйганнардыр алар.

Күченеп киткәннән соң, башка урам булу, авылга сирәк кайтылу сәбәпле, ни кызганыч, Мәфтухаттәйне бүтән күрә алмадым. Бераздан үлгән хәбәрен ишеттем. Биш карчык арасында ул беренче булып китте. Алда язганымча, кияүгә чыкмаган ике кыз. Шуларның берсе – акылга җиңелрәк... Гомер буе дигәндәй яшәлгән салам түбәле өй. Кимсенеп яшәү дә кешене вакытыннан алда гүргә кертә бит: Мәфтухаттәй яңадан авыл башына, шундагы мәңгелек йортына күчендә. Ә аңынчы әнкәй аларның теге кечкенә йортын утынга сатып алды. Кара көздә, җирне инде туңдырган, тик әлегә кар төшмәгән көннәрнең берсендә ул өйне, салам түбәдән тотынып, бүрәнәсен бүрәнәгә аерып, ярты көн эчендә сүтеп ташладым да әрдәнәләргә аерып «Дружба» пычкысы белән турап та куйдым.

Ә бит мин беренче сыйныфка кергән елны без өчәүләп – әнкәй, әбекәй, мин берничә атна аларга, мунчадан аз гына олы нәкъ шул өйгә сыйган, анда яшәп алган идек. Сәбәбе – яңа өй салуыбыз. Менә шул вакытта безне Мәфтуха әбиләр сыендырды. Калган күршеләр барысы да ир-атлы, аларга керү никтер уңайсыз. Ә без – кара-каршы диярлек урнашкан ике ихатада – ятимнәр. Ятим ятим янына елышмый, кая барсын? Соңга калып булса да, Мәфтухаттәйләргә аның өчен олы рәхмәт әйтәсем килә. Тик шунысы аянычлы: күршеләребезнең Ходай биргән гомере бетеп, рәхмәтемне кабул итәр кеше генә калмады бүген.

«Авыр аяк» Майкамал һәм Мөкатдис бабай

«Квартал»дагы бердәнбер бабайлы карчык – Майкамалтәй. Бәхетенә, булачак карты сугыштан исән-сау кайткан, без үскәндә дә, Ходай кушып, парлы гомер сөргән һәм инде – үзе тойды микән, юк микән – нәкъ менә шул сәбәпле, башка карчыкларга караганда бәхетлерәк әби дип белә идем мин аны. Биләмгә сирәгрәк йөрүче, калган башка әбиләр барысы да чандыр булганда, тыкрык буендагы төзек ихатада җиңел-җитез Мөкатдис бабай белән гомер итүче юантыграк бу карчыкның яшькелт күлмәктән, алъяпкычлы килеш, капка төбенә чыгып, кашы өстенә кулын куя-куя урамны, күрше-тирәне күзәткәне, кичке якта шул рәвешчә як-ягына каранып малларын барлаганы әле дә күз алдында. Үзе таза булгач, аяклары да юантыграк булгангамы, акрын хәрәкәтләнгәнгәме, минем әбекәй аны «авыр аяк» дип атый иде. Әллә чынлап, әллә шаяртып: «Тагын шул авыр аяк Майкамал очрады инде, юлым уңмас микәни», дигәннәре хәтердә әбекәемнең.

Мөкатдис бабай җитез, хәрәкәтчән, сүзгә дә оста, уңган-булган кеше иде. «Квартал»да иң яхшы җиләк-җимеш, яшелчә бакчасы – аныкы. Ихата, каралты-куралар да заманы өчен төзек. Алмагач-чияләре, кура җиләкләре, карлыган-крыжовниклары да, койма ярыгы аша барысын күреп, белеп торган без малай-шалайны кызыктырып, һәр елны мул уңыш бирә. Җәй ахырларында урамга чыгып, бала-чагага алма өләшә торган күркәм гадәте дә бар иде бабайның. Умарта да тотты. Монысы да зирәк кешеләр шөгыле. Бәлки, яшьрәк чакта ауга да йөргәләгәндер, мылтыгы да бар иде аның. Мылтык дигәннән. Җәйге җылы төннәрдә, күрше-тирә йокыга талган рәхәт мизгелләрдә ишегалдына чыгып, тора салып шул мылтыктан шартлатып атып, кире өенә кереп киткәли торган сәерлеге дә бар иде Мөкатдис бабайның. Картның болай кылануының версияләре без – күршеләрендә берничә булып, кемдер моны карчыгы белән сүзгә килгәннән соң шул рәвешчә «пар чыгаруы» дип бәяләсә, икенче аңлатма бакчасы белән бәйләнгән иде. Имеш, берсендә, яшьтәш малайлар арасында иң тәртипсезе Рәшит, Мөкатдис бабайның хуш исле сусыл алмаларына кызыгып, караңгы бер төндә караклыкка кергәндә, биек коймага үрмәләп менгәч кенә ату тавышыннан коты очып, җиргә егылып төшеп, кулын имгәтеп кенә калмаган, куркуыннан әле астына да «пес» иткән дип сөйләгәннәр иде, чын булса. Бакча каравыллавы булгандырмы, пар басымын киметүме яисә үзенә күрә бер мөгез чыгаруымы – бу гамәле күрше картының без белгән бердәнбер сәерлеге иде...

Майкамал әби белән Мөкатдис бабай күптән гүр ияләре булган кебек, язларын гөрләп чәчәк аткан, җәй ахырларына юмарт уңыш китергән ул бакчадан да хәзер инде бернәрсә дә калмады. Төзек-таза, заманы өчен үрнәк булырдай йорт та хәрабәгә әйләнеп килә. Гомерләр диген...

Хөснурый «ахирәт»

«Квартал»ыбыз карчыклары турындагы соңгы истәлек – ут күршебездә яшәгән Хөснурый әби турында. Ул үзе яшәгән өйдә генә түгел, аның янәшәсендәге йортта да әби кеше санала иде. Хикмәте гади – күршебез Нурмөхәммәт абый белән балачак дустым Әниснең әтисе Фәнис абый бертуганнар – алар Хөснурый әбинең уллары. Әлеге хәл булмаса, «квартал»ыбызда әле тагын да бер карчыкка – алтынчы әбигә дә гомер көзен кичәргә туры килгән булыр иде бәлки.

Әниснең әбисе башка әбиләрдән тагын үзенең динилеге, гарәпчә язу тануы белән аерылды. Капка төбенә болай гына чыкмас. Берәр дини китап тотып чыгар да янына утырган бер-ике «надан» яшьтәшенә сузып, үзенә генә хас мәкам белән шуннан аерым битләр укыр. Ике сүзнең берендә «И-и ахирәт» дияргә яратучы, янәшәсендәге карчыкларга һәрдаим шул рәвешле дәшүче күрше әби, үзен аш-суга чакырган йортларны да догасыз, сүрәләрсез калдырмас, Коръән ашлары гына түгел, мәрхүмнәрне соңгы юлга озатулар да ансыз үтмәс иде. Җыеп әйткәндә, Хөснурый әбиебез халыкны Алласыз калдырган, хәттә ки улы Нурмөхәммәт абыйны да партия әгъзасы итеп куйган совет заманында «квартал»ыбызның гына түгел, ярты Әтәмбинең абыстае була алды.

Дини, күпмедер укымышлы да булган күрше карчыгының күңелен бимазалап торган бердәнбер хәл – ул да булса Нурмөхәммәт абзыйның коммунистлыгыннан күпкә яманрак гадәте – тамагын бераз «чылатып» алгач, холыксызланулары иде. Гомере буе колхозның «Беларусь» тракторыннан төшмәгән, эшендә мактала торган күрше абый, эчеп кайтса, «партия дисциплинасын» бозып, коммунистик аң белән аз гына да исәпләшмичә, өйдә кем бар шуны куа да чыгара. Андый очракта күршегә керми бүтән кая барасың: Хөснурый әби килене белән парлашып безгә дә кереп җиткәли иде. Берсендә, хәтерлим, болар бик соң, төн урталарында ишек шакыды. Яткан җиреннән торып, төнге кунакларны каршылаган әбекәй, аптыраганнанмы, оятгарьлектәнме, капылт кына өйгә керергә кыймыйча, ишегалды баскычына утырып калган күрше карчыгын караңгыда шәйләмәстән, бусаганы узган Зәйнәп апага: «Төенчекләреңне нигә баскычта калдырдың, алып кер инде», – диюгә, тегесенең: «Төенчек түгел лә, әнкәй бит ул!» – диюләрен без соңыннан, кат-кат искә төшереп, үзебезчә кызык итеп сөйләшсәк тә, күршеләребезгә ул вакытта бер дә кызык булмагандыр шул.

Хөснураттәй, шактый озын гомер юлы узып, «квартал» әбиләреннән якты дөньяда бары минем әбекәйне генә калдырып, туксаннарга якынлашканда бакыйлыкка күчте...

Балачак хатирәләренең якты өлеше, күркәм истәлеге, хәтта бер бизәге булган, безне тәртипле, ипле, тәрбияле итеп үстерүгә хәтсез тырышлык куйган, яшь чакларында тормышның михнәтен, әчесен-төчесен дә шактый татыган биш әбекәйнең бишесенә дә фани дөньяда күрми калган рәхәтлекләрне ахирәттә алуларын теләп, сүземне шушы урында тәмамлыйсым килә.

Кадерле «Сөембикә» редакциясе!

ЯШӘЕШ

Дин һәм рухият турында уйланулар кичергән мизгелләрдә мин үз-үземә шундый сәер сорау бирәм. Кем соң без? Диндарлармы, әллә динсезләрме? Яисә «җир белән күк арасында» торучылар гынамы?

Мине шундый сорау белән вөҗданыма мөрәҗәгать итәргә әткәмәнкәм һәм үз башымнан кичкән фаҗигале хәлләр мәҗбүр итә. Әти-әниләрем Совет властеның беренче елларында халыкны мәгърифәтле итәргә тырышучы мөгаллимнәр булганнар. Әмма 20 нче елларда сәнәкчеләр фетнәсенә юлыгып, күп кыен «ашаганнар», могҗиза белән генә исән калганнар. Дин әһелләренең әлеге белән Кара-Зирек авылында (Ютазы районы) аларны салам эскерте астыннан тартып чыгарып, күзләрен кан баскан ерткычлар өеренә тоттырганнар. 18 кешелек партия-совет активын диннән язучылар сыйфатында Тымытык юнәлешенә (Азнакай районы) алып киткәннәр. Имән күсәкләр белән коралланган фетнәчеләр сусаган әсирләргә иелеп кар алырга да ирек бирмәгән. 35 чакрымны тәпиләп килгәч, салкын февраль төнендә Куктәкә авылында амбарга ябып куйганнар. Ә икенче көнне иртән, сафка тезеп, Ык елгасындагы бәке кырыена китереп бастырганнар. Кулларына изге китап – Коръән тоткан дин әһелләре язмышлары кыл өстендә калган бәндәләрне советка хезмәт итмәскә ант иттереп, тәүбәгә китермәкче булган. Чыннан да, рәхимсез фетнәчеләр «коммун яклы» бер кешене бәке төбенә җибәрергә дә өлгерә. Шул ук вакытта Тымытык авылында укытучы Харрас Рекәевне җәзалап үтерү хәбәре дә килеп ирешә. Бәхеткә, кызыл отряд килеп җитеп, үлемгә хөкем ителгәннәрне коткарып өлгерә. Әмма аларның тәннәрендә кара янмаган җирләре калмаган була.

Шушы канлы вакыйгадан соң әнкәемнең барлы-юклы гомере чирләр белән газапланып үтә. Авыр сугыш елларында ул вафат булып, 2 яшьлек сабые бишектә елап кала.

Шул давыллы еллардан башлап яшьләргә дини тәрбия бирү катгый тыелды. Гаиләдә дә, мәктәптә дә дини тәрбия күреп үсмәдем. Шулай да безнең әткәй-әнкәйләр буыннан-буынга күчеп килгән гореф-гадәт, йолаларны хөрмәт итәргә һәм үтәргә өйрәттеләр. Ә совет мәктәбе исә иң югары әхлак сыйфатлары тәрбияләде. Ул шәфкатьлелек, намуслылык, бер-береңә ярдәмчел, дус, әдәплеинсафлы булу, хәрамне хәләлдән аера белү, илгә бирелгәнлек, халкыбызга хас рухи кыйммәтләрне саклау һәм башкалар. Бу күркәм сыйфатлар чынбарлыкта иманлы булуның асылы түгелме соң?

Еллар узды. Гаилә традициясен дәвам итеп, мин дә әткәмәнкәм юлын сайладым, укытучы булдым. Ни гаҗәп: әткәм-әнкәмне динсезләр, алласызлар дип йөртсәләр, улымны сөннәткә утырткан өчен, дин тотучы сыйфатында үземне яраткан эшемнән җибәреп җәфаладылар. Яшь баламны күтәреп, Казанда Мәгариф министрлыгының бусагасын таптарга мәҗбүр булдым. Бу этлекне кемнәр эшләде диярсез? Шәхес культы елларында үзләренең кәнәфиләрен сакларга тырышкан, кеше язмышына битараф караучы шул ук мулла-мәзин малайлары.

Шунысы куанычлы: бу фани дөньяда саф күңелле, мәрхәмәтле, диндар кешеләр дә очраштыргалый. Шундый ачы язмышка дучар булган елларда мине ачык йөз белән каршылап, яраткан эшемә кире кайтарган мәгариф министры урынбасары Ясир Шәмсетдиновка гомерем буе рәхмәтле булып яшәдем.

8 яшемдә мәчет манарасын аударуларының да шаһиты булырга туры килде. Ул чакта бәләкәй идем. Бу коточкыч фаҗиганең нәрсәгә китерәчәген аңламаганмын. Колхоз төзелеше елларында әткәм-әнкәмне кулакларның эзәрлекләве дә күңелдә тирән җәрәхәт калдырды. Җитмәсә, 37 нче елларда әтиемне, мулла малае дип, Баулы районында эшсез

Фото: Анна Арахамия

калдырдылар, ул башка районга күчәргә мәҗбүр булды. Шушындый каршылыклы хәлләрне баштан кичерде безнең буын.

Тәкыя ШӘРИПОВА.
Азнакай районы Урсай авылы.



Миллионлаган хөрмәтле педагоглар сафында гади бер авыл укытучысы – әтием Ильясов Муса Идрис улының да булуы белән гомерем буе горурланып яшәдем.

Әти 1915 елның 14 апрелендә хәзерге Илеш районының Түбән Яркәй авылында Ильяс белән Факия гаиләсендә туа. Ләкин аның туу таныклыгына әтисенең исемен бутап, бабасы Идрис исемен язалар.

Әниләре Факия кечкенәдән музыкага һәвәс була. Балачактан ук оста итеп курайда уйный, җырлар иҗат итә. Аның «Олаккан торна», «Җилләр, җилләр», «Чирәм тапыйм» дип моңлы итеп җырлап утырганын әле мин дә хәтерлим. Картәтиебез Ильяс та үз чоры өчен зыялы кеше була. Телләр өйрәнсен дип, әтине урыс авылындагы «знаком»ы янына еш алып бара. Кечкенәдән үк немец телен дә белеп үсә әти. Ник дисәң, Түбән Яркәйдә аларга күрше булып бер немец гаиләсе яши. Әти аларның балалары белән бергә уйнап, аралашып, телләрен дә, гореф-гадәтләрен дә өйрәнә. Кечкенәдән үк укырга-язарга, рәсем ясарга маһирлыгы белән дә аерылып тора.

Түбән Яркәйдә башлангыч белем алганнан соң, бабай аны Дүртөйле районындагы крестьян яшьләре мәктәбенә бирә. Әтинең иң яраткан фәннәре математика, физика, астрономия һәм немец теле була.

1930 елда мәктәпне тәмамлап, Түбән Яркәйгә кайта ул. Картәти аны Пермь шәһәрендәге заводка эшкә урнаштыра. Шунда эшләгәндә татар-башкорт педагогика техникумына укырга керә. 45 сум стипендия алып, дүрт ел техникумда укый, студентлар һәм укытучылар арасында оста рәссам һәм музыкант булып таныла. Кулына таныклык алгач, әтине башта Тазлар авылына билгелиләр, соңрак Иске Дөмәй авылына җибәрәләр. Монда авыл яшьләре белән драмтүгәрәкләр оештырып, көн темасына кагылышлы кечкенә пьесалар язып, спектакльләр куеп та йөри әле ул. Шушы авылда эшләгәндә үзе шикелле яшь укытучы Мәгъфия белән гаилә корып, кызлары Дилара туа. Илдә, хөкүмәт программасы буенча, татар-башкорлар күпләп яшәгән төбәкләрдә милли мәктәпләр ачу эше барган чор. Безнең әти дә гаиләсе белән Үзбәкстанның Тархан өлкәсе Ворошилов районына укытырга китә. Авыллар арасында йөрергә ат бирәләр. Кызлары Диларага 1 яшь тулганда әтине Совет Армиясе сафларына алалар. 1939 елның 8 декабре була ул. Хәрби хезмәтне чик буенда – Литва Республикасында үтә. Инде хезмәтен тутырып, кайтып китәргә ике көн калгач, Бөек Ватан сугышы башлана. Беренче көннән үк сугышка кергән әтинең хәрби тормышы бары тик 1948 елда гына тәмамлана.

Сугыштан соң кабат үз эшенә керешә ул. Башта Үзбәкстанда, аннары Илеш районының Тормыш, Ирмәш мәктәпләрендә укыта. Дүрт еллык башлангыч белем бирү учреждениеләрендә үзе үк директор да, үзе үк дүрт сыйныфка укытучы да, өлкән сыйныфларга физика, математика укытучысы да, укытучылар югында немец теле, тел-әдәбият, астрономия укытучысы да булырга туры килә аңа. Мәктәптә җитешмәгән уку-укыту әсбапларын да, драмтүгәрәк өчен декорацияләрне дә, Яңа елда чыршы уенчыкларын да ул үзе ясады. Пьесалар да язды.

Ул чын укытучы иде. Антон Макаренко хезмәтләренә, язучы Аркадий Гайдар әсәрләренә таянып, уен белән хезмәтне бергә алып барды, балаларга кызыклы китаплар укыды, чит ил әсәрләрен тәрҗемә итеп, укучыларда фәннәргә, әдәбиятка карата кызыксыну уятырга тырышты. Балаларны бик яратты. Хәтерлим әле, авылда 12 яшьлек күзе күрмәүче бер кыз бар иде. 9 яшенә кадәр сау-сәламәт булган ул, агачтан егылып төшеп, күз нервларына зыян килгән булган. Тагын бер көчле стресс кичерсә, күрә дә башларга мөмкин, дигән табиблар. Ләкин әти аны көтеп тормый, Уфадан сукырларны укыту алымнарын өйрәнеп кайта да, теге кызга дәресләр бирә башлый. Өч ел дигәндә аны сигезенче сыйныфка кадәр китереп җиткерә. Хәтта буяу карандашларына тамгалар ясап, аңа рәсемнәргә кадәр ясата иде. Мәктәпне тәмамлап аттестат алган көнне ул кызның күзләре күрә башлады.

Без – сугыштан соң әтинең икенче гаиләсендә туган җиде баласы. Рҗүдә апабыз гына Югары Яркәйдә яши, калганнарыбыз барыбыз да Казанда. Әтинең беренче кызы – Дилара апа Ильясованың гына кайдалыгын белмибез. Ул Башкортстанда яшәргә тиеш дип уйлыйбыз, хәзер аңа 80 яшьләр тирәседер. Безнең аны бик тә күрәсебез, танышып, үз арабызга кертәсебез килә.

Диләрә ИЛЬЯСОВА-СӘРВӘРТДИНОВА.
Казан шәһәре.

Фотода: Әтием Муса Ильясов. 1980 ел. Казанда Бөек Җиңүнең 35 еллыгы уңаеннан килгәч төшкән рәсем.

Хөрмәтле укучыларыбыз! Сездән хатлар көтеп калабыз. Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2. e-mail: ssuum@yandex.ru





КОЯШНЫ, ЙОЛДЫЗЛАРНЫ БҮЛӘК ИТӘР ИДЕМ!..

Эльмира
ЗАКИРОВА

Безнең һәркайсыбыз өчен үз әнисе дөньяда иң матуры, иң әйбәте, иң булдыклысы... Берәү дә юк аның кебек! Ул – дөньяда бер!

Әниләребез турында дөньяларыбызны онытып сөйлибез. Күңелдә балачактан ук уелып калган әллә никадәр истәлекләр яңара...

Әни турында язган мәктәп сочинениесе. Әнигә әзерләнгән бүләк. Берничә көнгә генә каядыр китсә дә, әнине юксынып түккән күз яшьләре. Ераклардан әнигә язган сагыну хатлары...

Әнә, Светлана әнисе турында ничек яратып сөйли!

Көлә-көлә төрле мәзәк хәлләрне исенә төшерә (ул беренче тапкыр сыер сауганда, сыерның җилене шешә. Сәбәбен шундук аңлата инде әнисе: сөтен ахыргача савып бетермәгән икән бит!) Иң кирәкле сүзләрне эзләп, ул аның кайбер «тәрбия алымнары»н ача (төнлә кеше бакчаларыннан ак розалар өзеп, әнисенең туган көнендә урланган чәчәкләрне иртән вазага утырта... «Ничек тотмаганнар?!» – ди Светлана шаккатып. Аның каравы, әнисе шундый итеп оялта кызын...) Хатын-кыз матурлыгы серләрен чишә (без аның белән ике дус кыз кебек булдык. Тушь, помада, хушбуйлар ала миңа...)

«Минем ӘНИ – көтеп алып, ниһаять, килеп җиткән бәйрәм кебек ул!..»

Светлана Афанасьева хәзер үзе дә әни кеше. Гаиләләрендә ике кыз, бер малай үсә. Матурлык тудыру, иҗат – аның хоббие да, дизайнерлык эше дә. Ир, балалар, кайнана... Алар белән мөнәсәбәттә инде бу нәзберек яшь ханымның яратуы, бар күңел җылысы, шәп энергетикасы, дипломатик осталыгы, хатын-кыз интуициясе бер гармониядә чагыла. Зур җитәкченең, район башлыгының хатыны булу үзе генә дә никадәр җаваплы миссия бит! Ул сынауларны да «биш»легә башкара Светлана Марсель кызы. Әнисе дәресләре! Тормыштагы иң гадел һәм таләпчән укытучысы әнисе бит!

Баулы мәктәбендә укыганда әниләр турында сочинение язып килергә кушалар. И озак уйлана инде кыз. Аның әнисе бит берәүнекенә дә охшамаган! Үзе чибәр, үзе сөйкемле, үзе уңган... Ул киенүләре! Светлананың әнисе генә шулай булдырадыр! Ни кисә дә килешә! Тегүчесен дә таба, тиз генә тегеп тә бирәләр. Үзе берәр нәрсә уйлап таба, үзе шуны ук тормышка да ашыра! Светлананы «Эльмира Шәйнуровна кызы» дип йөртүләрендә дә әнисенә карата үзенә бер хөрмәт сизелә.

Ә сочинениесен менә болайрак яза ул: «Әнием Эльмира Муллагалиева 1959 елның 15 июлендә Туймазы районы Уязы-Тамак авылында туган. Әтисе Шәйнур бабам белән әнисе Фәния әбием аңа Эльмира дип исем кушкан. Эльмира принцесса дигән мәгънәне аңлата. Нәкъ минем әни! Бик яхшы укый ул, мәктәпнең баскетбол командасында уйный, сәнгать ярата. Үҗәтлеге, эшчәнлеге, тәвәккәллеге – әбиемнән, тәртип яратуы, башлаган эшен ахырынача җиткерүе – бабамнан. Апасы Фәймә белән акыллы, тырыш кызлар булып үскәннәр. Әни Бөгелмәдә техникум тәмамлап, баш бухгалтер булып эшли. Ул көчле хатын-кыз! Маргаретт Митчеллның «Унесённые ветром»ны яратып укуы да юкка гына түгел. Берәр катлаулы хәлдә калса, Скарлетт О'Хара сүзләре белән: «Болар белән башымны катырып та тормыйм хәзер. Иртәгә уйлармын әле», – дип әйтә, ә икенче көнне бар да җиңел генә чишелә дә куя. «Матурлыгы белән хатын-кыз леди булмаска да мөмкин, ә күлмәге чып-чын леди ясый аннан!» Монысын да әни Скарлеттан өйрәнгән!..»

Светлана әнисе турында сәгатьләр буе сөйләп торырга да әзер. Нәрсәнедер исенә төшереп, чылтырап көлеп җибәреп, әле иркә кыз роленә кереп, әле сокланып...

...Инглиз теле, компьютер курсларына язылып, правага укы дип, гел төрткәләп кенә торды әни. Хатын-кыз ире күләгәсендә генә яшәмәскә, үсәргә тиеш, сиңа карап, балалар да шундый булып үсә, ди ул һәрвакыт. Баянда уйныйм, немец, инглиз телләрендә сөйләшәм, машина йөртәм – бар да әни теләгәнчә булды.

...Минем балалар белән мәш килә ул! Кызмый, ачуланмый – җайлап кына үзенекен сеңдереп аңлата. Биштә үк торып, балалар ярата дип, кыстыбый пешереп куя. Шимбә иртүк Арсентийны футбол уйнарга илтәм. Кичтән әниләргә барып кунабыз да кыстыбый белән сыйланып, футболга китәбез. Берзаман уртанчы кызым Рита скрипкада уйныйсым килә ди башлады. Котым очты! Үзем музыка мәктәбенә яратмый гына йөргән идем, баян классында укыдым бит. Ә әни скрипкасын да сатып алды, иң шәп укытучысын да тапты... Әбисе көйләп, тәмле ашатып,Ританы сәнгать мәктәбенә дә, бассейнга йөзәргә дә йөртә. Ә Юля мәктәпне тәмамлауга, аның белән Мәскәүгә китәргә дә риза!

...Мин мәдәният институтында укыганда, әни гел Казанга килә иде. Матур кием алып кидерә, тәмле ашата, косметика алып бирә, суыткычны тутыра да кайтып китә. Минем дә кайтасым килә. Бөгелмәгә самолетка утырып очам. Елап кайтам, елап китәм. Китәсем килми, дип зарлана башласам да, әни гел: «Ярар, ярар, кызым», – дип җайлап-майлап озата...

...Баулыга Сабан туена кайткач, гел җырлый идем. Радиода музыкаль тапшырулар редакциясендә эшләүче туганыбыз Сиринә апа Латыйповага мине тыңлатып, әни тәки морадына иреште бит! Җырчы Гали Ильясовтан вокал дәресләре алдым.

...Әни озак вакыт кайнанасын карады. Әтинең абыйларын шундый матур итеп каршы ала, кунак итә белүе дә иренә карата хөрмәт билгесе ул.

...Әти белән шундый пар килгәннәр! Икесе дә ачык. Көтмәгәндә бәйрәм ясыйлар. Бергә табын әзерлиләр, бергә җыештыралар, бергә ял да итәләр. Әти әнине тәки машина йөртергә өйрәтте бит! Мәҗлесләр җыярга дисәң, аларга гына куш! Шуңа безгә кунаклар да килергә ярата. Әни оста итеп бәлешләр сала. Хатын-кызлар мунча яга, ирләр су ташый. Күңелле итеп җырлашып кич утыралар... Шул матур гадәтләрне үзебезгә дә кертәсем килә.

...Әни зур урында эшләвемне, югарыга күтәрелүемне тели иде. «Син булдырасың!» – дип үстерде ул мине. Үзе бер дә куркып тормый, берәүгә дә аркаланмый, бары үзенә генә ышана, һәм эше барып та чыга! Һич тик утыра торганнардан түгел: Казанда үзенең ательесын ачты, кайбер оешмаларда бухгалтерия эшләрен алып бара. Булдыра, кыскасы!

Әнисе туган көне алдыннан Светлана әнә шундый уйдык-уйдык мизгелләрне исенә төшереп утырды. Бу юлы нәрсә бүләк итәр икән? Мәктәптә укыганда мулине җебеннән салфеткалар чигеп биргәне хәтерендә. И сөенгән иде әнисе! Үсә төшкәч, әтисеннән акча сорап, затлы алкалар алып бүләк итте. Институтта укыганда чәй белән матур чынаяклар алып кайтты. Хыялында ул аны алтын-көмешкә күмде, Җир шарының әллә нинди матур җирләрен күрсәтте. Хәленнән килсә, ай-кояшны, йолдызларны бүләк итәр иде. Бакчада әнисе үстергән купшы дәлияләр, алсу чалма гөлләр, шәмәхә цинияләр җай гына тирбәлә. Нинди рәхәт! Биредә Светлана үзе дә иркә балага әйләнә. Өч баласы янында дүртенчесе булып ул йөри. Ә үзе һаман бер үк сүзләрне кабатлый: «Озын гомер телим сиңа, әни! Сәламәт бул! Әти белән бергә тигез гомер итегез! Сез бик кадерле безгә!»

Фото:гаилә архивыннан

PRESSA



ИМӘН ШАҺИТ...

Лариса
МАЛИКОВА

Үзәге нык бер хатынның үз көче белән рәхәт, бәхетле тормыш коруы һәм саклавы турында балалары, оныклары сагынып искә ала, аның хакындагы хатирәләрне оныкларының балаларына да сөйли; ә икенче хатын ихтыяр көчсезлеге аркасында шул тормышны рәхимсез рәвештә тар-мар итә... Бу хикәят шул турыда.

«Бу фото монда калуын телим... Истәлеккә... Беләм, күпләр өчен ул берни дә аңлатмый. Гап-гади агач... Ә минә минем өчен бу фотосурәткә барысы да сыйган! Хатирәләр, кичерешләр белән тулы үткәндәге тормышым... Балачагым... Әлеге көннәрнең шундый кадерле бер кыйпылчыгы ул! Аңа, әйткәнемчә, әллә ниләр сыйган: иң бәхетле җәйге көннәр, яңа өзгән укроп белән сарымсак кушып пешкән яшь бәрәңгенең хуш исе, әле генә мичтән чыккан кайнар ипи, аның өстенә ягылган алма повидлосы, кәҗә сөте... Аларның тәмлелеге! Минә әбекәй мичтән бөтен өйгә хуш ис тараткан пирогларын чыгара. Үзе матур, үзе кечкенә – орчык кебек кенә... Яулык читеннән көлсу дулкын чәчләре күренә... Үткен зәңгәр күзләрендә никадәр ярату, игелек, мәрхәмәт... Җәй өчен көйләнгән аш-су бүлмәсендәге ул иртәнге чәйләрне, көндезге ашларны ничек ярата идем мин... Минә шул 17 елым әйтерсең тоташ киселеп калды! Ә мин ул йортны һаман да төшемдә күрәм... Ул нигездә хәзер инде чит кешеләр яши... Якты киләчәккә зур өметләр баглап кайчандыр утырткан Имән генә һаман шул килеш. Язмыш җилләренә үч итеп, ябалдашларын тагын да киңрәк җәя, ныгый бара кебек. Иң якын кешеләрем – бабакаем һәм әбекәемне хәтерләтүче ядкарь булып мәңге шулай шаулап утырсын иде ул...»

Бер көнне Инстаграмны актарып утырганда тап булдым мин бу сүзләргә. Һәм әлеге юлларның авторы белән элемтәгә кереп, аның тормышын сөйләтә алдым бит! Ризалаттым! Бу юллар артында гыйбрәтле язмыш (чынлыкта язмышлар булып чыкты ул!) икәнен сизгән идем аны.

...Имән чикләвеген әнисе үзенең энесе белән бакчаларына балачакта утырткан булган. Еллар узган, кечкенә балалар инде үсеп буй җиткән: башлы-күзле булганнар, гаилә корганнар... Ә имән? Имән дә үскән! Көннән-көн югарыга үрмәләгән, ныгыган, кәүсәләре калынайган, ә тамырлары тирәнгәрәк киткән... Аның ябалдашлары күләгәсендә инде оныклар – апалы-энеле ике туган гаиләсендә үсеп килүче кызлар уйный башлаган. Дүртәү булган алар. Көн туса, кызлар һаман шул имән тирәсендә бөтерелгән, хәтта ябалдашларына куыш корып, ятар урынга кадәр җайлаганнар. Имән аларны үз ышыгына алган, җил-яңгырдан саклаган...

Мин тормышымның җанга бик тә газиз булган бу кадерле җирен гел сагынып искә төшерәм.

Әңгәмәдәшемнең иң бәхетле һәм иң якты истәлекләре әнә шул чор – әнисе үскән шул нигез белән бәйләнгән. Ләкин бәхет кенә бу йортка озакка тукталмаган булып чыккан...

– Әнинең энесе спортчы иде – боксер. Ул актив тормыш белән яшәде. Авылга кайткан чакларда да тынгы белми, күп вакыт безнең белән әвәрә килә – походларга ияртеп алып чыгып китә иде. Гаиләсе матур иде абыйның. Хатыны табиб иде. Бар да әйбәт кебек иде. Ләкин... Бәла шулай сиздермичә килә бугай ул. Абыйның хатынына инде гаилә дә, балалар да кирәкмәвен көннәрдән бер көнне бөтенебез аңладык. Ул һәммәсен дә шешәгә алыштырган... Читләрдән яшерүдән күптән узган икән. Без аңладык, абый гына... Кеше барыбер һаман яхшыга ышана, яхшыга өметләнә бит ул: әле соң түгелдер, барысын да төзәтеп булыр дип уйлый. Абый да шундый өмет белән яшәгән иде дә соң... Ә фаҗига аның үзенә килеп кагылды: ул арабыздан китеп барды. Коточкыч хәл: үз өендә, үз диванында ял итеп ятканда аның гомерен өзделәр...

Хатынының беренче никахтан булган улы гаепне үз өстенә алды. Ләкин моңа берәү дә ышанмады. Ул төпле малай иде, әниләрен кулга алсалар, икенче әтидән туган сеңелләренең әтисез дә, әнисез дә каласын аңлагандыр. Абыйның бер кызына – 6, икенчесенә 3 яшь иде ул вакытта...

Бу гаиләнең бәхетсезлеге минә шуннан башлана да инде.

– Абыйның хатыны тагын да ныграк эчүгә сабышты. Кызларга тәрбия эләкмәде. «Әни бүген дә исерек», – дип, күз яшьләре белән елап әбиләргә килеп кергән көннәре күп булды. Тик әниләре азрак айнып, артларыннан килүгә, бар начарлыгын онытып, кичереп, кабат аның белән кайтып китәләр иде. Нинди генә булса да, әниләре бит...

Әти-әнине ярату хисе кешегә туганда ук салынадыр, һәм алар нинди генә булса да, үзләрен ничек кенә тотса да, ул хис беркая да китеп югалмыйдыр, күрәсең. Кызларның үзләрен шулай тотуы опека органнарын да ялгыш фикергә этәргәли.

– Тиздән җиңги – абыйның хатыны – йортын сатып башка авылга күчеп китте. Туганнан туган сеңелләрем коточкыч шартларда үсте. Моның ахыры хәерле булмаячагы билгеле иде инде – кызлар приютка эләкте. Әбекәй кызларның олысын үзенә алып кала алды. Ә кечкенәсен үзебезгә алырга дип, минем әни документлар җыя башлады. Апам белән миңа гаиләбезнең тиздән ишәячәген – абыйның кечкенә кызы да безнең белән яшәячәген аңлаттылар. Әнинең ул чактагы борчылуларын, документлар җыеп изалануларын бик яхшы хәтерлим. Инспектор гына нигәдер гел каршылыклар тудырып торды. Мөгаен, аның нинди дер без белмәгән үз мәнфәгатьләре булгандыр. Еллар үткәч кенә нинди дер кыек эшләре өчен аны җәзага тартканнарын ишеттек. Кыскасы,

Әбекәйнең васыятенә каршы барып, ул картны өйдән чыгарып җибәрә алмадык шул. Әбекәй кичермәс иде...

абыйның кече кызын үзебезгә ала алмадык. Әни өчен ул гомерлек йөрәк ярасына әйләнде... Кызларның икесе белән дә гел аралашып тордык. Балалар йортында калган кечкенә кыз янына да күчтәнәчләр белән еш бара идек.

Бу вакытта инде әбекәй дә тол калган иде. Хуҗалык мәшәкатьләрен берүзе алып бару авылда хатын-кызга җиңел түгел бит. Бәлки, шуңадыр, озакламый әбекәй күршедәге ялгыз бабай белән кушылды – бергә яши башладылар. Тармакланып, куәт алып үскән Имән бу хәлләрнең барысына да шаһит иде: ул, әйтерсең лә бу йортта яшәүчеләргә көч бирергә теләде. Әбекәй башына да күп сынаулар төште шул... Соңгы вакытта ул бик биреште, җанына тынычлык эзләп, гел догада булды. Апам белән мине дә, үзе үстергән оныгын да, читтә үскән оныгын да – беребезне дә догадан калдырмады. Гел безгә бәхет сорады. Еш кына аның тагын гел бер нәрсә сорап Ходайга ялварганын ишетә идем. Һәм ул мине һәрвакыт куркыта, тетрәндерә иде. Аллаһы Тәгаләдән җиңел, тиз үлем сорый иде ул. Теләкләре кабул булды әбекәемнең: нәкъ менә шулай китеп тә барды ул. Өй мәшәкатьләреннән бераз хәл алыйм дип утырган җиреннән мәңгелеккә күчте...

Ә язмыш тәгәрмәче берәүне дә аямыйча тәгәри дә тәгәри...

– Җиңгинең малае төрмәдә передозировкадан үлеп китте. Язмыш аны сындырды, күрәсең... Ә җиңги үзе тормыш төбенә һаман тирәнгәрәк төшә барды. Иренең төп нигезенә дә еш килгәли башлады. Әбекәй үлгәч, шунда яшәп калган теге бабай белән бергәләп эчәр өчен килә иде. Аракыга акча җитмәсә, әбекәй белән бабакайның гомер буе җыйган әйберләрен сатып эчтеләр.

Әбекәй борчак төшкән күлмәк һәм колак алкалары тагарга ярата иде. Аның бизәнү әйберләре белән тулы тартмасын актару безнең, кызларның, иң яраткан шөгыле иде. Әбекәй гел: «Борчак бизәкле күлмәк күрсәм, йөрәгем әллә нишләп китә», – дия торган иде. Үләренә күп тә калмаган иде инде, ул тагын шундый бер яңа күлмәк сатып алды. Көзге алдында аны киеп сөенүләре әле һаман күз алдымда, әмма киеп туздырырга гына насыйп булмады... Әбекәйне соңгы юлга озатканда, шкаф ишеге кинәт шыгырдап ачылып китте һәм ишек ярыгыннан шул күлмәкнең итәге күренде. Әйтерсең хушлаштылар... Әбекәй әле бәйләү бәйләргә дә бик оста иде, свитер, оекбашлар гына да түгел, өен ул үзе бәйләгән челтәрләр белән дә бизи иде. Кызганыч, боларның барысы да юкка чыкты – әрәмшәрәм булды. Аның кул җылысын саклаган, ул яраткан, без яраткан әйберләр... Кадерле әбекәем бөртекләп булдырган, озак еллар күз карасыдай саклаган дөньяның күз алдында менә шулай меңләгән кисәкләргә таркалып юкка чыга баруын күрү түзә алмаслык авыр иде. Бары Имән генә элеккечә иде: әйтерсең ул боларның барысын һаман сакларга тели, әйтерсең берни дә үзгәрмәгән...

Абыйның олы кызы әчкече әнисе белән үсте. Әнисе һөнәрен сайлап, медицина көллиятенә укырга керде. Әмма балачактан әйләндереп алган мохит үз җимешләрен бирә башлады – ул да начар юлга кереп китте: алкоголь, наркотиклар... Берчак Казанга безгә кунакка килде, һәм хәтта шул вакытта да үз ишләрен табып, кәеф-сафа корып йөрде. Хәтерне бик калдырды... Кайтып киткәч тә берничә тапкыр шалтыратты әле ул. Көннән-көн тормышның төбенәрәк тәгәри баруы телефон аша да сизелә иде. Бәлки ялгышым булгандыр: тик мин аңа башка шалтыратмаска куштым. Безнең уртак сөйләшер сүзләр дә кимегәннән-кими бара иде бит инде...

Күп тә үтмәде, әбекәй өендә ут чыкканын ишеттек: хуҗа төтенгә булыгып үлгән, диделәр... Әниемнең туган нигезе белән бәйләнеш шулай итеп бөтенләй өзелде. Бары хатирәләр генә калды... Моның өчен иң кайгырган кеше әнием булды, әлбәттә.

Еллар уза торды... Без дә буйга җиттек. Кайчандыр имән төбендә уйнап үскән кызлар инде үзебез әни булдык. Тормышка мөнәсәбәтләр, карашлар да үзгәреп тора: сабырландык, күп нәрсәнең кыйммәтен башкача аңлый башладык. Туганнар кадере дә артты. Хәзерге интернет заманында кайчандыр югалган элемтәләрне торгызу бер дә кыен түгел ул. Күптән түгел без дә бер-беребез белән табыштык. Менә шатлык: абыйның олы кызы теге афәтләрдән арынып өчен көч тапкан бит үзендә! Бүген үзе шул ситуациягә эләккәннәргә булыша икән. «Вконтакте»дагы битеннән укып, аның да балачак елларын сагынуын аңладык. Кечкенәсе дә укуын тәмамлап, инде эшли икән.

Әлегә телефон аша гына хәбәрләшәбез, әмма тиздән ял алып, әниләрнең туган авылына кайтырга җыенабыз. Бөтенебез бергә! Ничә еллар аерылышып торганнан соң, кабат Имәнебез янында күрешергә сөйләштек. Безнең – кыз туганнарның яраткан урынында!

...Имән ышыгында әбекәй рецепты буенча яшь бәрәңге пешерербез. Мин улларыма әбекәй белән бабакай турында, бу йорт, Имән белән бәйле бәхетле мизгелләр турында сөйләрмен... Аларның да мине аңлавын, безнең гаиләдәге кискен борылышларның сүзсез шаһитын яратуларын бик телим...

БЕР-БЕРЕГЕЗГӘ КҮЛМӘК БУЛЫГЫЗ



Илнар хәзрәт ЗИННӘТУЛЛИН, «Туган авылым» мәчете имам-хатыйбы

Хатыннарның ирләре каршында нинди бурычлары бар?

– Беренчесе – итагать, ягъни ирнең сүзен тыңлау. Пәйгамбәребез: «Әгәр дә хатын-кыз намазын укыса, уразасын тотса, үзен зинадан сакласа һәм иренә буйсынса, аңа: «Җәннәтнең кайсы ишегеннән керәсең килә, шунсыннан кер», – дип әйтерләр», – ди. Иренә буйсыну хатын-кыз өчен аерым гыйбадәт булып санала. Аның төп нигезе – каршы дәшмәү. Кайвакыт хатын-кыз ир кеше әйткәнне үти, ләкин мең сүз белән. Бу очракта ул үтәмәүгә тиң.

Икенчесе – хатын-кыз җенси якынлыкка каршы килергә тиеш түгел. Әлбәттә, сәбәп булмаса (күрем вакыты, Рамазан уразасы, авыру). Юк, дип әйтү ир кешенең кәефен җибәрә. Һәм ир кеше башка синең яныңа якын килмәскә, күңеленә башкалар керә башларга мөмкин. Пәйгамбәребез: «Ир кеше чакырган вакытта хатын-кыз сәбәпсез «юк» дисә, таң атканчы фәрештәләр аңа ләгънәт кылыр», – ди.

Хатын-кыз нәрсәдер эшләргә җыенса, башта ирдән рөхсәт сорарга тиеш. Әйтик, кемнедер кунакка чакырасы килсә. (Хәтта әти-әнисен чакырса яки үзе аларга барса да.) Бездә хатын-кыз бергә яши башлагач, буталып – «онытып» җибәрә: «Монда мин дә хуҗа», – ди. Әмма өйдә ир кеше хуҗа, өйдәге мал – аныкы, тәртип аңа буйсына. Хатын-кыз каядыр барасы булса, өйдәге акчаны тотарга теләсә (сәдака бирәсе, кемгәдер ярдәм итәсе, күршегә биреп торасы килсә) иреннән рөхсәт алырга тиеш. Хәдистә пәйгамбәребез: «Әгәр ирнең рөхсәтеннән башка хатын-кыз өйдән чыгып китсә, ул кайтып кергәнче фәрештәләр ләгънәт кылып торыр», – ди.

Яхшы сыйфатларның берсе – ирдән риза булу. Ул алып кайтканны риза булып кабул итә белү. Хәтта эшләп тә акча алып кайта алмаса яки күп эшләп тә, аз алып кайтса, моны аңлап, риза һәм канәгать була белергә кирәк. Ир кеше бот күтәреп өйдә ятса, бу – икенче мәсьәлә.

Хатын-кыз ире алдында берәр начарлык эшләсә, гафу үтенә белергә тиеш. Пәйгамбәребез: «Хатынына ирнең ачуы килсә, ул хатынның намазлары да кабул булмый, савапсыз була», – ди. Әгәр хатын-кыз ир кешенең ачуын китерсә, гафу үтенмәсә, хур кызлары җәннәттә: «Сиңа ләгънәт булсын, син аның кадерен белмисең, тиздән ул безнең яныбызга килер, без аның кадерен белербез», – дип әйтерләр ди. Ир кеше кәефсез кайтса, яхшы хатын аның янына килеп: «Кадерлем, күреп торам, кәефең юк, әгәр берәр гаебем булса, гафу ит. Кәефеңне күтәрү өчен нишли алам?» – дияргә тиеш. Бүгенге көн өчен бу фантастика инде. Хәзер, киресенчә, ирләр хатын-кызны көйли.

Хатын-кыз ирнең әти-әнисен ихтирам итәргә, аларга тел-теш тидерергә тиеш түгел. Ир кеше өйләнсә дә, беренче урында әти-әнисе кала. (Хатын-кыз кияүгә чыккач исә беренче урында ире булырга тиеш.) Әгәр хатын-кыз кайнатакайнанасына яхшы мөгамәлә күрсәтсә, ир дә аның әти-әнисенә рәхмәтле булачак: моны аяк терәп, тавыш чыгарып сорарга кирәкми. Ир әти-әнисенә ярдәм иткән очракта, аңа дәгъва белдерелергә тиеш түгел, чөнки бу – аның вазыйфасы. Әмма, әлбәттә, монда да чама булырга тиеш.

Хатын-кыз гаурәтләрен капларга – яулыксыз йөрмәскә, кыска итәк кимәскә, күлмәк изүен ачмаска тиеш. Ире генә күрергә тиеш матурлыкны башкаларга күрсәтү – ирнең аңа өйләнү сәбәбен юкка чыгара.

Ирнең дәрәҗәсен төшерерлек серләрне, кимчелекле якларны ачмаска тиеш. Коръәни-Кәримдә «бер-берегезгә күлмәк булыгыз» диелгән. Боларны бигрәк тә үз әти-әниеңә сөйләргә кирәкми: чит кеше ишетә дә оныта, ә аларның күңелендә авыр булып кала.

Хатын-кызның иң мөһим бурычларының берсе – бала тәрбиясе. Ашату, эчертү, киендерү – ир кеше өстендә. Ә хәләл ризык, беренче догалар – әнидә. Бигрәк тә әтигә булган мөнәсәбәт: әни ничек тәрбияләсә, балалар әтигә шулай карый. Ләкин бала белән ир арасында, хатын-кыз өчен ир – беренче урында. Табын янында беренче ризык атага бирелә, моны бала күрергә тиеш. Шуңа күрә яхшы хатын алган ир – бер аягы белән җәннәттә, начарны алганы – бер аягы белән тәмугта, ди пәйгамбәребез.

Ир-атка ашарга пешерү – хатын-кызның бурычымы?

– Ирләрегезгә ашарга пешерегез, керләрен юыгыз, дигән сүзе юк пәйгамбәребезнең. Әмма үзенең тормышында аның хатыннары ашарга да пешергән, өй эшләрен дә алып барган. Димәк, бу табигый күренеш дигән сүз. Пәйгамбәребез шуңа махсус әйтми дә. Бу хакта хәдис булмаганга күрә, кемдер: «Ашарга пешерү – хатын-кызның вазыйфасы түгел», – ди. Ул очракта хатын-кыз бала табучы инкубатор гынамыни? Әмма өйдә эшләре бик күбәеп китсә, хатын-кыз ярдәмче сорарга мөмкин. Динебездә бу каралган. Ярдәмче яллау гаилә бюджетына зур зыян салачак. Су ташый-ташый иңбашлары уелып беткәч, кызы Фатыйма пәйгамбәребездән ярдәм сораган. «Көненә 33 әр тапкыр «сөбханалла», «әлхәмдүлилләһ», «Аллаһу әкбәр» дип әйт – зикер кыл, бу, хезмәтчегә караганда, зуррак ярдәм булыр», – дигән пәйгамбәребез.

Хатын-кыз нинди бурычлардан баш тарта ала?

– Ирне тыңлауның да чикләре бар. Хатын-кызга тиешле булмаган, сәламәтлегенә зыян китергән, дингә каршы килгән нәрсәне сораса, хатын-кыз иргә буйсынмаска хаклы. Тавышланмыйча, матур гына баш тарта ала.



ИСТАНБУЛ РИТМЫ



Гөлүсә ЗАКИРОВА

Диңгез ярындагы илләргә зәңгәр дулкыннары белән хозурлану өчен сәфәр чыгалар дип уйлый идем. Ул чакта 15 миллион кеше яшәгән Истанбул дигән таш калага барып чыгасымны һәм... яратачагымны күз алдына да китермәгәнмен.

Кызыктырдылар...

Төркия татары Якуб Акчура белән Фейсбукта дуслар идек, аралашып тордык. Бер хатта татар кызына өйләнергә теләге барлыгын белдерде ул. Бөтендөнья татар конгрессының чираттагы корылтаена кайтырга җыенган чагы иде. Ә күршем Айзирәк Гәрәеваның эштән киткән көннәре. Тоттым да таныштырдым! Һәм... оныттым. Ә яшь йөрәкләр уртак тел табарга да өлгергән булып чыкты, алай гына да түгел, Якубның шул кайтуында никах та укытып куймасыннармы! Җыелышып, матур теләкләр әйтеп, Истанбулга озаттык аларны. Менә шуннан соң башланды...

Беренчедән, яучылыкның җаваплылыгын аңлау килде. Айзирәк миңа үпкәләп ятмый микән чит кыйтгаларда? Элемтәдә булсак та, ахирәтемнең сер бирми торган үҗәт холкын да беләм ич.

Икенчедән, Айзирәгем бик актив язарга кереште. «Идел» журналында Төркиядәге татар авылы – Госмания Корыһөйүк тарихы турында, Истанбулдагы татарлар язмышы хакында саллы гына язмалары басылды. Төркиядәге татар нефтьчесе турында мәгълүматлар эзләп табып, «Ка зан утлары» өчен повесть язып җибәрде. Аларны укыгач, миндә эчке бер кызыксыну уянды. Моңарчы курорт шәһәрләрен генә күргән кешегә, Айзирәк әйтмешли, җырлый

Мәчетләрнең мәзиннәре ярыша ахры,

дип тә уйлап куясың: кайсы тарафка борылсаң да, бер-берсен уздырырга теләгәндәй, азан кайтавазы...



торган мәчетләр каласын күрү ипи өстенә яккан май кебек кенә булыр дидем.

Юрганыңа карап суз

Бурычка батмый гына да дөнья гизүнең мең төрле җайлы ысулы бар. Истанбул – шундый сәяхәтләремнең чираттагысы. Тур алган очракта бермә-бермә күбрәк түләргә туры киләчәк: без үз җаебызга барырга булдык. Авиакомпанияләр кайчак шундый шәп акцияләр тәкъдим итеп куйгалый. Алар, билгеле, бик тиз юкка да чыга, шулай да тиз арада хәл итеп, бик арзан сумга гына билетлар юнәтү мөмкинлеге бар. Баргач, торыр урын да кирәк. Анысын хәл итүнең бер авырлыгы да юк. Миңа җылы өйне хәтерләткән бутик-отельләр ошый. Истанбулда исә алардан күп нәрсә юк. Көндәшлек зур булгач, сыйфат та начар түгел, кайберләре иртәнге аш белән дә сыйлый, теләсә кайсы вакытта чәй, кофе ясап эчәргә була. Вай-фай бар, юыныр урыны, ак сөлгеләре... Тагын ни кирәк? Без отельдә ятар өчен килмәдек лә!

Ашау мәсьәләсе. Бер генә киңәш: туристлар күп булган урыннарда түгел, ә төрекләр үзләре сыйлана торган кафеларны сайларга тырышыгыз. Хакы да күпкә арзан, тәме дә башка. Экскурсиядә йөргәндә үтереп карыны ачкан кешеләргә чат саен симит, каштан, кукуруз сатып торучылар ярдәмгә килер. Дүнерләре дә туклыклы. Миңа аеруча ясмык ашы ошады. Туристлар кайнашкан урыннарда да бәясе биш-алты лира тирәсе генә, тәмле дә.

Ыгы-зыгылы тынлык

Без шәһәрнең тарихи үзәгенә – Солтанәхмәт мәйданы тирәсенә урнаштык. Туристларның күп булуы да, беренче көннәрдәге тымызык яңгыр да кәефне төшермәде. Хәер, Истанбулда һава торышын аязучан болытлы һава дип билгеләргә буладыр: Босфор бугазыннан искән җилләр әллә нинди кара болытларны куып китерә дә, күз ачып йомганчы алып та китә. Тымызык яңгырдан соң, шәһәргә сафлык иңгәндәй була. Ул да түгел, гадәти шау-шу, ыгы-зыгы башлана, рельсларыннан шуышкан трамвайлар чыңы, Мәрмәр диңгезен урап кайткан симез акчарлакларның әче кычкыру авазлары ишетелеп ала. Шушы җанланышның үзгә бер тәме борынны кытыклый: яңа гына мичтән чыккан симит, кыздырылган каштан чикләвеге исе... Авылда бәрәңге алганнан соң, учак көлендә тәгәрәтеп пешерелгән бәрәңге бит бу дип ымсынасың... Тик чикләвекнең тәме бәрәңгенеке түгеллеген белгәч, бераз гына кәефең киткәндәй була. Әмма монда ритм башка: сыктап торырга вакыт юк. Әнә урамдагы исләрнең тагын бер нотасы борынны иркәли: каһвә исе... Монда аны бик тәмләп эчәләр. Үтә күренмәле чынаяктан бер йотым чиста су да бу тәмнең затлылыгын арттыра. Шунда синең кабалануыңны үзгә бер фәлсәфә белән күзәткән урам мәчеләренә күз төшә. Үз көйләренә мырлап кына яши алар монда... Ул да түгел, озын тәртәле, зур полиэтилен капчыклы кул арбасын сөйрәп, чүп җыючы малайлар үтеп китә. Тротуарга алтынсу шкатулка сыман савытын көйләп, башмакчы чыгып утыра. Һавага аяк киеме кремы исе тарала... Ә аннан соң калебеңнең эчке җепселләре дә куырылып килерлек азан тавышы яңгырый.

Зәңгәр мәчет – Истанбулның символы. Ислам һәм дөнья архитектурасы шедевры! Солтан Әхмәт I идарә иткән чорда төзелгән, берьюлы ун мең кешене сыйдырырлык иң гүзәл һәм күркәм Аллаһ йорты. Ул вакытта Госманлы империясе берьюлы ике сугыш алып бара: Австрия һәм Иран белән көч сынаша. Әмма җиңелүгә дучар була. Солтан, бу хурлыкны күтәрү өчен Аллаһтан ярлыкау сорарга ниятли һәм мәчет салырга боера. Моңарчы төзелешләр сугышта ирешелгән байлык бәрабәренә башкарылса, бу юлы солтанга үз казнасын юкартырга туры килә. Архитектор Сәдәфкар Мәхмүт Ага остазы – Бөек Синанны уздырырга ниятли. Җиде ел төзелгән мәчет диварлары егерме меңгә якын ак-зәңгәр төсләрдәге керамик эшләнмәләр белән бизәлә (менә ул Зәңгәр мәчетнең исеме кайдан!). Солтан исә илнең

Төрек ризыкларын сәяхәттә дә ашамагач, тагын кайчан авыз итәргә җыенасыз?



■ Сөләймания мәчетен Сөләйман солтан боерыгы буенча олуг архитектор Синан төзи. Мунчасы, мәдрәсәсе, обсерваториясе, кухнясы, китапханәсе булган зур комплекс. Тагын... Сөләйман солтан үзе дә, сөекле хатыны Хюррем да бирегә җирләнгән.



төрле почмакларыннан иң матур үрнәкләрне китергән фабрикаларга аларны башка берәүгә дә сатмаска боера. Шулай итеп, керамика белән шөгыльләнүче осталарның да эше комга тереләә. Аһ, аларның матурлыгы: бер лалә чәчәгенең генә дә 50 төрле сурәте бар. Сүрәләр язылган эшләнмәләр күз явын ала. 260 тәрәзәдән төшкән кояш нурларыннан келәмнәр тагын да затлырак күренә...

Мәчеткә бөтен кешене дә кертәләр. Ишек катында аяк киемеңне пакетка саласың да, үзең белән кыстырып, хатын-кызлар залына узасың. Шуңа игътибар иттем: ишекләре бик тәбәнәк. Баксаң, ул Аллаһтан олы булмавыңны тою өчен махсус эшләнгән икән. Хәтта солтан булсаң да, сине барыбер өч аршын җир көтә... Җомга вәгазе ике сәгатькә якын укылды. Мәчеттә алма төшәрлек тә урын юк кебек. Костюм кигән, галстук таккан дәүләт эшлеклеләре дә, башларына чалма ураган дин әһелләре дә, балалар да... тын да алмый аны тыңлап утырды! Ник берсе кузгалсын! Рәт-рәт булып намазга баскач, җан авазы булып күздән яшь ага башлады. Бу кадәр рухи чистарынуны көтмәгән идем...

Төрекләргә тагын бер кат сокलануымны яшерә алмадым: «Мөхтәшәм йөз ел» («Великолепный век») киносын төшереп кенә дә, милләтләренә, солтаннарына, тарихка һәм мәдәниятка мәхәббәт тәрбияли алган олуг халык! Әнә «Сөләймания»дә дә чит мәмләкәтләрдән килгән сәяхәтчеләр Сөләйман солтан, кызы Миһримаһ, хатыны Хюррем, улы Мәхмүт каберләре каршында баш игән. Минем дә куллар догада: төрек солтаны өчен генә түгел, үзебезнең Колшәриф мәчете каршындагы ханнар төрбәсен, Болгардагы ханнарның мәсхәрәләнгән кабер ташларын күзаллап, ярлыкау сорыйм... Ходай кичерсен инде безне...

Акчарлаклар селфи төшә

Сөләймания мәчете бакчасыннан карасаң, Босфор бугазының аргы ягында борынгы бер манарага күз төшә. Галата манарасы! Шактый биек, борынгы һәм... үзенең тарихи йөзен югалткан тарихи урын. Нигәме? Манара эченә бүген... лифт корып куйганнар. (Заман уңайлыклары тыгылдымы – борынгылыкның эзе дә калмый!) Галата манарасы хәзер төнге клуб һәм рестораны белән күбрәк данлыклы бугай. Ә көндезен шул лифт туристларны ташый. Шунда менеп шәһәргә күз ташлау өчен җитмеш биш лира түләргә кирәк. Күбрәк... Әмма уч төбендәге Истанбул үзгенә баккач, янә бер сөенечтән балкып аласың. Аеруча акчарлакның синең белән селфи төшкәнен күргәч...

Анысы да монысы... Истанбул базарларында сатуалу – чын сәнгать. Капалы Чарши (Гранд-базар) сәүдә рәтләрендә көненә ярты миллион кеше йөри икән. Шулай булмый ни! Шәһәрнең иске өлешендә, 61 урамга җәелгән 4400 кибет бит ул! Күз алдына китерәсезме? Мин аның бер урамын урап чыкканда да хәлдән тайдым, ярый лимон суы сатып йөрүче төрек агае очрады. Аркасына аскан кувшиныннан лимон суы агызып, шуңа яңа түтәлдән өзеп алган бөтнек яфрагы сала...

Капалы Чаршы

Константинопольне алганнан соң ук төзелә. Барысы унсигез капкасы булган базарда XIX гасыр урталарына кадәр колларга кадәр саталар. Зәркәнчеләр, антиквариат, келәмнәр, сувенирлар, тукыма, тире, керамика һәм агач эшләнмәләре... Бәяләре кыйммәтрәк билгеле (күбрәк туристлар кесәсенә өмет итәләр бугай). Эминүню тирәсендә Мысыр Чаршысы (Мисыр базары)



■ Баттал Гази төрбәсе тау башына урнашкан. Заманында биредә мәдрәсә, мәчет, ашлык сарайлары булган. Мәчет хәзер дә гамәлдә. Ишегалдында дәрвишләр көе уйнап тора. Һәм бу табигый да...

да бар. Кучтәнәчләрне аннан алу хәерлерәк. Хаммам белән дә шул ук хәл: туристлар күп булган урыннарда йөзәр евро сорыйлар. Төрекләр яшәгән кварталларда егерме лирага да табарга була.

Барыр идем, илем ерак...

Төркиядә яшәүче татарларның санын төгәл беркем дә әйтә алмый торгандыр. «Ун меңнән күбрәк», – ди Якуб. Аның тамырлары – кайчандыр Татарстаннан күченеп килгән татар авылы – Госмания Корыһөйүктән. Лениногорскиның Сарабиккол авылыннан чыкканнар. Мөһаҗирлек тамырлары 1917 елгы инкыйлабка кадәрге чорга туры килә. Төркиядә сыену урыны тапкан беренче татарлар 1683 елларда ук теркәлә, алар Степан Разинның уңышсыз түнтәрелешеннән соң, православие диненә күчәргә теләмәгән өчен, җирләре һәм милкеннән коры калган татарлар була. Госманлы империясенә алар мөселман булып калу өчен күченә.

Татарлар читтә дә татарлыгын югалтмаган. Госманлы Корыһөйүк авылына барып чыккач, моңа тагын бер кат инандым. Күченеп килгән мәлдә иң беренче эш итеп мәчет корып куйганнар. Мәчеткә терәлеп диярлек үк төзелгән янкорма мәдрәсә вазыйфаларын башкара, аннан мәктәп булып хезмәт итә. Дөрес, соңгы елларда балаларны төрек мәктәпләренә автобус белән алып китәләр. Янкорманы Казан татарлары мәдәни үзәге итеп үзгәрткәннәр.

Казаннар килгәнне ишетеп, тирә-күршеләр агыла башлады. Макбулә әби шушы авылда элек-электән җан авазы булган «Хәсрәт җыры»н көйли башлый. Ул салмак тавыш белән җырлый, ә минем йөрәк елый.

Ап-ак идем, ак каз идем, сусыз җирдә каралдым,
Ак чырайлы малай идем, хәсрәт белән саргайдым.
Без китәсе юлларның чит-читләре казылган,
Безнең болай буласыбыз язмышларга язылган...

Әйе, Төркиядә яшәүче татарлар да туган телләрен, милли гореф-гадәтләрне югалтып баралар. Очрашуга килгән татарларның күбесе инде төрекчә сөйләште...

Аннан Зөлфәт Хәким җырларын тыңлый-тыңлый, Сәет Баттал Гази төрбәсенә юл тоттык. Бу шәхес турында ишеткән бар: VII гасырда дин өчен көрәштә батыр даны алган кеше, Мөхәммәт (с. г. в.) пәйгамбәрнең оныгы! «Батталнамә» дигән китапта аның шактый гына батырлыклары, Аллаһка булган мәхәббәте сурәтләнә. Үлеме турында мондый риваять язганнар: сугыш вакытында 60 яшьлек Баттал Гази Византия королен кирмәненә кадәр куа бара һәм... диварга сөялеп, беразга гына йокымсырап китә. Үзенә якынлашкан атлы гаскәрләрне дә сизми. Әмма Византия короленең Баттал Газига гашыйк кызы, аны уятырга теләп, өстән кечкенә генә таш кисәге ата. Кирәк бит: таш батырның нәкъ йөрәгенә тия һәм үлеменә сәбәпче була. Нинди куркыныч сугышларда да сер бирмәгән көрәшче мәхәббәт ташыннан җан тәслим кыла...

Аны күпләр әле дә үзенең рухи атасы дип саный. Менә ни өчен каберенә әллә кай тарафлардан да киләләр. Баттал Газиның рухи фәлсәфәсе – рухи кыйммәтләр өчен көрәштән гыйбарәт. Иң зур һәм авыр сугышны ул үзенең нәфесе белән көрәшү ди.

Истанбулга юл тоттык. Юл ерак, башта уйлар күп... Искешәһәрдәге йортында татар дөньясы турында язудан тәм тапкан татар кызы Айзирәккә Актаныш балы белән бер уч илһам калдырып китеп барыш... Хәләле белән татарлар турында бөртекләп мәгълүмат җыйганда илһам комачауламас...

Тархана шулпасы



Бик хикмәтле аш икән Төркия татарларының элек-электән яратып пешерә торган шулпасы. Аерым бер осталык кирәк, ди Айзирәк. Аны кайнанасы өйрәткән. Онын алдан әзерләү хәерлерәк (базардан да алырга була). Помидор, борыч, суган, катык (йогурт), он, тоз, чүпрә кушып болгатып, ваклап, йә кояшта, йә мичтә киптерәсе. Манный ярмасына охшаган кызыл он булып чыга ул. Аннан кәстрүл төбенә зәйтүн мае салып, берничә тырнак сарымсак турап кыздырасың. Шуңа бер олы кашык томат соусы салып бутыйсың. Бераз тоткач, өч-дүрт олы кашык тархана онын саласың. Болар өстенә акрын гына салкын су агызасың. Он укмашып китмәсен һәм кәстрүл төбенә утырмасын өчен, гел болгатып торырга кирәк. 10-15 минутта аш әзер!

«ХАТЫННАРНЫҢ ҺӘМ ИРЛӘРНЕҢ БӘХЕТЕ ДӘ ҮЗГӘ...»



Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя... Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик.

Марат ХӘБИБУЛЛИН,
Г. Тукай исемендәге
Әтнә дәүләт драма театры артисты,
Татарстанның атказанган артисты;
гаилә стажы – 26 ел.

1 Иң элек хатын-кызның нәрсәсенә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Тегүче булсам, киеменә, дип җавап бирер идем, мөгаен... Минем бер танышым бар – малайларның волейбол командасы тренеры, үз эшенең фанаты – ул хатын-кызның буена гына игътибар итә. Аның үз логикасы: «Озын буйлы хатыннарның малайлары да озын була, ә озын буйлы малайдан волейболчы «ясарга» мөмкин», – ди. Ә мин беренче күрүдә хатын-кыз затын гомумән генә бәяли алам: «сөйкемле... чибәр... тыйнак... үткен...» Ә соңыннан аның нәрсә кигәнен дә, күзләренең төсен дә, хәтта көлмәгәненең төсен дә исемә төшерә алмыйм, шул беренче фикер генә иска килә.

2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?

– Яшь арагыз күпме, мөнәсәбәтләрегез нинди булуга карап, вакытын һәм урынын исәпләп, хатын-кызның барлык сыйфатларын да гафу итәргә була.

3 Ә нәрсә өчен бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?

– «Яраткан хатын-кызга бөтен нәрсәне гафу итеп була», дип йомры гына җавап бирәсе иде дә бит, тик... Тик сынау килгәч кенә сабырлыкның чиген белеп була. Аллага шөкер, «Сөембикә» журналы куйган сорауны тормыш минем алга куйганы юк әлегә кадәр. Моннан соң да: «Иң якын кешемне гафу итимме, әллә кичермимме?» дип газапланырга язмасын. Беркемгә дә. Беркайчан да.

4 Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм өйдә аның өчен комфорт тудыручы хуҗабикәләр. Сезгә аның кайсы якынрак?

– Бу яктан мин бик бәхетле – тормыш иптәшем Раузалия ике якны да үзенә сыйдырган. «Ярым җүләр үзен мактар, чи җүләр хатынын мактар», дип, борын төбемә татар мәкальләре җыентыгын төртергә ашыкмагыз – фикеремне дәлиллим. Минем өемдә яраткан кәнәфием бар, кайчак, шуңа тамыр җибәргәндәй берегеп, алдыма ноутбук алып тәүлек буе нидер язарга маташып утырам. Шул чакларда кухнядан Раузалия чыгарган тәмледән-тәмле исләрдән дә ныграк илһам чыганагы юк минем өчен!

Һәм тагын. «Тормыш – театр», дигән Шекспир. Театрдагы кебек, тормышта да гел бертөрле генә рольләр башкарырга ярамый – тамашачы, ягъни әйләнә-тирәдәгеләр бик тиз туярга мөмкин. Айлар, еллар буе тәүлекнең егерме дүрт сәгатендә янәшәңнән илһамландыручы муза китми ятса – ычкынырсың! Ә мамыкка төргән кебек, өзлексез комфорт белән әйләндереп алсалар, зоопаркта читлектә яшәгән аю сыман, симереп, ваемсызланып бетәрсең. Без – ир-атның да «бер амплуа актеры» булуын гына теләмидер хатын-кызлар: вакыты белән малтабар да, вакыты белән рыцарь да бул аларга, кайчак – романтик, ә кирәксә – прагматик... Башлы хатын-кыз аңлый: «чеп-чи Хәлил» белән мәхәббәт кенә матур, ә тормыш итеп бетерүләре, ай-һай, җиңел булмаска мөмкин – аның өчен ирдә бераз «Исмәгыйль каны» булу да кирәк.

5 Ир кеше өчен аның хатыны дус та була аламы?

– Һичшиксез! Тикмәгә генә татарда «тормыш иптәше» димиләр бит инде. Башка телләрне әйтә алмыйм, әмма рус телендә андый төшенчә юк. Чагыштырып карагыз: «спутница жизни» һәм «тормыш иптәше» – тормыш юлдашы түгел! Юлдаш очраклы кеше дә булырга мөмкин, ә иптәш – ул башта сайлана, аннан сынала... Минем иң якын ике дустымны берсе – хатыным.

«Британия галимнәре исәпләп чыгарган», дигән әйтем афоризмга кереп бара инде. Чыннан да, күзләре нәрсәгә төшә, шуны исәпләп күнеккән Британия галимнәре мәхәббәт тойгысын да бизмәнгә салган һәм, көнләп-сәгатьләп, күпме дәвам иткәнен исәпләп чыгарган. Нәтиҗәләре кырыс: шашып гашыйк булу мәңгелек була алмый. Баксаң, мәхәббәт кебек тирән хис кичергәндә кеше организмы эшчәнлеге тулысынча диярлек үзгәрә, гади итеп әйткәндә, форсаж режимына күчә. Зур тизлектә машинада баргандай, кичерешләр кискенләшә, адреналин ташый... Әмма техника форсажда озак эшли алмаган кебек, организм да хисләр ташкынында озак «тарта алмый» – ул йә суынырга тиеш, йә таркалуга дучар. Машинада баргында бер газга басып, двигательне үкертеп, канны кыздырып аласың да, шуннан тизлекне киметеп, әйләнә-

тирәдәге матурлыкларга күз салып, юлдан да игътибарны алмыйча, тыныч кына бара башлыйсың. Мәхәббәттә дә кайнар хисләргә алмашка бер-берең ихлас хөрмәт, бер-береңнең иңен тоеп яшәү килсә, выжылдап узып китүчеләргә игътибар итмичә, юл читендә ватылып-бәрелеп калганнардан гыйбрәт алып, тормыш юлын тыныч һәм матур итеп узарга була, минемчә.

6 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганыгызны хәтерлисезме?

– Хәтерлим. Мин икәүдән-икәү генә тәкъдим ясарга шүрләдем – Аллам сакласын, риза булмаса! Борынгыча, Раузалияне сорарга яучылар белән бардым. Анда да әле, нәселебезнең өлкән ир-аты – олы абыем белән генә чикләнмичә, «авыр артиллерияне» җәлеп иттем: гаиләбез дусты, шул ук вакытта Раузалиянең туганнан туганы Хәмит абыйны һәм ул чакта икебез дә бергә эшләгән «Әтнә таңы» газетасы баш мөхәррире Марс абыйны чакырдым. Янәсе, үз абыйсына һәм җитәкчебезгә «отказ» бирә алмас. Белмим, дүртебездән кайсыбызның дәлилләре саллырак булгандыр – үземнеке дип уйлыйсы килә, әлбәттә – әмма әбием Зәйтүнә миңа кызын бирергә ризалашты. Өч яучыга да, әбиемә дә – исәннәренә саулык, мәрхүмнәргә җәннәт сорап, бүген дә рәхмәт укыйм.

7 Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый диләр, шулаймы?

– Тормышта андый хәлләр була, ләкин бу минем очрак түгел. Мәрхүм психолог Зигмунд Фрейд андый күренешләрне гаиләдә хакимлек иткән хатыннарның уллары белән бәйли иде бугай. Мин белгән мисалларда, әнисенә охшаган хатын белән яшәгән ирләр бик үк бәхетле түгел шикелле, һәрхәлдә, читтән караганда. Әлбәттә, хатын белән әни, бер-берсенә охшап, ике фәрештә булсалар шәп булыр иде! Бер түбә астына ике фәрештә сыюы гына икеле...

8 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар. Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?

– Ә ул бу очракта ир кеше булмый инде! Аллаһы Тәгалә ирләрне һәм хатыннарны төрле итеп яралткан, төрле вазыйфа йөкләгән һәм төрле хокуклар биргән. Безнең театрда кызлар, бер-берсен котлап, «хатын-кыз бәхете телим», дип язалар. Һәм бу дөрес тә! Хатыннарның һәм ирләрнең бәхете дә үзгә. Миңа калса, әзмәвердәй ире барында гаиләдә үзе баш булырга тырышкан хатын-кыз да, ирлек сыйфатларын югалтып, «хатын-кыз бәхетен татырга» маташкан трансвестит та бер дәрәҗәдә бәхетсез.

9 Гашыйк булуын хатын-кыз башлап үзе белдерүгә ничек карыйсыз?

– Хупламыйм. Мин, гомумән, баш – югарыда, аяклар җирдә булу ягында. Кызганыч, бүгенге заманда егетләр белән кызлар арасындагы аерма кимегәннән-кими бара. Физиологлар моны малайлар эчкән газировкада, ашаган фаст-фудта хатын-кыз гормоннары – эстрогеннар күп булу белән аңлата, психологлар исә гаиләдә ата кеше роле кимү турында сөйли... Балаларның уеннары да бертөрле бит хәзер – барысы да смартфонга, компьютерга кадалган: кызлар кулына курчак алмый, малайлар «сугыш-сугыш» уйный белми. Егетләр хатын-кыз сыман җебеган булып үсә, кызлар ир-ат кебек лап-лоп атлап йөри – кая ул көянтә-чиләк белән су ташып үскән сылуларның нечкә билләре, егетләрне иләсләндереп атлап йөрүләре! Нәтиҗәдә, бүгенге көндә еш кына егетләр түгел, ә кызлар өйләнә – тәкъдим ясауны да, туй хәстәрен дә кызлар үз өстенә ала... Асты өскә килгән дөнья димичә, ни дисең?!

10 Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә дип саныйсыз?

– Хатын-кызның эчке дөньясы минем өчен шулкадәр зур табышмак ки, хәтта бу сорауга җавап та эзләп карамыйм – барыбер берни әйтә алмам.

11 Хатын-кызларның үзегезнең кайсы якларыгызга игътибар итүне көтәсез?

– Чибәрлегем – чамалы, башымда чәч – санаулы, кесәм – әллә ни калын түгел, шулай булгач, бөтен ышанычым – акылыма, тапкырлыгыма һәм юмор хисемә.

12 Ир-атны артык чибәр һәм көчле хатын-кызлар куркыта, диләр. Бу, чынлап та, шулаймы?

– Төрле ирләр бар. Берәүләрне, чыннан да, куркыта. Ә икенчеләрендә, киресенчә, юлбарыс ауларга чыккан сунарчы азартын уята. Үзем шул ике төр аралыгында кысылып калдым, дөрес, беренчеләренә шактый якынрак торам.

13 Ир-ат һәм хатын-кыз логикасы дигән төшенчә бар. Алар, сезнеңчә, бер-берсеннән нәрсә белән аерыла?

– Салкын һәм кайнар, плюс һәм минус, инь һәм янь... Ир-ат белән хатын-кыз – икесе ике полюста, шул очракта гына алар арасында электр барлыкка килә ала. Логикабыз да үзгә: безнеке күбрәк салкын акылга таяна, ә хатын-кызныкы – кайнар хискә, безнең вектор тышка омтыла, хатын-кызныкы эчкә тартыла.

14 Ир-ат белән хатын-кыз икесе ике галәмнән икәне билгеле инде. Кайчакларда аларның бер-берсен аңламаулары шуннан килеп чыга да.

– Балачактан бирле Шарлотта Кордның адашым – француз революционеры Маратны нигә үтергәнен аңлый алмыйм. Чынлап әйтәм!

15 Шундый очракны күзаллыйк әле: сез, ачыгып, арыпталып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән.

– Мондый очракны теориядә генә күзаллый алам, минем тормышта әле андый хәл булганы юк. Инде була калса, аптырап тормам – үзем дә бераз аш-суны маташтыра алам. Ашарлык, диләр өйдәгеләр. Бер генә кимчелек – артымнан тау кадәр юылмаган савыт-саба кала.

16 Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар, соңга калучан.

– Ачу килгән чак та була. Бу хәл белән һәм, гомумән, хатын белән көрәшеп торасы юк, ачу хисе белән көрәшергә кирәк.

17 Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша...

– Иң ошаганы – калын кызыл таба, мин аны бик яратам. Ә ошамаган бүләк мисалларын мин үземә бирелгәннәрдән түгел, тормыш юлымда очраганнардан гына искә төшерә алам. Әйтик, студент чакта, җыелышып, бер бик явыз укытучы ханымга бүләк ясадык: деканаттан адресын белешеп, өенә «Свиноводство» журналын яздырттык.



Песиләрне сыйпасаң...

«Кагылма, лишай йоктырасың!» Мыраубикәне сыйпарга дип үрелүче балаларыбызны әнә шулай кисәтергә ашыгабыз. Баланың тәнендә кызыл тап күрсәк, иң беренче шик аларга төшә. Тимрәү хайваннардан гына йогамы? Аннан ничек сакланырга һәм ничек дәваланырга? Бу хакта югары категорияле табиб-эпидемиолог, Республика балалар клиник хастаханәсенең эпидемиология бүлеге җитәкчесе, медицина фәннәре кандидаты Илсөя ФАЗЫЛҖАНОВА белән сөйләшәбез.

Тимрәүнең (халык телендә күбрәк лишай дип йөртелә) төрләре бик күп: кызыл тимрәү, уралма, гади тимрәү... Ләкин балалар аның кырчын тимрәү (стригущий) дигәнен ешрак йоктыра. Кырчын тимрәүнең медицина телендәге атамасы – микроспория. Үтә дә йогышлы бу авыруның сәбәпчесе – микроспорум гөмбәсе. Ул тирене, чәч һәм йон бөртекләрен, каш-керфекләрне, аларның тамырларын зарарлый. Микроспорум гөмбәсе гаять яшәүчән, йомшак һәм йөнтәс җирлектә еллар буе да яшәргә мөмкин, кояш нурына, температурага чыдам.

Әлеге чир белән күбесенчә балалар һәм 15 яшькә кадәрге яшүсмерләр авырый. Организмга ул тәндәге вак яралар аша үтеп керә. Иммунитетның зәгыйфьлеге аркасында бик тиз таралып, тиренең зур-зур өлешләрен зарарларга да мөмкин. Гадәттә, балалар тимрәүне авыру хайваннар белән уйнаганда ияртә. Әмма аны чирле кешенең шәхси әйберләрен, кием-салымын кулланып та йоктырырга була. Тимрәү чыккан урынга орынып киткәннән дә күчәргә мөмкин ул.

Чирне йоктырып өч көн узгач, микроспориянең беренче билгеләре күренә башлый. Кайчак бу чор ай ярымга да сузыла. Тәндә кызылалсу төстәге бођрасыман таплар барлыкка килә, алар кычыта, сулы куык белән каплана. Кашыгач, куык шартлап, тап өсте кутырлый, кубалаклана. Баш тиресе зарарланганда, чәч арасына түгәрәк пеләш таплар чыга. Җентекләп карасаң, чәчләр 4–8 миллиметр калдырып кыркылган сыман күренә. Чирнең рус телендәге атамасы да шушыннан алынган.

Дөрес диагнозны табиб-дерматолог кына куя. Баланың кырчын тимрәү йоктырганын раслау өчен, тән тиресе махсус люминесцент лампа белән тикшерелә. Микроспорум гөмбәсе белән зарарланган урыннар аның яктысыннан яшел төстә күренә. Дерматолог башка төрле тикшеренүләр дә билгеләргә мөмкин.

Заманча дәвалау чаралары ярдәмендә әлеге чирне тулысынча җиңеп була. Тәндәге таплар берикедән артмаса, күкертле-салицилллы яки дегетле-күкертле майлар билгеләнә. Зарарланган урын көнгә берничә тапкыр 2–5 процентлы йод эремәсе белән эшкәртелә. Таплар күп булып чыкса һәм баш тиресен дә зарарласа, гөмбәгә каршы кулланылучы антибиотиклар эчәргә туры килә. Бала тәмам савыгып бетмичә, аның балалар бакчасына яки мәктәпкә баруы тыела. Чирнең бик тә йогышлы булуы сәбәпле, шундый саклык чаралары күрергә туры килә.

Табиб киңәше

- балаларның хуҗасыз эт һәм мәчеләр белән уйнавына юл куймагыз;
- өегезгә яңа йомшак дус алырга уйласагыз, иң элек аны ветеринарга күрсәтегез;
- үзегездә яшәүче хайваннарны даими рәвештә ветеринарга күрсәтеп торыгыз;
- урамнан кергәч, баланы кулларын сабынлап юарга өйрәтегез;
- кеше мунчаласы белән юынмагыз һәм кеше сөлгесенә сөртенмәгез;
- гаиләдә һәркемнең шәхси гигиена әйберләрен булдырыгыз: тарак, сөлге һәркемгә аерым булсын;
- читләрнең баш киемнәрен, аяк киемнәрен кимәгез;
- ничек кенә баналь яңгырамасын – баланың иммунитетын күтәрергә тырышыгыз.



«Толлар өркәче»

Әлеге проблеманы шушылай атауның сәбәбе – ялгыз калган тол хатынның башын аска иеп, күңелсезләнеп йөрүеннән муенына бөкре чыга дип уйлау. Хатын-кызның гәүдәсен бозып, ямьсезләп торучы бу күренешнең сәбәбе чынлап та башны иеп йөрүдәме соң? Аның нилектән килеп чыгуы һәм дәвалау ысуллары турында безгә югары категорияле табиб, Республика клиник хастаханәсе травматология үзәгенең нейрохирургия бүлеге мөдире Валерий ИГНАТЬЕВ сөйли.

Хатын-кызларның гәүдә матурлыгын бозучы әлеге күренешне чир дип әйтү бик дөрес тә булмас. Бу – умыртканың җиденче буыны өстенә май катламы утыру. Күпләр аны остеохондроз аркасында барлыкка килә дип уйлый. Шеш дип борчылучылар да булгалый. «Толлар өркәче»нең остеохондроз белән дә, шеш белән дә бернинди бәйләнеше юк. Гомумән, умырткага кагылышы юк аның. Ул май тукымасыннан гына гыйбарәт.

Төп сәбәбе – гормоннар үзгәреше. 45–50 яшь – климакс чоры башланган вакыт. Организмда хатын-кыз һәм ир-ат гормоннарының балансы югала. Эстроген кими, тестостерон арта. Хатын-кыз гормоннары, нигездә, май тукымасында җитештерелгәнлектән, май катламын арттырып, организм бу кытлыкны тулыландырмакчы була. Ләкин ир-ат гормоннары тәэсирендә бу чорда инде артык майлар, көчле затлар тибына хас булганча, корсакка һәм җилкәгә «куна».

Тагын бер өстәмә сәбәп – хатынкызның озак вакытлар бер халәттә утырып эшләве. «Толлар өркәче»н икенче төрле «бухгалтер синдромы» дип тә атыйлар. Җилкәдәге мускулларның еллар дәвамында хәрәкәтсез, гел бер халәттә генә булуы муенга май катламы утыруын тизләтә генә.

Бу – күбесенчә артык авырлыктан интеккән, организмында май тукымасы күп булган хатын-кызларга хас. Гәүдә үзенчәлекләренә бәйле рәвештә, ул беленер-беленмәс кенә яки шактый ук зур да була. Муен кыска булганда аеруча күзгә ташлана. Бетерү чараларын күрмәсәң, өлкәнәйгән саен зурая гына бара. Артык зурайса, муендагы кан тамырларын һәм нерв төеннәрен кысарга, баш һәм җилкәләрне авырттырырга мөмкин. Аннары, мондый «таучык»ның хатын-кыз гәүдәсенә матурлык өстәмәвен дә әйтеп үтәргә кирәктер. Хәер, ул ир-атларда да күзәтелә, аларда исә май бөтен җилкә киңлегенә ята.

Дәвалау ысулларына килгәндә, әлбәттә, иң элек участок табибына күренү мөһим. Ул тиеш дип тапса, эндокринологка юллама бирә. Төп сәбәп гормоннар булганлыктан, гормоннарга анализ бирү зарур.

Иң үтемле һәм һәркем куллана ала торган дәва чарасы – массаж. Сүз, билгеле, мануаль массаж турында бармый, анысын умырткада бөсерләр булу-булмауга тикшеренгәч кенә ясарга ярый. Мин исә тән мускулларын йомшарта һәм тонусын арттыра торган гадәти массаж турында әйтәм. Аны үзеңә үзең ясарга да була.

Икенче чара – махсус гимнастика. Муендагы «өркәч» күбесенчә җилкә мускулларының хәрәкәтсезлегеннән зурая. Кулларны ян-якка җәеп, әйләнмәле хәрәкәтләр ясау, чиратлаштырып күтәрү, иңбашларын чиратлаштырып күтәреп, алга-артка таба җыеру, муенны алга-артка, уңга-сулга бору кебек гади генә күнегүләр ярдәмендә әлеге «өркәч»тән арынырга була.

Шулай ук физиодәва да кулланып карарга мөмкин. Пациентларыма бассейнга да язылырга киңәш итәм мин. Арка-җилкә мускуллары өчен (гомумән, организмга тулаем) суда йөзү бик яхшы тәэсир итә. Ул бу проблеманы гына түгел, умыртка һәм мускуллар белән бәйле башка бик күп чирләрне дәваларга мөмкинлек бирә.

Бик зур размерларга кадәр үсеп, кан тамырларын, нервларны кысып, авырттырып торса, бу очракта инде операция билгеләнә. Табиблык тәҗрибәмдә андый операцияләр ясаганым булды, ләкин сәбәбен бетермәсәң, ул урынга кабаттан май катламы утыра башлый. Шуңа да симптомнарны гына түгел, сәбәбен дә бетерү белән шөгыльләнергә кирәк.

Табиб киңәше

- матурлыкның нигезендә дөрес туклану һәм сәламәт тормыш рәвеше алып бару ята;
- артык авырлыктан арыну – сәламәтлеккә таба ясаган тәүге адым;
- гел бер урында утырып эшләүчеләр, вакыт-вакыт бүленеп, тәннәрен яздырып алуны гадәт итсен;
- климакс башланган вакыт – хатын-кыз организмы өчен катлаулы чор. Ничек кенә мәшгуль булсагыз да, сәламәтлегегезне кайгыртырга вакыт табыгыз.

Яһүд ашы – чолнт

Яһүдләр – борынгы һәм зур милләтләрнең берсе. Дөньяда 13 миллионнан артык яһүд кешесе яши дип исәпләнә. Диннәре – иудаизм, телләре иврит һәм идиш. Яһүд кешесе кайда гына яшәсә дә, үзенең тамырларын хөрмәт итә, дини бәйрәмнәрне игътибарсыз калдырмый. Иң зур дини бәйрәмнәрнең берсе – Песах – Израиль улларының коллыктан котылып, бер милләт булып оешкан көннәре. Песах җиде көн дәвам итә. Бу көннәрдә йортта әчеткеч кушып әзерләнгән ризыклар, хәтта ипи валчыгы да булырга тиеш түгел. Шуңа да хуҗабикәләр аңа ныклап әзерләнә.
Яңа ел, ягъни Рош ха-Шананы да зурлап билгеләп үтәләр. Быел ул 30 сентябрьдә уздырыла. Бу көнне бер еллык язмыш языла дип уйланыла. Мул табынга мәҗбүри ризыклардан түгәрәк икмәк, балык (муллык символы), балык яки бәрән башы (баш булу өчен), кишер тәгәрмәчләре (акчага юрала), алма һәм бал куела.
Яһүдиләр яратып һәм көтеп ала торган көннәрнең иң олысы – Шаббат, ягъни атнаның җиденче көне – шимбә. Дини ышанулар буенча, Илаһи Илаһ алты көн буе Җиһанны бар кыла, ә җиденче көнне ял итә. Шаббатта эш эшләү, ризык әзерләү, ут кабызу һәм сүндерү тыела. Аңа җомгадан ук әзерләнәләр. «Хуҗабикә» сәхифәсенең бүгенге кунагы – Екатерина ПИЛЬ яһүдләрнең Шаббатка әзерләнә торган милли ашларыннан берсе булган чолнт пешереп карарга тәкъдим итә. Элек чолнтны җомгадан мичкә куеп калдыра торган булганнар. Шунда озаклап, томаланып пешкән ул. Шаббатта ризык әзерләү тыелса да, гаилә кайнар ризыксыз калырга тиеш түгел. Бүген мичләр юк, яһүд гаиләләрендә аның вазыйфасын электр белән эшләүче чуен такта үти. Әйдәгез әле, яһүдләрнең бу ашын без дә пешереп карыйк.





Кирәк

- 500 г сөяксез ит (тана яки бәрән ите);
- 2 баш суган;
- 2 стакан фасоль (ак фасоль дә, кызылы да ярый);
- чама белән бәрәңге;
- тәменчә тоз, кара һәм кызыл борыч, зира аш тәмләткече.

Эш барышы

- Фасольне суга салып бүрттерәбез.
- Суганны ваклап турап, үсемлек маенда кыздырабыз.
- Аның өстенә шакмаклап туралган ит салабыз. Ул да бераз кызарга тиеш.
- Ит өстенә салкын су агызып, кайнатып чыгарабыз һәм сүрән утта 25–30 минут пешерәбез.
- Шулпага бүрттерелгән фасольне салабыз. Үзебез исә ул арада бәрәңге әрчеп, эрерәк кисәкләргә турыйбыз.
- Бәрәңгене дә шулпага кушып, әзер булганчы пешерәбез. Тәменчә тоз, кара һәм кызыл борыч, зира өстибез.
- Чолнтны кайнар килеш табынга бирәбез. Өстенә туралган укроп белән петрушка сибәбез.
- Ашларыгыз тәмле булсын!



Фото: Анна Арахамия



Фото: www.pixabay.com

Озней Аман

Рәвеше белән безнең өчпочмакларга охшаш бу баллы печеньены Яңа ел табынына әзерлиләр. Ул ачы камырдан да, төчесеннән дә пешерелә. Эчлеге төрлечә булырга мөмкин.

100 г атланмайны һәм 250 г шикәр комын зур савытта күпертәбез. Икенче бер савытта йомырка белән сөтне туглыйбыз, тоз һәм ванилин өстибез. 200–250 г он илибез. Күпертелгән атланмайга онның өчтән берен салып күпертәбез. Аннары онны һәм тугланган йомырканы азлап-азлап куша-куша, камырны басып бетерәбез. Ул йомшак һәм үзле булырга, кулга ябышмаска тиеш. Камырны 1 сәгатькә суыткычка куеп торабыз.

Эчлек өчен 130 г тарттырылган мәк орлыгын, 75 г туралган төшсез йөземне 120 мл сөттә 10–15 минут пешерәбез. Шунда ук 3-4 аш кашыгы шикәр комы, 1–2 чәй кашыгы вак угычтан уылган лимон кабыгы, 2 аш кашыгы патока кушабыз. Эчлекне уттан алгач кына 1 чәй кашыгы ванилин өстибез.

Камырны 7-8 см диаметрлы итеп җәеп, уртасына 1-2 аш кашыгы эчлек салабыз. Өчпочмак итеп бөреп, 180 градус кызулыктагы мичтә 15 минут пешерәбез.

Мастер-классны оештыруда ярдәм иткәннәрә өчен Татарстан халыкларының Дуслык йортына рәхмәт белдерәбез.

Хуш исле каһвә...



Җир шарында яшәүчеләрнең күпчелеге иртәне каһвәдән башлый. Ул ләззәтне башка бернәрсә белән дә алыштырып булмый. Кәеф күтәрүче бу эчемлекнең килеп чыгышы да үзенчәлекле. Каһвәнен башлап кулланучылар Йәмәндә тарикать шәехләре булган. Алар, йокыларын качыру һәм аятьләр укып уздыру максатында каһвә куллана башлыйлар. Каһвәне «шахматчылар һәм фикер ияләре сөте» дип атаганнар.

Безнең эраның якынча VIII гасырында каһвә әле башта азык итеп кулланыла. Өлгергән җимешләрне, кузакларны һәм кабыгын ваклап, май кушып, шарчыклар рәвешендә әвәлиләр. Соңрак кипкән җимешләре дә шулай эшкәртелә. Аннары таш киледә тарттыралар. XII–XIII гасырларда киптерелгән кабыкны һәм яшел ногытны ачык утта балчыктан йә таштан эшләнгән савытта кыздыралар.

Соңгы вакытта кечерәк кенә җыйнак кофейняларга йөрү матур бер гадәткә кереп китте. Яшьләр дә, төрледән-төрле хуш исле каһвә эчеп, тын, аулак урында күңелләренә хуш килгән кеше белән аралашып утырырга яраталар. Натураль продуктларны куллана белү культурасы сәламәт яшәү рәвешенә кереп бара. Иртән бер чынаяк хуш исле каһвә эчмәсәң, көнең көн булмый. Тормышыбызга ул шулкадәр тирән үтеп кергән – аны чәй урынына эчәләр... Хәтта чәйдән өстенрәк тә күрәләр әле. Статистика буенча, судан кала каһвә кулланылышы ягыннан икенче урында тора.

Бу эчемлекнең тылсымлы сихәте нидә соң? Каһвәнең файдасы турындагы бәхәсләр соңгы арада гына тынып калгандай булды. Бөтен дөнья каһвә файдалымы, зарарлымы дип бәхәсләште. Һәм, ниһаять, соңгы тикшеренүләр каһвәнең организм өчен файдалы гына булып калмыйча, гомерне дә саклап кала алу үзлеген ачты. «Каһвәдә антиоксидантлар һәм фенол кушылмалары күп. Алар яман шешкә каршы торучанлыкны арттыра, – ди тикшеренү уздырган галимнәрнең берсе Вероника Сетяван. – Бу тикшеренүләр составындагы кайсы химик матдәләр гомерне озайтырга мөмкин икәнен күрсәтмәсә дә, каһвәне сәламәт диетага һәм яшәү рәвешенә кертергә мөмкин».

Сүз дә юк, каһвә – организмның тереклек итү сәләтен күтәрүче эчемлек. Аны куллану төрле сәбәпләр аркасындагы үлем очракларын киме-тә. Составындагы алкалоид кофеин йөрәк-кан тамырлары һәм нерв системасы эшчәнлеген тәэмин итә. Дөрес, кайбер чикләүләр дә бар:
аны чамасыз күп эчәргә ярамый.

Россиялеләр, гадәттә, тиз эри торган яки сублимир каһвә эчә, кофейняларда «Капучино»га өстенлек бирелә. Америкада исә «Американо» натураль каһвәсен яки «Капучино»ны зур чынаяклардан эчәргә яраталар. Итальяннар, французлар, испаннар һәм португаллар пешерелгән каһвәне шикәрсез генә эчә. Көньяк халкы чәйне бөтенләй дә эчми. Европалылар өстәлендә исә иртән йомшак күмәч йә круассан, джем белән каһвә торыр. Төрекләр комда пешерелгән төрек каһвәсеннән биһуш. Хәтта нәзберек инглизләр дә иртән чәй урынына сөтле каһвәне кулайрак күрә.

Төрле кофейняларда кофеның төрлечә пешерелгән төрле сортларын татып карагыз. Үзегезгә хуш килгәнен тапмый калмассыз. Ул кәефегезне дә күтәрер, үзенә бер ләззәт тә бирер.

СВЕЖЕОБЖАРЕННЫЙ
КОФЕ
С ЛЮБОВЬЮ
КОФЕЙНЯ
WAKE UP
coffee with love
Варим кофе на зерне собственной обжарки, с любовью, для Вас!
В меню классические, альтернативные и авторские кофейные напитки
Десерты по правильному питанию и веган-десерты
(без муки, сахара и молока)
Мы находимся на Декабристов 129
(Московский рынок, ст.м.Яшьлек)
РЕКЛАМА

Кучкар. Вакыйгаларга бай һәм уңышлы ай. Эшкә яңа көч, яңа максатлар белән тотынырсыз. Үткәндәге уңышсызлыкларны кабат анализлап, үз файдагызга бору өчен яхшы вакыт.

Үгезбозау. Тынгысыз ай. Тирә-юнегездәге активлыктан арып киткәндәй булырсыз. Гаилә белән ял итү, өйдә ремонт башлау өчен кулай чор, тормыш мәшәкатьләренә иҗади карашыгыз ачылыр.

Игезәкләр. Моңарчы гамегездә дә булмаган әйберләр белән кызыксынып китәрсез, яңалыкка омтылыш барлыкка килер. Яңа эш, яңа шөгыль белән мавыгып, үзегезне өр-яңадан ачарсыз.

Кысла. Тыныч ай дип әйтеп булмый. Айның ыгы-зыгылы энергиясе бәхәскә, каршылыкка этәрә торган. Фикерегездә нык торып, якыннарыгызны үпкәләтә күрмәгез, компромисслар эзләргә туры килер.

Арыслан. Уңышлы чорга аяк басасыз. Язмышыгызга язылган «йолдыз сәгате» сугар көннәр якынлаша. Шәхси тормышыгызда да, һөнәри өлкәдә дә күңелле үзгәрешләр булыр. Тормыштан үзегез теләгәнне алырсыз.

Сөмбелә. Энергия агымының яңа циклына аяк басасыз. Бераз күңел төшенкелеге күзәтелергә мөмкин. Максат куеп алга барсагыз, ямансулап утырырга вакытыгыз калмас.

Бизмән. Коллектив проектлар башлар өчен уңышлы ай. Үзләрен эшкә багышлаган Бизмәннәргә чынлап торып уңыш елмаячак. Бу айда башлаган эшләр – киләчәкнең нигезен тәшкил итә.

Чаян. Сәламәтлек өчен катлаулырак булса да, һөнәри өлкәдә үрләр яулар вакыт. Тырышлыгыгызның җимешләрен татырсыз, абруй казанырсыз. Финанс ягыгызны җайлар өчен дә мөмкинлек чыгар.

Укчы. Үзегезне яңа рольдә сынап карарга туры килер. Сездәге оптимизм теләсә кайсы ситуациядән исән-имин чыгарлык. Хыялларны чын итәр, яңа идеяләрне тормышка ашырыр өчен иң кулай чор.

Кәҗәмөгез. Тормышыгызның гаҗәеп тыныч, рәхәт бер чоры. Якыннарыгызның янәшәдә булуына сөенеп, һәр көннән тәм табып, үз рәхәтегез өчен яшәп алырсыз. Кайдандыр шактый акча керүе дә ихтимал.

Сукояр. Ашыкмый гына дөрес карарлар кабул итәргә мөмкинлек туар. Катлаулы мәсьәләләр дә уңай хәл ителер. Хаталарны төзәтү, башлаган эшләрне төгәлләү өчен яхшы вакыт. Яңа эшләргә алынмый торсагыз хәерле.

Балык. Тырышлык сорый торган катлаулы чор. Үзегезне зуррак вазыйфага билгеләүләре ихтимал. Яңалыкларга әзер торыгыз, бу айда аларның күп булуы көтелә. Ай ахыры бераз тынычрак узар.

зирәк кешедән зирәк сүз

ПАР АЛМА

Бу дөньяга килгәнче, бер-берләренә насыйп җаннар алма кебек түм-түгәрәк була, имеш. Ә Җир йөзенә җибәрер алдыннан Аллаһы Тәгалә аларны урталай бүлә һәм кешеләргә үз парларын эзләргә туры килә. Миллионнар арасыннан үзеңнекен табып алуы җиңел түгел. Инде бер-беребезне таптык дигәннәр дә гомер итү дәверендә: «Бу чынлап та минем парым булды микән?» – дип икеләнми калмый. Шушы хакта шәкертләре бер хәлфәгә сорау биргән: «Үз тиңеңне ничек табарга?» – дигән алар. Хәлфә алсу алманы урталай бүлгән дә, һәр ике яртысын да аерым-аерым тешләп алган. «Туры киләме хәзер бу өлешләр бер-берсенә? – дип сораган ул укучыларыннан. – Дөнья әнә шулай һәрберебезне дә үзгәртә», – дигән хәлфә һәм тагын берничә алманы урталай бүлгән. Кулына төрле алмаларның яртыларын алып, аларны бер-берләренә якын китергән. «Бу өлешләр пар түгел», – диешкән шәкертләре. «Ә хәзер?» – дип сораган хәлфә һәм кулына тоткан ике кисәкне кара-каршы куеп, икесен дә берьюлы тешләгән. «Хәзер алар бер-берсенә туры килә», – дип җавап биргән укучылар. «Менә! Тормыш аларның икесен бергә үзгәртте, шуңа күрә бертөсле булдылар. Гаилә корганда да шулай. Бер алманың ике яртысы булып та, тормыш аерым-аерым үзгәртсә, алма инде бербөтен булмый. Ә икең ике алмадан булып та, бер тормышта кайнап, шатлык-кайгыларын бергә күреп, бертөсле кителсәң, бер-береңә иң туры килгән пар буласың, – дигән остаз. – Гаилә сере бер алманың ике яртысы булуда түгел, ә тормыш итү дәверендә икең бертөслегә әверелүдә».

* * *

Бәхетле гаиләләр бар да бер-берсенә охшаш, һәр бәхетсез гаилә үзенчә бәхетсез.

Лев Тостой (рус язучысы)

Ир һәм хатын булып яшәү – сәнгать, аны көн саен яңартып торырга кирәк.

Рабиндранат Тагор (һинд шагыйре)

Гаилә кору өчен гашыйк булу да җитә. Ә менә саклар өчен сабырлыкка һәм гафу итәргә өйрәнәсе бар.

Тереза Ана (дөньякүләм билгеле монахиня)

Гаилә барысын да алыштыра. Башлы-күзле булганчы, яхшылап уйла: синең өчен нәрсә мөһимрәк – барысы дамы, әллә гаиләме?

Фаина Раневския (СССРның халык артисты)

Идеаль ир һәрвакыт башка хатынга өйләнгән булып чыга.

Фей Дьюневэй (Америка актрисасы)

Өч ай яратышу, өч ел ызгышу һәм утыз ел түзеп яшәү гаилә тормышы дип атала.

Бернар Вербер (француз язучысы, философ)

Киләчәк турында хатын-кыз – кияүгә чыкканчы, ә ир-ат өйләнгәч борчыла.

Коко Шанель (француз модельеры)

«Хатын-кыз галәме» сәхифәсен әзерләүче – Лилия ГӘРӘЕВА







ШИФА ТУЛЫ ШӘМАИЛЛӘР

Мәскәү архитектура институтын тәмамлап диплом алгач, Голландиягә китәргә уйлаган иҗатчыга Казанга әйләнеп кайтырга туры килә. Тиздән Казан дәүләт университетының татар филологиясе факультетында белем ала башлый ул, һәм гарәп теле дәресләре барышында... аңының эчке катламы ниндидер үзгә образлар дөньясына омтылуын тоя. «Төрле образлар ни өчендер нәкъ менә гарәп теле дәресләрендә күзаллана иде, – ди Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе каллиграф Рөстәм Шәмсутов. – Бераздан алар буенча аерым бер сериядә картиналар да яздым». Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институтында эшләгән чорда исә татар шәмаилләре тарихы белән кызыксынып китеп, анализлы фәнни хезмәт тә яза. Шуның нигезендә рус телендә «Слово и образ в татарском шамаиле» китабын нәшер итә. Иҗатын борынгы тарихка караган картиналардан башласа да, соңрак барыбер шәмаилләр язуны өстенрәк күрә рәссам. 2010 елны Колшәриф мәчетендә Татар шәмаиле галереясы ачып, бүгенге көнгә кадәр анда утызлап үзенчәлекле күргәзмә оештырган тырыш директор ул. Аны Казан дәүләт архитектура һәм төзелеш университетының архитектура һәм дизайн институтында студентларга белем бирүче галим буларак та беләләр.

«Шәмаилләрем классик төрдә түгел, башкача чишелештә, мин аларны майлы буяулар белән киндергә язам. Әсәрләрем – сынлы сәнгать һәм графика синтезы», – ди Рөстәм Шәмсутов, иҗатындагы «Укы!», «Аятел Көрси», «Әл-Фатиха», «Әл-Борак», «Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим!» кебек төгәл әсәрләрен барлап.

Тагын бер әһәмиятле проектын тормышка ашыруы белән дә горурлана: Байлар Сабасындагы сәләтле балалар өчен ачылган мәктәп вестибюле бизәлешенең идея авторы һәм җитәкчесе буларак, иҗатчы аны татар язмасы тарихы аша яктырткан. Гаять күләмле паннода төрки руннар чоры өчен – балчык плитәләр, гарәп әлифбасы өчен – төсле смальта, латин хәрефләре өчен – авангард стилендә авыштырылган плитәләр һәм кириллча язма өчен компьютер графикасы кулланылган. Бу бизәлеш 2014 елны тормышка ашырылса да, әлеге идеяне берничә ел буе күңелендә йөртә ул. «Шәмаилләр яза башлаганчы озын юл үттем, – ди рәссам. – Хәзер инде аларны язганда чит ил архитектура казанышларын күреп соклану да булышлык итә, илһам бирә. Әйтик, Испаниядә, Кордова мәчетен күреп кайттым. VIII гасырда төзелеп, XVI гасырда христиан чиркәве итеп үзгәртелүенә карамастан, бу мәчетнең михрабы әле дә... чиркәү эчендә саклана! Шулкадәр дә матур михрабны җимерергә беркем дә җөрьәт итми. Моннан кала, Истанбулның Зәңгәр мәчете һәм Шакирин мәчете белән дә тәэсирләндем!»

Рөстәм Илшат улы Татарстан мәчетләре бизәлешенә дә үз өлешен керткән каллиграф. Шулай да аның эшчәнлегенең төп асыл сәбабы – Татар шәмаиле галереясыдыр. «Казан Кремле»нә, Колшәриф мәчетенә килгән туристлар мәчеттә яңгырап торган Коръән сүрәләрен тыңлый-тыңлый, галереядагы шәмаилләрне карап йөреп, ислам сәнгате традицияләрендәге әсәрләре белән гасыр пульсын ишеттерүче рәссамнар иҗатына сокклануларын белдерәләр.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА

Рөстәм Шәмсутов













Фото: Рөстәм Шәмсутов

Алдагы биттә: «Татар язуы тарихы» панносы. Байлар Сабасындагы талантлы балалар мәктәбе интерьеры. Проект Исмаил Әхмәтовның Мәгарифкә һәм мәдәнияткә ярдәм итү фонды катнашында тормышка ашырылган.

«Укы!» (Коръән сүрәләреннән). Шәхси коллекция. (Мәскәү)
«Аятел Көрси аяте». «Казан» милли мәдәният үзәге
«Зөләйха». Шәхси коллекция. (Истанбул)

«Дөнья яратылу» («Басмала»). Татарстан дәүләт тарих һәм сәнгать музее.
«Әл-Борак». Шәхси коллекция (Мәскәү).
«Ана Бүре». Шәхси коллекция. (Истанбул).



РУК
Российский университет кооперации

Казанский кооперативный институт

Направления подготовки и специальности высшего и среднего профессионального образования

Казанский кооперативный институт ведет многопрофильную подготовку специалистов для основных отраслей экономики; учебный процесс максимально ориентирован на современные требования развития социально-экономических, хозяйственных отраслей Республики Татарстан, Российской Федерации.

Бакалавриат

Сервис Профиль: *Сервис транспортных средств* Вступительные испытания*: *Математика (27), Русский язык (36), Обществознание (42)*	**Туризм** Профиль: *Организация туристской деятельности* Вступительные испытания*: *История (32), Русский язык (36), Обществознание (42)*
Гостиничное дело Профиль: *Отельный бизнес* Вступительные испытания*: *История (32), Русский язык (36), Обществознание (42)*	**Товароведение** Профиль: *Экспертиза качества и безопасности товаров* Вступительные испытания*: *Математика (27), Русский язык (36), Обществознание (42)*
Бизнес-информатика Профиль: *Электронный бизнес* Вступительные испытания*: *Математика (27), Русский язык (36), Обществознание (42)*	**Менеджмент** Профиль: *Маркетинг; Спортивный менеджмент; Управление проектами; Управление талантами.* Вступительные испытания*: *Математика (27), Русский язык (36), Обществознание (42)*
Экономика Профиль: *Экономика кооперативных организаций; Исламские финансы; Экономика малого и среднего бизнеса; Бухгалтерский учет, анализ и аудит; Финансы и кредит.* Вступительные испытания*: *Математика (27), Русский язык (36), Обществознание (42)*	**Технология продукции и организация общественного питания** Профиль: *Организация производства и обслуживания в индустрии питания* Вступительные испытания*: *Математика (27), Русский язык (36), Биология (36)*

Стоимость обучения: Очная форма – от 69 000 руб. в год. Заочная форма – от 59 900 руб. в год

Сроки обучения: После школы: очная форма – 4 года; заочная форма – 4 года 6 месяцев.
После колледжа и техникума: очная форма – 3 года; заочная форма – 3 года 6 месяцев.

** Перечень вступительных испытаний с указанием минимального количества баллов. Форма проведения: письменное тестирование или ЕГЭ*

Специалитет

Таможенное дело Профиль: *Правоохранительная деятельность и информационные технологии в таможенном деле; Таможенная логистика; Таможенные платежи; Таможенный постаудит (постконтроль).* Вступительные испытания*: *Русский язык (36), Обществознание (42), Физическая культура (тестирование)*	**Экономическая безопасность** Профиль: *Экономико-правовое обеспечение экономической безопасности* Вступительные испытания: *Русский язык (36), Математика (27), Обществознание (42)*
Сроки обучения: очная форма – 5 лет; заочная форма – 5 лет 6 месяцев.	**Стоимость обучения:** Очная форма – от 75 500 руб. в год. Заочная форма – от 59 900 руб. в год.

Среднее профессиональное образование

Банковское дело *Квалификация: Специалист банковского дела* **Гостиничный сервис** *Квалификация: Менеджер* **Коммерция (по отраслям)** *Квалификация: Менеджер по продажам* **Право и организация социального обеспечения** *Квалификация: Юрист* **Товароведение и экспертиза качества потребительских товаров** *Квалификация: Товаровед-эксперт* **Экономика и бухгалтерский учет (по отраслям)** *Квалификация: Бухгалтер* **Срок обучения:** На базе 9 класса: очная форма – 2 года 10 месяцев; заочная форма – 3 года 6 месяцев. На базе 11 класса: очная форма – 1 год 10 месяцев; заочная форма – 2 года 6 месяцев. **Стоимость обучения:** Очная форма – от 52900 руб. в год. Заочная форма – от 29900 руб. в год.	**Прикладная информатика (по отраслям)** *Квалификация: Техник-программист* **Технология продукции общественного питания** *Квалификация: Техник-технолог* **Технология хлеба, кондитерских и макаронных изделий** *Квалификация: Техник-технолог* **Срок обучения:** На базе 9 класса: очная форма – 3 года 10 месяцев; заочная форма – 4 года 6 месяцев. На базе 11 класса: очная форма – 2 года 10 месяцев; заочная форма – 3 года 6 месяцев.

Прием документов начинается с 3 июня 2019 года по адресам:
- г. Казань, ул. Н. Ершова, д. 58 *(остановка «Кооперативный институт»)*;
- г. Казань, ул. Даурская, д. 32 *(остановка «Станция метро Аметьево»)*.

Перечень необходимых документов:
- паспорт или копия паспорта;
- оригинал или копия документа об образовании;
- фото 3х4 (4 штуки, цветные);

Дополнительно: ИНН, СНИЛС.

WWW.KAZAN.RUC.SU

+7 (843) 210-30-25

г. Казань, ул. Николая Ершова, д. 58
ул. Даурская, д. 32

 kazanruc  ruc_kazan  russiancoop

Лицензия: серия 90Л 01 № 0001089, рег. № 1023 от 16.06.2014 г. – выдана бессрочно. Свидетельство о государственной аккредитации № 1055 от 11 июля 2014 года

16+

РЕКЛАМА